**Рәдиф Гаташ**
**Сайланма әсәрләр**

**Өч томда**

## 3 том

**Хиссият аятьләре**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2009

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Г24

**Гаташ, Р.К.**

Сайланма әсәрләр : 3 томда / Рәдиф Гаташ ; кереш сүз авт. Р.Ганиева. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009.
ISBN 978-5-298-01864-7
3 т. : Хиссият аятьләре : шигырьләр. – 2009. – 351 б.
ISBN 978-5-298-01867-8

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташ әсәрләренең бу томына шагыйрьнең классик шигъриятебезнең сыналган борынгы жанрларында язылган газәл, робагый, мәдхия, касыйдәләре һәм укучыга яхшы билгеле лирик цикллары туплап бирелде.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01867-8 (3 т.)
ISBN 978-5-298-01864-7

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Гаташ Р.К., 2009

### ЗАМАННЫҢ ШИГЪРИ ПӘЙГАМБӘРЕ

Рәдиф Гаташ XX гасырның икенче яртысында СССР дигән империянең чылбырлары азмы-күпме какшаган, совет җәмгыяте торгынлык кичерә башлаган посттоталитар дәвердә шаулап-гөрләп килгән яшь татар «шестидесятниклары»ның талантлы бер вәкиле буларак әдәбият мәйданына аяк басты. Шәкертлек, өйрәнчеклек баскычлары аша үтү-сикерүләрне әллә ни кирәксенмичә, Рәдиф Гаташлар, Равил Фәйзуллиннар, Ренат Харислар, Гәрәй Рәхимнәр, Рөстәм Мингалимнәр, ә биш ел соңрак Мөдәррис Әгъләмов белән Зөлфәт Маликовлар буынының төп казанышы – «җепшеклек» елларыннан файдаланып, рәсми коммунистик идеологиянең шөрепләрне кысарга омтылышы белән тартышып, иҗтимагый яшәешебездәге күренешләрне агын ак, карасын кара дип объектив сурәтләүгә талпыныш ясау; дөньяга карашларда, әдәби-эстетик фикерләүдә, шигъри ритмнарны яңартуда хөрлеккә омтылу; бөтендөнья мәдәнияте, аеруча Көнбатыш Европа һәм рус әдәбияты казанышларын иҗади үзләштереп, Парнас биеклекләренә күтәрелү. «Алтмышынчылар», ярсу хисле Рәдиф Гаташлар буыны күздә тоткан максат-бурычлар җитмешенче-сиксәненче еллар дәвамында шактый уңышлы тормышка ашырыла. Совет режимы үз гражданнарының Көнбатыш демократиясе белән танышуын һич тә өнәмәгән елларда Рәдиф Гаташка, робагыйларында язганча, бик сирәк шагыйрьләргә насыйп була торган бәхет елмая. Ул Англия, Франция, Испания, Төркия кебек чит илләргә сәфәр чыга, дөнья күрә, яшәеш турындагы офыкларын киңәйтә. Нәтиҗә буларак, Европа халыкларының тарихы, социаль-икътисади халәте, менталитеты, архитектурасы, сәнгате, әдәбияты турында бай мәгълүмат биргән лирик-публицистик рухлы, романтик пафослы, фәлсәфи уйлар белән өртелгән «Европада татар шагыйрьләре» (1973–1984) исемле шигырьләр циклы мәйданга чыга. Автор үзенең Европага сәяхәтенең гадәти бер очраклылык кына түгел икәнлегенә дә басым ясый. Шагыйрьне бирегә Икенче бөтендөнья сугышы зилзиләләре вакытында җәсәдләре Европада ятып калган татар шагыйрьләре рухы – Җәлилләр, Кәримнәр, Кутуйлар, Баяннар чакырып китергән икән. Ул мәдәни Европаның үткәне, бүгенгесе белән даими фикри һәм хисси диалог-әңгәмәдә, бәхәстә. Рәдиф Гаташ һәрнәрсәгә татар зыялысы күзлегеннән бәя бирә, чагыштыра, нәтиҗә ясый. Кино тасмасындагы кебек тезелеп киткән ассоциацияләр чылбыры ярдәмендә күз алдына мәдәниятләр, диннәр бишеге булган кояшлы Урта диңгез буйлары, борынгы юнан, грек Гомер, италияле Данте поэмалары каһарманнары килеп баса. Лирик геройның уй-кичерешләренә ияреп, әле Шотландия, Англия, әле Германия,

Франциягә барып чыгасың, сихри елмаюы белән әсир итүче Леонардо да Винчинең Луврдагы Мона Лиза (Джоконда) рәсеме алдында сәҗдә кыласың. Гете, Гейне, Шиллер, Шекспир, Бернс, Шелли, Байрон кебек бөек романтикларның шигъри авазларын ишеткәндәй хәйран каласың. Испания башкаласы Мадридта Дон Кихот скульптурасына карап, Сервантесның акыллы да, җүләрлеге дә җитәрлек үлемсез героен күз алдына китерәсең, уйга таласың. Франко урнаштырган фашистик диктатура һәм тагын әллә нинди кара көчләр корбаны шагыйрь Гарсиа Лорканың фаҗигале язмышы хакында ишетеп борчыласың, ухылдыйсың. Шул ук испанлыларның кан коюга, җан кыюга корылган корридаларын кабул итмичә, татарның кешелекле сабантуйларын сагынасың. «Европада татар шагыйрьләре»нең әдәби җирлеге тулысы белән бүген Көнбатыш һәм Россия галимнәре бик тә мавыгып тәфсилле өйрәнеп яткан интертекстуальлеккә корылган; Европадагы илләр, дәүләтләрнең иҗтимагый-тарихи, сәяси-мәдәни тормышын, асыл сыйфатларын, үзенчәлекләрен цитаталар, реминисценцияләр, аллюзия-ишарәләр ярдәмендә олуг бер рәссам сыман чагылдыруга юнәлтелгән.

Дөнья әдәбиятындагы традицияләр белән бәйлелекне күздә тотып, тәнкыйтьчеләр, әдәбият галимнәре, каләмдәшләре Рәдиф Гаташ иҗатын икегә – Көнчыгыш һәм Көнбатыш чорларына бүлеп, аны Евразия шагыйре дип атыйлар. Әйе, Рәдиф Гаташ иҗаты ике канатлы, ике терәкле. Романтик-публицистик пафослы беренче чор лирикасында ул эчтәлек-мотивларда, поэтика өлкәсендәге эзләнүләрдә, ирекле ритм-рифмалар сайлауда Көнбатыш Европа әдәбиятлары тәҗрибәсен якын күрде. Шагыйрь, әле XX гасыр башында да «Гыйльм илә хикмәт кояшы тугъды мәгърибтән хазир» дип язган Тукай кебек, үзенең аурупачылык шигаренә ихлас күңелдән ышанган иде.

Гаделлек өчен шуны да искәртергә кирәк, Рәдиф Гаташ поэзиясенең Көнбатыш һәм Көнчыгыш чорларын бер-берсеннән Бөек Кытай дивары белән аерып каршы кую да мөмкин түгел. Көнбатыш традицияләренә өстенлек биргән заманда да Рәдиф Гаташ милли җирлектән, халык иҗатыннан, тарихи хәтеребездән аерылмады; Кол Гали, Котб, Сәйф Сараи, Мәүла Колый, Утыз Имәни, Кандалыйларның шигъри тәҗрибәсен һәрдаим күз уңында тотты; Тукай уты, Дәрдемәнд аһәңе, Рәми бунты аңа һәрвакыт юлдаш булды; Бабич, Такташ, Җәлил, Туфан, Хәким, Наҗар Нәҗми, Мостай Кәрим, Назыйм Хикмәтләр шигъри остаз булып калуларын дәвам итте.

Иҗатының Көнбатыш чорында Рәдиф Гаташ поэзиясендә шәркыйлек бер дә күзгә ташланмый дип әйтеп булмый. Шагыйрь гарәп мотивларына («Җиде төн») мөрәҗәгать итә, газәлләр дә язгалап куя. Әмма социалистик реализм эстетикасы хакимлек иткән бу елларда әллә ни зур урын алып тормаган бу шәркый элементлар да, «Көнчыгыш поэзиясе белән мавыгу» дип, тискәре бәяләнә.

Рәдиф Гаташның Көнбатыштан үрнәк һәм гыйбрәт алу, кан яңарту чоры 60–80 нче еллардагы татар шигъриятен дөньякүләм әдәби барышка якынайтты, мәдәни багланышларның интертекстуальлек белән сугарылган өр-яңа төрен гамәлгә кертте, мәдәни-әдәби хәрәкәтебездә традицияләр кабул итүнең яңа традиционлылык (неотрадиционализм) дигән юнәлешенә нигез салды.

Иҗатының икенче чорында да Рәдиф Гаташ традицияләрне яңартып бирү ысулына турылыклы булып калды. Әмма егерменче гасырның 90 нчы елларында илдә барлыкка килгән иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади вазгыять, коммунистик бәйнәлмиләл идеяләренең милли идеаллар белән алмашынуы тарихи барышка, совет чорындагы яшәешкә, Гареб һәм Шәрекъ мәдәниятләренә мөнәсәбәтне тамырдан үзгәртте, аларга яңача бәя бирү, яңа маяклар эзләү тарихи зарурият буларак көн тәртибенә килеп басты. Иҗтимагый формацияләр алмашыну, империядәге бер төркем халыкларның колониаль бәйлелектән котылуы татар халкының һәм аның зыялыларының узган тарихта югалган дәүләтчелек, мөстәкыйльлек, онытылырга мәҗбүр ителгән мәдәни-әдәби мирас турындагы уй-фикерләрен кузгатып җибәрде. Советча яшәү рәвешен тәнкыйтьләгән, кыргый капитализмның вәхши кануннарына, аның кешелексезлегенә ризасызлык белдергән, фетнә күтәргән, әдәби-эстетик табигате белән бик тә чуар булган, егерменче йөз башы татар модернизмының кайбер чалымнарын хәтерләткән төрле жанрлардагы постмодернизм әдәбияты барлыкка килде. Үз чиратында ул урта гасыр һәм яңа заман татар әдәбиятында ныклы тамырлары булган, сәнгатьчә фикерләүнең реалистик һәм романтик төрләрен яңа карашлар, өслүбләр, иҗат ысуллары, алымнары һәм дә антиутопиягә тартым, антигеройлар белән тулган, бәхәс уяткан әсәрләр белән баетты. Постмодернистлар җәмгыятьне, көндәлек яшәешне басып киткән гаделсезлек, бозыклык, җенси азгынлык, ришвәтчелек, наркомания кебек чирләрне, байлык үзләштерү өчен кылынган бихисап җинаятьләрне, суеш-үтерешләрне кире кактылар; аларны кешелекне, милләтне һәлакәткә, инкыйразга илтә торган социаль зарарлы күренеш дип тамгалап, экзистенциалистларча сыкрандылар, сызландылар йә булмаса ирония, пародия, фарс-буффонада, абсурд, уен, тамаша күрсәтү алымнары ярдәмендә тәнкыйть һәм көлү объекты иттеләр.

Әйтергә кирәк, татар язучылары җитмеш ел дәвамында социализм, ә аннан соң капитализм алып килгән афәтләрне сурәтләү белән генә чикләнмәделәр. Алар арасында татар милләтен, аның улларын һәм кызларын шат, бәхетле, кешелекле итү уй-хыяллары белән янган-көйгән романтик шагыйрь Рәдиф Гаташ та бар иде. Бу күренекле шагыйрь үзенең бөтен вөҗүде белән совет чорының атеистик пропагандасы табу салган Коръән тәгълиматын, аның Алланы да, Кешене дә олылаган әт-Тәүхид фәлсәфәсен, аеруча кешенең акылына һәм хисләренә мәдхия укыган гарәп-фарсы-төрки Ренессанс әдәбиятлары казанышларын үз итте, алардагы илаһи һәм дөньяви мәхәббәт мотивларына бәйле мәңгелек рухи кыйммәтләрне халыкка кайтаруны үзенең изге бурычы итеп санады. Озак та көттерми, Рәдиф Гаташның мөселман мәдәниятенең күзләрне камаштырырлык шигъри җәүһәрләре балкышын чагылдырган, Шәрекъ сүз сәнгатенең фәлсәфи-эстетик, этик ачышларын гәүдәләндергән, гүзәллекне, мәхәббәтне, галәмне хәрәкәткә китерә торган бөек көч дип таныган «илаһи каләм» дәфтәрләре дөнья күрә. Бу шигырь җыентыклары XX–XXI гасырлар чигендә яңарыш кичергән татар әдәбиятында яңа традиционализм юнәлешенең яңа шәрекъчелек (неоориентализм) дип аталган икенче бер яңа канатына нигез сала.

Рәдиф Гаташның шәркыйлек чоры лирикасындагы үзәк мотив –гуманистик идеаллар белән сугарылган Мәхәббәт. Шәрекъ Ренессансы шагыйрьләречә, ул да мәхәббәткә универсаль эчтәлек сала, гашыйк булу күкләрдә барлыкка килгән, дөнья мәхәббәттән барлыкка килгән дип исәпли. Шуңа күрә шагыйрьнең лирик герое өчен мәхәббәт ул – Аллаһы Тәгалә һәм мәңгелек каршында баш ию дә; җир тормышында «бәхетле утлар» кабызу, шатлыклы бәйрәм итеп кабул итү дә; кайгы-хәсрәтләрне Йосыф пәйгамбәр кебек күркәм сабырлык белән кичерү дә; моннан биш мең еллар элек яшәгән дип фаразланган «туранлык»тан – «Ана йорт»тан килгән, дөньяны тетрәткән борынгы төркиләрне сагыну да; милләтнең шигъри пәйгамбәрләрен ихтирам итү дә; моңлы, сагышлы милли тарихыңны, илеңне, җиреңне, «утлар, сулар кичкән» газиз туган телеңне, татарыңны, «төрки рухның мәркәзе» Казаныңны ярату да; әби-бабаларны, ата-аналарны, балаларны хөрмәт итү дә; гомумән, Аллаһы халикъ иткән (яраткан) Кешене табигатьнең таҗы дип олылау да! Гашыйклык ул – шагыйрь Габдулла Тукайның илһамчысы, иҗатка рухландыручы сөекле Зәйтүнәсенә ләззәтле һәм газаплы яшерен

әфләтүн мәхәббәте тоту да. Мәхәббәт ул – акылларны әсир иткән милләт йолдызлары Ләйләләргә, җир гүзәлләре Чулпан, Луизаларга Мәҗнүн кебек гашыйк булудан туган гедонистик мотивлар да, нәфис эротик тасвирлар һәм кичерешләр дә, җан һәм тән белән яраткан сөйгән ярлар да!

Мәхәббәт темасының сыйдырышлы эчтәлекле, күп мотивлы булуы турында шагыйрь үзе дә әйтеп үтә:

Мин тормышны бөек иткән көчне
Мәхәббәттә –
Илгә, җиргә мәхәббәттә күрәм
Һәм яшермим: сөям, сөям!
...Бер сүзем юк...
Мәхәббәтнең
Мәҗнүн исемендәге премиясен
Бу ел өчен миңа бирегез, яме?!

*(Мәхәббәттән башка...)*

Рәдиф Гаташның универсаль яңгырашлы гыйшык җырлары фарсы һәм азәрбайҗан әдәбиятларының атаклы лириклары Хафиз белән Нәсиминең парәкәнд (чәчелмеш) газәлләрен хәтерләтә. Бу шагыйрьләрнең кайбер әсәрләрен ул татарчага да тәрҗемә иткән иде. Илаһилык белән дөньявилыкны бербөтен итеп үргән, суфичылыктан алынган образ-сурәтләр белән сипләнгән Хафиз газәлләре аңа аеруча якын. Хафиз иҗаты аша ул борынгы гарәпләрнең гомәриләр һәм гозрә кабиләләре шагыйрьләреннән килә торган ике традицияне «мәхәббәт ул – шатлык», «мәхәббәт ул – кайгы-хәсрәт, үлем» дигән мотивларны үзләштерде. Бу очракта да аңа традицияләргә иҗади якын килергә туры килде. Гозрә газәлләрендә җавапсыз мәхәббәттән гамь чигү, сыкрану, газаплану, Генрих Гейнечә әйтсәк, «гашыйклыктан үлү» («полюбив умирали»), Ризаэтдин Фәхретдиновча, мәхәббәттән «шәһит китү» мотивы Рәдиф Гаташ тарафыннан алып ташланды, фаҗигалелек якты сагыш, күңел хөрлеге, яшәү дәрте белән алмашынды.

Шәрекъ әдәбиятлары өчен бик тә традицион дип исәпләнгән газәл жанрының мәгънәви эчтәлеге үзгәрүдә европалылар белән русларның мәхәббәт лирикасы, Эрос турындагы карашлары йогынтысы шактый зур булган дип әйтми калу мөмкин түгел. «Мәңгелек сусау» китабында еш очраган аллюзияләр, реминисценцияләр Рәдиф Гаташ шигъриятендә борынгы юнан шагыйре Анакреонтның, француз һәм алман трубадурлары, миннезингерлары, италияле Ф.Петрарканың сөеклесе Лаурага багышланган сонетлары, В.А.Соловьевның мәңге нәфис хатын-кыз җаны фәлсәфәсе һәм А.Блокның «Гүзәл ханым шигырьләре» циклының эзләре калу турында сөйли.

Традицияләргә мөнәсәбәттә Рәдиф Гаташ газәлләрендә кызыклы бер үзенчәлек күзәтелә. Ул урта гасыр шәрекъ һәм татар әдәбиятларында мәҗбүри канун төсен алган нәзыйрәчелектән, тәкълидчелектән, мәгълүм авторларга иярүләр язудан баш тарта, Тукайлар заманыннан ук тернәкләнеп килгән традиционализмның үзгә бер төренә – интертекстуальлеккә мөрәҗәгать итә.

Рәдиф Гаташның мәхәббәт темасына язылган газәлләре, робагыйлары, Шәрекъ Ренессанс эстетикасы кануннары таләп иткәнчә, фәнниләр һәм фәлсәфи эчтәлеклеләр. Белгәнебезчә, Шәрекътә шигырьләре фәнни-фәлсәфи эчтәлекле булмаган шагыйрьләрне «аварга торган дивар» (Фөзүли) белән тиңләгәннәр. Рәдиф Гаташ газәлләре исә Ибн Сина таләп иткән акыл (гыйлем) белән хис бөтенлеген тәшкил иткән «рух» – рухилык таләпләренә җавап бирә. Аның сәнгатьчә фикерләвендәге һәр шигъри күзәнәк Ибн Сина, Ибн Хазм, әл-Җаһизларның гыйшык рисаләләрендә чагылыш тапкан мәхәббәт фәлсәфәсе турындагы теоретик карашлары белән таныш булуга ишарә ясый. Төрки халыкларда акыллылык, гыйлемлелек шагыйрь булу өчен беренчел шарт булып исәпләнгән. Шуңа күрә дә казахларның атаклы мәгърифәтче шагыйре Абай Кунанбаев: «Шигырь – сүзнең патшасы, Яратып әйтәдер ир данасы» (укымышлысы, аңлысы) дип язып калдырган. Кытай-япон йолдызнамәсе буенча Рәдиф Гаташ Елан елында туган. Бу елда дөньяга килгәннәр – тирәнтен уйлаучы, фәлсәфи фикер йөртүче гыйлем ияләре, хис-кичерешләрнең дә иң югары баскычында торучылар. Рәдиф Гаташ та кеше һәм шагыйрь буларак интеллектуаль үсешнең югары дәрәҗәсенә күтәрелгән зыялыларыбызның иң күренеклесе.

Рәдиф Гаташның татар сүз сәнгате үсешенә керткән өлеше бик тә зур. Ул инде аңа ярты гасырга якын фидакярләрчә хезмәт итә; татар, башкорт, рус телләрендә егерме алты китап чыгара, фәнни-теоретик мәкаләләр яза; әдәбиятыбызга яшь кадрлар әзерләү өлкәсендә дә җигелеп эшли. Көчле фәлсәфи рухы, традицияләр өлкәсендәге яңа әдәби-эстетик ачышлары белән язмыш һәм тормыш сынауларын җиңә-җиңә, җан азыгына тиң шигъри тәлгәшләре белән замандашларын сөендерүен дәвам итә.

*Резеда Ганиева,*
*филология фәннәре докторы*
*2008*

# *I. Чулпан-йолдыз калыкканда*
## *(1994)*

* * *

Акыл җуеп, кем йотылды күзләреңә?
Онытылды кисәтүле сүзләрең дә...
Бар булмышым – савап, гөнаһ җыйган башым
Сәҗдәгә егылды ул көн – тезләреңә.

Тарих мең дә тугыз йөз дә туксан дүрттә
Кол иттең син гашыйк җанын гомерлеккә.
Муенчагым – көмеш, алтын келәймәсен
Шигырь итеп язарга җан илһам көтә.

Шуны сиздем тугыз йөз дә туксан дүрттә:
Яшьлек үтте мәхәббәттә, гомер үтә –
Бәлки, соң кат ашам яңа биеклеккә;
Рәхмәт сиңа, Илаһи Нур –
горур бикә!

* * *

Кыз хыялы! Сәер уйлар, серле йөк...
Иделдән диңгез ягына килдең ник?

Кайсы кәрванның нык, чыдам дөясе
Илтте иңендә бай җаның дөньясын?

Атаклы чал Хәзәрдә бит чылатып,
Еладыңмы аннан комына ятып?

Җир маеннан чыраг кабызган шәһәр
Яшьлегеңә булдымы калым-мәһәр?

Уен идеме, туеңмы ул кичләр?
Гомереңне яктырткан айлы хисләр...

Азак сагынгансың, бәлки: кәрваннар
Алырга сине илеңнән барганнар.

Ни белән ул баеган яшь җаның тик? –
Таумы анда? Кәрванчыга авыр бик...

«Кайта, – дисең, – төрки шигырь гөлләре,
Гел чәчәктә, мәңге тере үзләре.

Шул гөлләрнең исе тансык Иделгә:
Мең-мең еллар яшәсеннәр илемдә!»

...Сәяхәт... йә сәясәтме? Риваять –
Җаныңның бер сәфәреннән хикәят.

Хыялың бит гел ай тулган чакларда
Шунда дәшә – сүнмәгән учакларга.

## БӨЕКЛӘРГӘ КАСЫЙДӘ

Низами! Кыпчак кызы, дип,
Аппак, дип янган даһи!
Фарсыча язган кулың тик,
Рухың – төрки, валлаһи!

Фөзүли! Көчең – Ходайдан,
Юк газәлдә тиңдәшең!
Сөйгәнсең тигез – сөрткәнсең
Шигырьдә яр, ил яшен.

Нәсими! Төрки пәйгамбәр!
Син – пирем*, хәким-шагыйрь.
Мин дә «Аллага тиң»ме әллә?
Бармы көч миндә, сабыр?

Вагыйф! Аһ, ялкынлы йөрәк,
Яр данлауда остазым!
Әйт миңа: «шаһ кызы» күңелен
Яуларга бармы сазым?!

Видади, Закир – гел бергә,
Гаҗәеп мошаирә.
Төркиләр күңеле күктәдер –
«Торналар» белән бергә?

...Остазлар! Рухыгызга кагылып,
Уятсам ялгыш – гафу!
Нишлим, ярым сезгә гашыйк,
Тетрәткән җанын Баку...

Ул илһам бирмәсә, бүген
Ничек тасвирлар идем
Мең еллар сезне яндырган
Төрки «дилбәр»нең миңен?!

Шигырегездән түгел бугай,
Сөюдән сезнең көнлим;
Юкса шашкын хисле Гаташ
Сезләргә, бәлки, тиң мин?!

* * *

Әүвәл пәйда булып илдә вәкиле,
Озакламый аннан ислам да килде.
Моңа мең ел! Күңелләрдә – бер Илаһ!
Язмышыңны синең язган ул инде.

Дин тойгысын алганмын каумем аша,
Ә нигә мәҗүси уйлар бу башта? –
Сине уйлап багам, юллар салам мин,
Уем – тарих, Болгарларга тоташа.

Эзлим Ибне Фазлан узган юлларны,
Изге байракны ил кабул кылганны...
Яшел төсе күзләреңнең шуннандыр,
Күзаллыйм мин ялкын чәчле син ярны!

Күрәм: яңа дин өчен, вәкилләргә
Бүләк Кыз – син, китәсе – ят илләргә. –
Шул кол ярның – мин гашыйк үз корбаны,
Акыл җуеп, кермәдемме телләргә?!

...Югалтканмын сине мең еллар элек,
Юлга чыксам, бүген каян эзләргә?!

* * *

Тагын шул як дәшсә сине, ни әйтим?
Ерактан яр эзләүчегә дөнья киң!
Тагын Каспий дулкын какса җаныңда,
«Язмыш» димме? Үзең теләгән ләкин...

Тагын бер шигый баласы уеңда,
Баку баглары җанлана җырыңда.
Адашканмы йөрәге, бер илчеме? –
Болгар кызы әзәрләр кәрванында.

Тагын Каф тауга чакырса язмышың,
Җәй авышкан, табылырмы язың соң?!
Бөек Ефәк юлы, Чин, Әфган иле... –
Тәкъдирең хыялга кайсын язды соң?!

Тагын Туран җиле, гөлләр... Дөнья киң!
Сөнни ярың – мин калсам монда ятим?
Бакуга бакый мәхәббәт иясе,
«Бәхетле бул» димме? Әллә «Китмә!» дим?!

Тагын шул ил дәшсә, сиңа ни әйтим?!

* * *

Миннән соң да аязыр йә болыт торыр,
Яшь шат аваз моңсу өнем оныттырыр, –

Һәм битараф бу Казансу ярларында
Минем яшьне түкмәс мәҗнүн таллары да...

Сөембикә елавының кайтавазы –
Ерак тарих! Ил кызлары милли язны

Бәйрәм итәр... Шул көннәргә карап, ерак
Киләчәккә дәшсәм әгәр, ярлык сорап,

Камил чорның бәхет җыры-чыңнарында
Табылырмы урын минем моңнарыма?

Галәм – чиксез, барсын күреп ул аргандыр...
Вакыт-комны күп гомерләр сугаргандыр...

Гашыйк җаны, ир акылы һәр бөртектә.
Комнар күчә... вакыт ага... Сөю – үтә...

Әмма бүген, янып, рухым күккә ашса,
Илаһи юл күрсәтүче син ләбаса!

Тугры калсаң уртак ялкын-шигырьләргә,
Мин ышанмам җирдә хәтта үлемнәргә.

...Бүген, бәлки, моңсумындыр шигем барга?..

* * *

Бәлки, шагыйрьләр оҗмахы бу кала?
Ә мин – шуннан үзем бер киткән бала...

«Яшь Адәм чакларым» белгән урыннар
Сине үз итеп, сәламләп тордылар.

Уйчан идең зиратта – тау башында,
Сәгыйть Рәми кабер ташы каршында.

Остазның рухын яд итте йөрәкләр,
Күңелдә иде мөкатдәс теләкләр...

Сораштың гел Тукай булган җирләрне,
Бабич таланты балкыган көннәрне...

Ә мәчетләр ишегеннән кергәндә,
Яулык белән чәчеңне өреткәндә,

Күккә аштык бергә – Ходай катына,
Ә җирдә Салават аты чакыра...

Яңгыр яуды һаман, сизмичә йөрдек,
Иң-иң ихлас тойгыларга төрендек.

И сөендем: син – мин үскән якларда,
Кайтырбыз күк Хыял – бөре чакларга.

Биек Бакча, диден, – бу гүзәл кала;
Сөен, «Хауам»! «Оҗмах»та эзләр кала.

* * *

Ян әле син! Дөньяга без
Янар өчен яралган.
Яз! Рух каләмең Хактан бит
Язар өчен җан алган!

– Бар да булыр, вакыт килер,
Ашыктырма, Гаташым!..

– Ашыкмыйча ни хәл итим,
Гомер уза, җанашым...

Көл әле! Синдәйләр җирне
Ямьләр өчен яралган,
Бәлки, Кояшның үзеннән
Кыз күкрәге җан алган?!

– Күңел-касәм тулы сагыш,
Онытылсын, Гаташым...

– Яшьлекнең һәр халәте – җыр,
Кадерен бел, җанашым!
...Бак күккә! Юккамы Кеше
Йолдызга тиң яралган?
Бәлки, шунда кайтасы бар, –
Без бурычка җан алган!

– Җиргә инде күп кат килеп,
Киткәнмендер, Гаташым!

– Соң тапкыр Күккә ашканда
Бергә булыйк, җанашым!

* * *

Иске саутыңда, тән, яңа шәрабмы?
Сәрхуш җаным мәңгелектә корабмы?

Гомер җәе узган ирнең «азганы»,
Бәлки, бу хис? Әллә «Хакның язганы»?

Әллә табигатьтән соңгы мәрхәмәт –
Синең сөю – канда яңа хәрәкәт?!

Гади генә бер җир кызы сагышы
Йолдызларга илтәчәк нур-балкышмы?

Сайлап менә нәкъ минем рух-хисемне
Юнәлтәсең нигә шунда син мине?

Гөнаһларым күп – моны беләхалык,
Биеклеккә нигә минем җан лаек?

Пәйгамбәр дә тик үлеп аша күккә...
Гашыйкны ни илтә үлемсезлеккә?

Бөек хыял һәм ышаныч канаты
Биреп, мине яшәрттеме ярату?!

Иске саутыңда, тән, яшь җан шәрабым
Чайпалсын тик... Мәңгелектә корабым!

* * *

Сүзләр – гүя йөгерек су – җырлап акты!
Хисләр – үтә күренмәле, моң – якты!
Төшлегеңнән соң, гомер, бу нинди нур? –
Эт елыннан Дуңгыз елына чаклы?..

Күңелнең җәе авышкан – бу хакмы?
Әмма кояш ник кыздыра бу чаклы?
Болай да утларда янам – түзмәсәм
Эт елыннан Дуңгыз елына чаклы?..

Йолдызыннан чакыру-өнме? Гаташны
Галәм-күк юлына нинди көч атты?!
Беләм, үлем юк анда – тик тетрәнү
Эт елыннан Дуңгыз елына чаклы...

Җаннарыбыз бүген сер – табышмакмы?
Көтәбезме биектә кавышмакны?
Әле сагыну, шашу, сынау сәгате
Эт елыннан Дуңгыз елына чаклы...

Әле һәр көн, һәр мизгел җанга шакый:
Кыйммәт булачак, ди, сөю, җыр хакы.
Гомер белән түләнсә дә, йолдызым,
Балкыт юлны, килсен илаһи якты!

Озак еллар, соңгы җырыма чаклы...

**ОЛЫГАЙГАЧ, БЕР ДОГА**

Илаһым! Бу җанымны үзең
Тугры юлга салса идең!
Ул юл шул: йолдызымнан гел
Аерылмыйча янса идем!

Хаҗда, Кәгъбә ташын үбеп,
Ләйлә өчен ауруын –
Сөюен мәңгелек ит дип,
Мәҗнүннең ялваруын
Исеңә төшерәм... Минем хәл
Шуңа тиң, Тәңрем, бүген.
Сәҗдәгә егылсам, хисем
Әллә ул изге түгел?

Әүвәл без – Син яраткан җан,
Аннан соң сөю колы...
Мәхәббәткә юл уза тик
Бөек әмерең аркылы...

Кичер дә уем, ярлыка
Гөнаһлы гашыйк җанын.
Ялвара сиңа... Һәм ярына –
Догасы ихлас аның!

Илаһым! Һәр дөньяңда җан
Ак юлыңда калса иде,
Иманлы яшәп, пакь сөеп,
Ахыргача янса иде!

Тугры юлдан барса иде!

### «ҖЫРЛАР ҖЫРЫ»Н УКЫГАЧ

«Иерусалим кызлары, сез
Ишетәсезме, ялварам
Иртән ак күңелем белән,
Һәм яшь җәйраннар исменнән
Ялварам таңда, янам:
– Уятмагыз сөйгәнемне,
Ул арган, йокласачы...
Уятмагыз мәхәббәтне,
Ул үзе уянганчы...»

Бу – «җырлар җыры» Тәүраттан...
Ерак халыклар таушы
Ник шулай якын тоела? –
Чынлыгы, беләм, ачы...
– Уятма, – дисең бит син дә, –
Тимә арган хисләремә! –
Шуңа шагыйрьнең аһы...

Тик хәтерлим үз җырыңны:
– Кем, ышанып җаныма,
Серенада-гимн белән
Нур сузар хыялыма –
Яктыртыр кем дөньямны? Кем
Кушылыр җан җырыма?!

Уятырга телим сине,
Үз вакытын көткән җанны –
Татар кызын – бөре хисен,
Гүяки шигъри таңны...

Милләт кызлары, ишетегез,
Иртән сезгә ялварам:
Уятыгыз Мәхәббәтне!
Бөек җыр көчен, моң, дәртне
Алган ул кыз Алладан.
Балкысын халкым күгендә,
Уятыгыз! – мин янам,
Уятыгыз – ялварам...

## СИҢА – СӘГЫЙТЬ РӘМИГӘ ТӘКЪЛИДӘН

Азат булмадым шул, булмам гомергә,
Язган миңа гүзәл коллык күрергә.

Изге санап шуны, горур мин яшим.
Күңелемне тутырган яшерен яшем!

Кимеми гамь кайнаган савытымда,
Илаһи бу бер халәт хәятымда.

Хисләр язмыштан узыйк дип шашса да,
Бу бәхетне алмашмам мин башкага.

Яраткан Хак мине шулай – бар иткән,
Шәрекъ-гаребкә бер (!) гыйбрәт яр иткән.

Ашыкмыймын касә төбен күрергә,
Азат түгел, гашыйк булыйм гомергә!

## УФАДАН СИҢА ХАТ

Анда ни сөйли фонтаннар?
Монда никтер сүзсез алар
Уфада...
Синсез – хатирәләр өнсез,
Бар табигать гүя телсез...
Уф, Алла!

Анда ни сөйли фонтаннар?
Гаташтай шаулыймы алар
Казанда?
Ә монда кырыс көз йөзе,
Яфрак күмә безнең эзне
Һаман да.

Анда ни сөйли фонтаннар?
Каршыңа атыламы алар
Узганда?
...Йолдызың шул ук – биектә...
Күзләрем монда да күктә –
Чулпанда!

Анда ни сөйли фонтаннар?
Бәлки, арып, йоклый алар?
Уф, Аллам...
Салкын бу юлы матурлык,
Синсез башкача кайту юк
Уфама!

* * *

Ни китәрде Әфганда синең һушны?!
Һират гөле йә биек Һиндикушмы?

Әзәрдә соң, төрки күзләр карагач,
Арагызга кердеме ут-Карабах?

Һәм Азия – Термез, Карши капкасын,
Таулар белән хушлашып, бер япкач син,
Күпме ерак китсәң дә, дисең, алар
Озата килә... гел күренә шул таулар.

...Күңел язында таулар күп булганга,
Сәяхәткә дәштем, Идел, Чулманга...
Тик моңыңнан гүя туфан ташты да,
Мин дә тау (!) салдым аягың астына...
Карадык икәү кыядан дөньяга...

Туктаган килеп хыяллар Уфага!
Биеклекләр, мөгаен, язмышыңда,
Иркен сулый тауларда җаның шуңа...

Онытма: елады монда Гаташың,
Агыйделнең кочып изге ак ташын...

* * *

Әкияттәге өч патша кызы гүя
Утыра идегез тәрәз янында,
«Шәмдәлләрдә утлар» яндымы ул кич,
Әллә ялкын иде гашыйк җанымда?

Матурлыкның таҗлы өч кызы гүя –
Татар өметенең өч ак нуры сез.
Моң-бәхетегез булсын халкыма тоташ,
Җаныгыз – ил гаменнән аерылгысыз!

Өч карашны тоям, өч холык-фигыль,
Фал китабымда – өч язмыш иясен...
Синең туган көнең бу, йолдызым! Тик
Өчегезгә дә килә баш иясем!

Әкиятләрдән мирас гүя бүгенгә –
Өч алтын алма сез хыял бакчамда.
Мин җаваплы сезнең өчен: сакта мин,
Бирмәм ятларга, кем капка какса да...

Өчегезгә атап язган җырым, яр!
Ошар микән ул апаңа, сеңлеңә?

Алларына хистән мин энҗе чәчтем,
Юл күрсәтер, бәлки, алар күңеленә?

Сезгә бу җыр – сиңа, апаң, сеңлеңә...

* * *

Сәламнәрем сезгә – өч кыз туганга!
Сандугач чакырып, таңнар туганда,
Кайсыгыз йокысыз моңая анда?
Кайсыгыз тәрәзә ачкан дөньяга?
Сәламнәрем сезгә – өч кыз туганга!

Сандугач уяткан таң сызылганда,
Яз сулышын тоясыздыр дөньяда.
Бакчагызда нинди яктылык анда?
Туй күлмәге киеп, алмагачлар да
Тәрәзәгезгә киләме таңнарда?

Кайсыгыз йокысыз моңая анда?
Яшьлек күзләре язларда уяу ла.
Күзләрдән күчә җаннарга сорау да,
Җавабы табылыр, бәлки, бу айда –
Гөлгә охшап, җан ачылган язларда.

Кайсыгыз тәрәзә ачты дөньяга?
Керә матурлык – гүяки нур ага.
Миндә дә, ниһаять, илһам уяна!
Чакыру авазы ишетәм юлларда,
Миндә дә бит бар тәрәзә дөньяга!

Бу – рәхмәтем минем өч кыз туганга,
Юлым беркөнне сезгә тап булганга.
Шул бәхеттән исереп айнымаганга,
Гаташ тагын гашыйк булды дөньяга,
Ә хисләре сезгә – өч кыз туганга!

* * *

Ниндидер төпсез коеда калганмы
Яшьлек ядкарең – бәһасез балдагың?
Төштең эзләп нинди уй чоңгылына,
Алып чыгыйм сине кереп анда мин?

Табылырмы җуйган балдагың кабат?
Йөзеңә көләч яз нуры кайтырмы?
Яшерен сереңә – күңелеңә тимичә,
Яратырга телимен син матурны.

Оныттырыйм – дәва булыйм яраңа,
Гашыйк җыры биеккә дәшсен сине.
Әйт, ничегрәк коткарыйм уй-упкыннан,
Кайтарыйм синең шат, гамьсез хисеңне?

Ниндидер тирән коеда калган күк
Әллә күңелең синең, әллә балдагың –
Табармынмы? Бүген мин ул упкында
Аздан гына үзем торып калмадым,

Яшьлегем яктысын күрдем анда мин!

* * *

Яшь яр, миңа нигә ишегең бикле?
Ачылмасмы, көтсәм дә таңга тикле?
Әллә бәхетемнең киче дә җиттеме?
Күңел көнем әллә үтеп тә китте?

Яшьлекнеңме ишеге җанга бикле?
Ялынырга, бәлки? Кайчанга тикле?
...Хисләр язы – ул син идең түгелме?
Җәем үтеп, әллә көзләр дә җитте?

Яшәүгә дә ишек бер булыр бикле...
Сиздермичә куярлар авыр бикне.
Бәхет хисең җуйсаң, гомер дә үтәр,
Бәхет – нәкъ синең сөю... ник тиз бетте?

Ишегең, дөнья, китсәк без, гел бикле...
Ачылмас ул мәхшәр көненә тикле.
Җанына кертми елатсын бүген яр, –
Яшәү – бәхет! Үкенеч: гомер чикле.

Әйтче син, яр, ни фал: ишегең бикле?!

* * *

Гаебем синең алда зур: чал чәчем –
Сөеп шактый яшәдем җирдә, яшим...
«Мәхәббәт – җәмал сорамый» дигәннәр,
Сорамыйдыр шулай ук йөрәк яшен?!

Сагышлымын ләкин: җанның бар моңы –
Табигый, бик татлы ул – яшь яр моңы!
Гаебем синең алда шул: олыгаю...
Кайсы урманга озатыйм «аю»ны?

Көләдер күк миннән җир, күрәдер күк,
Тиңме сиңа яшь йолдыз, диядер күк...
Яшәргә ашкынган, сөяргә ашыккан
Гомер инде «ялгыш»ын сизәдер күк...

Гаебем шул: яшь матурны күргәнмен,
Чал башны игәнмен аңа – сөйгәнмен...
Бәс, иелә, хәтта тезләнә алгач,
Каткан карт агач та түгел икәнмен!

Әллә җанны юкка кыйныйм микән мин?!

* * *

Ник шулкадәр уйлыйм мин синең хакта?
Уйларымнан исереп елыйм хәтта!
Җаннан таша моңнар, җырлар агыла,
Иң бәхетле җирдә миндер шул чакта!

Мин шулкадәр еш уйлыйм синең хакта!
Ходайдан, дим, син бүләктер хәятка.
Мондый бәхеткә ни өчен лаек мин? –
Гашыйкларга вәзир дә түгел хәтта...

Мин шулкадәр саф уйлыйм синең хакта!
Шул сафлыкны дөньяда тоям хәтта.
Тик матурлык күрәм аның эчендә.
Карасы бардыр – табынам тик акка!

Мин шулкадәр уйлыймын синең хакта,
Килерсең күк син дә минем халәткә...
Шул халәт өчен мин үләргә риза, тик
Мәңге яшәргә телим синең хакка!

Йә, үзең соң ни әйтерсең бу хакта?!

* * *

Кайт тагын да шигыремә май кичендә, –
Вагыйфны яттан сөйләвең исемдә.
«Күпләрне оныттым бугай», – дисең дә,
Яшисең син төрки моңнар өчен дә...
Кайт яңа шигыремә май кичендә!

Сагынып сине, лаләләр күз ача,
Казанда нәркисләр хәлеңне сораша.
Яшел яз! Йөрәкләр серләшә, очрашса,
Карт күңел гөле дә үрелә кояшка.
Кайт, сине сагынган гөлләр күз ача...

Булса да уеңда диңгез, фонтаннар...
Ак шомыртлар илдә, түгел анарлар.
Саф татарча яңгырап, аһәңсазлар,
Гашыйк җырын сиңа җиткерсен алар,
Ә Казанда сагыну хисен – фонтаннар.

Килде чәчәк ату вакыты кешегә! –
Суытса да кинәт, күңел төшермә,
Кырау төшермә тик бәхет хисеңә!
Җилгә әйт, кагылса ут-чәчеңә,
Исен китерсен сагынган кешеңә!

Кайт Казанга – шигыремә! – май кичендә,
Вагыйфка гашыйк итәрсең мине дә,
Йөрик шигъри лаләләр, моң эчендә,
Тугры булып төрки дөнья хисенә,
Казанымда – гаҗәеп май кичендә!

* * *

Гүя айнып китте җырым:
Кем әле илһамчысы?
Багышланды кемгә җанда
Яшемнең соң тамчысы?
Тәкәббер салкын ярнымы ул
Аңлар дип җан ышанган?
Сәгыйть Рәми «Җәмилә»се...

Шәүләсенә охшаган
Гүзәл тән...
Шуңамы озак
Табынганмын, бакканмын?
Күккә ашып, илһам көтеп,
Гакылымнанмы шашканмын?
Тәңрем, ярамыйдыр ул Кызга,
Илаһ санап, баш ию.
Потка табыну – бер гөнаһ,
Бөек языктыр – сөю!
Шул юлга багышланган җан, –
Рух түгел, хис ялчысы
Түгелме мин? Бәлки, рәшә –
Алдап тарткан яктысы?
Гүя, айнып, уйлыйм: болай
Яшәвем, бәлки, оят?
Хыял – тик чынлыктан шәүлә,
Сөю дә алдану мәллә?!
Соң кабат, дөнья, уят!

**СИНЕҢ БҮЛӘГЕҢ – ЛӘЙЛӘ СУРӘТЕНӘ**

Ләйлә сурәтен бар кылды яр кулы! –
Шуның белән фәкыйрь җанны хан кылды.
Рәсемдә тиңе юк гүзәл... Ходаем!
Ни әйтәсең, яр, син Ләйлә аркылы?

Алдында гөлләр, җан өргән кем тыны?
Кулында саз – алтынмы аның кылы?
Сихри көеннән тын калган табигать, –
Кайда дәшәсең, яр, шул моң аркылы?

Кичке кояш алсулый сахра-кырны,
Чиксезлек бу, юк башы һәм ахыры...
«Дөнья, яшәү, сөю – бөек, илаһи!» –
Дисеңме, яр, миңа сурәт аркылы?

Мәңгелеккә юл суздыңмы, яр кулы?!

* * *

Нинди сер соң бу юлларда? Уйланам...
Ни кагыла күңел-кылга? Моңланам.

Җирдә юкса аз мәллә үкенечләр –
Өндә дә һәм төштә дә шундый хисләр!

Сөюең белән хушлашу яшь көе...
Яшьлек белән саубуллашу, яшь коеп...

Чынга ашмый сүнә җанда хыяллар,
Чәчәк аталмый, өметләр сулалар.

Әверелсә гомереӊ гамь үзәгенә,
Фаҗигаләр күчә җыр йөрәгенә!

Иҗат бәхете дип тә сөйлиләр, имеш.
Ә бит бәгырьдән өзелә һәр җимеш!

* * *

Ни әйтим мин?
Беләм, Җирдә үз юлың...
Әзер, димен,
Сиңа җылы сүз, кулым...
Таяныч ул! –
Юл башланмый хуплаусыз.
«Бәхетле бул!» –
Дип кабатлыйм туктаусыз.
Биеклеккә
Ашканыңны күрсәмче!
Беркөн күккә
Сәер кошым күчкәнче...
Әйт, кая дип
Рух канатың җилкенә?!
Моратка бит
Ирешү – хак иркендә...
Тугры һаман
Сиңа догам – каләм, сүз...
Шулай калам,
Ихлас җанга таян, Кыз!

* * *

Кызлар, быел һәммәгез ут чәчлеме?
Сары көнбагыш сез – кояш чәчтеме

Йөз-чәһрәгез тирәли ул төсләрне?
Яшьлек алтынымы назлый күзләрне?

Ничәгезне мин, тик Аңа охшатып,
Күбәләктәй якын бардым, җан атып.

Ничә күлмәк иясен (аллы-гөлле!)
«Танып», утка очып килдем мин – тиле...

Ялгыштым шул! Кызлар, тере ялкын сез,
Гүя игезәктәй охшаш-матурсыз...

Алдансам да, ярыма әйтер сүзне,
Серне чишмәдем, – саклады Хак сүзе...

Әмма бу яз хистә төсләр буталды.
Шуны беләм: Казанымны ут алды.

Гүя ялкын эченнән эзлим сине –
Алтын балкышны, көнбагыш төслемне.

* * *

Садәлегем куркытамы,
Әллә соң шашкын хисем?
Алдыңда илле кыш күргән
Башым иелгән өчен,
Ут-языңа килгәнемне
«Бу – сәер, сәер» димсең?..

Ерактыр чынлыктан, дисең,
Белеп бетмидер барсын...

Аһ, ул «белү»!
Читенме, йә,
Күзаллау «чаршау арты»н?!
Кыенмы аңлау гөнаһның
Уй җитмәс тирәнлеген?
Кешедә җан хыянәте
Бөек тән гүзәллеген
Гүя, күкләргә үч итеп,
Иблискә биргәнлеген?
...Җырга биеклек шул түбән
Хистән дә килгәнлеген?

Теләкләрнең чиге юкны,
Мәкер, үч үлмәгәнне,
Намусны нәфес нишләтә –
Бик күпләр белмәгәнне
Аңламыймыни Гаташың?!
Кеше
үзгәрмәгәнне?!
Ә үзе гүя пакьләнү –
Яңадан туу өчен
Иелгән синең алдыңа,
Саклаган сабый хисен...

Син шуны «сәер» димсең?!
* * *

И милли яр! Сиңа Хактан
Түземлек теләп язам.
Тарихи зур рухи йөкне
Илтәсең кебек һаман.
Нәни, хәлсез бер йөрәккә
Ник шундый язмыш язган?

Ник аңа тия үткәннең,
Бүгенгенең ялкыны?
Гүя Төркинең, Татарның
Бар тарихы, дау юлы
Уза хисең аркылы.
Җаныңда – зилзилә, күздә –
Яшькелт моң диңгезе лә...
Әллә милләт фатихасын,
Ят кавемнәр бәддогасын
Алгансың берүзеңә?
...Яңарып ватан, кайтыр бит
Халкым кабат үзенә?!
Бүген гөл түгел, ил көле
Күкрәгеңдә, кыз бала!
Күкләр – битараф, ә җирдә
Татарны кем кызгана?!

Сакла, сөю!
Фаҗигале
Бөек юлны узганда!

* * *

Тик бер сүз... аh, авыр кагылды:
Йөрәк кара шәлен ябынды.

*Ч.З.*

Кабат-кабат сорыйм йөрәк хәлеңне:
«Син алдыңмы аннан кара шәлеңне?!»

Һаман уйлыйм: яшь бер хискә ник матәм?
Ул килешми сиңа –
чынын мин әйтәм...
Ал ул шәлне – кара төстән ерак йөр...
Синдә керсез, йолдыз затлы йөрәк, бел...

Биеккә ул ашсын, тиңсез нур булып,
Сөя белмәгәннәр калсын хур булып...

Бөек горурлыгын Кызның балкыштан
Таныганнар көнләшсен ак язмыштан!

Кош юлына күтәр якты хисеңне,
Мин гел шуннан эзләргә әзер сине!

...Һәм күрсәң сәҗдәгә егылган мәлемне,
Алдыма җәй соң шул кара шәлеңне!

## СӘЯХӘТТӘН ЭКСПРОМТЛАР

### I

Нинди булыр язмыш алда?
Сорыйк дулкыннардан.
– Мине борчымый бу, – дисең.
Җилләр әйтә:
– Ял-га-а-н!

Җанда
Үткәннәрдән безнең
Күпме гамь-моң калган.
– Миндә юк... – дигән сүзеңне
Яңгыр юсын:
– Ял-га-а-н!

Хис Иделдәй ташкан бүген,
Ә иртәгә? Аннан?
– Миңа барыбер, – дисәң, күк
Күкрәр озак:
– Ял-га-а-н!

...Иделдән Чулманга кердек,
Көн ачылмый һаман.

### II

Уйлыйсыңмы: йөзәбез дип бүген
Без Чулман өстендә?
Йөрәкләр ул шулай мәңгелектә –
Тыныч кына аккан бер халәттән
Ярсуга күчендә.

Күр, сөйләшә сәях ике йолдыз
Чиксезлек эчендә.

Безнең йөрәкләр ул балкый бүген
Төнге җир өстендә –
Мәңгелек эчендә...

* * *

Озак янып көйдем, әмма түздем,
Сөйдем, хәзер миндә шундый җан:
Сыйган гүя аңа Илаһ үзе,
Кар түбәле мәгърур тау сыйган!

*Ч.З.*

Ник җаныңа үталмый җан – аңладым:
Текә тавың – менеп җитә алмадым...

Салкын биеклек – кыялар илаһы;
Ни аңа наз, йөрәк эндәше, аһы?!

Элек, янартау булып, ут аткан да
Катып калган шомлы ташлар ул тауда...

Кар аклыгы кисә гашыйклар күзен, –
Биеклектә юк хәтта кошлар эзе.

Шулай икән, ник хыял анда оча?
Сөю эзләпме боз тауны уй коча?!

Зәңгәр кыялар – язмышым, аңладым:
Җитә алмамдыр... һәм китә дә алмамын!

* * *

Сөен: хәзер син бар – хуҗа рухыма,
Һәр гөнаһтан өстен язмышым шуңа.

*Ч.З.*

...Ә нинди көч хуҗа минем җаныма?
Һәр ике дөньяда булыр ядымда.

Ничә дистә денсез-имансыз еллар
Мең гасырлык пакь диннән аердылар!

Әмма илаһ иттек без туган телне,
Газиз кавем, җандагы ватан-илне...

Шулай бугай үзебезне сакладык,
Җанны бөтенләй гөнаһка атмадык!

Фәрештәдәй ак калдым дип әйтәлмим,
Саклады тик пакь күңеле әнкәмнең...

Һәм яр итте илһам милләт баласын,
Хәзер дә, рух, шуңа тугры каласың!

...Ярның бар үз рух хуҗасы, дөньясы...
Тик үзгәрмәс аңа Гаташ догасы!

# *II. Моңсу матурлык*

***(1996—1998)***

* * *

Яшьлеккә хас саф, гөнаһсыз хәйләләр
Әнкәң биргән олуг акыл мәллә, Яр?

Серең – яшерен, биктә, яраттырсаң да,
Читкә тибәрмисең, ерак торсаң да.

Күзеңдә шаян ут катнаш җылы наз,
Сүзең күркәм, бар чаялык та бераз...

Сурәтеңне шулай тасвир кылмышым...
Үзең күптән җанга оя кормышың...

Шуны раслар бу шигырем язылсынга–
Очрашканбыз дөньяның яхшысында.

Күктә, бәлки, кирәк булмас хәйләләр?!
Җирдә җанны сер-мөһергә бәйлә, Яр!

**ГӨНАҺ-УТ**

**I**

Күңелеңнең болганмас, бел, болагы,
Хисеңнең бик сак күзе һәм колагы;

Язык бер эш кермәс һәм сүз – яраусыз...
(Фәрештәләр! Бу – изге, дип язарсыз!)

Ул гөнаһтан өстен, биек калачак.
Шундый күреп, сине күкләр алачак!

**II**

Җир кызы син – җирдән аеры тән булмас!
Тузанланыр – кайсы тәнгә кер кунмас?!

Чуар, кара җирдә үзең туфрак син.
(Яшәештә күктән шактый ерак син!)

Каралтса да мохит, рух, җан пакьлеге
Булыр сиңа азак – йөзең аклыгы!

Әһле оҗмах, шиксез, хәйран калачак,
Бер җаныңа җиде дөнья багачак!

**III**

Үткәннәрдән нинди җаныңда эзләр?
Кабатлана ни гамь, ядыңда сүзләр?!

Кан фетнәсе, дәрт үче булгандыр бит?
Гөнаһлы уй явы кагылгандыр бит?

Һәммәбезгә олуг сынау узасы...
Сират аша кичерер кем догасы?
Кемнең яше, яклап, Хакка барачак?
Тик пакьләнгәч җан, аны күк алачак!

**IV**

Вәсвәсәле теләк, шәһвәт иблисе!
Кит ул Ярдан, ак күңел ул, гөл исле...

Ул сафлыкта сиңа табылмас урын,
Кит яныннан, хурлыкка калмас борын.

Йә күрсәтеп шөһрәттән тәти аңа,
Кызыктырма, пакь рух белән уйнама.

Бел, ялганнан чын динне аерачак,
Раббысына тугры юлдан барачак!

**V**

Каршылыклы бу уйларның тезгенен
Тоталмыйча, гаҗиз Гаташ-мескенең

Сине уйлый: аргач, тәнең-җаныңны
Гөлсабыйлык сагындырыр чагыңны,

Үз халәтенә охшаш дип, үз тиңе.
Елап, хыял эзләр җирдә генә сине...

Әле гөнаһ-утта ул күп яначак!
...Ә күктә аны син аклап калачак!

* * *

Син язмышым мәллә, моңсу матурлык?
Гомерем синең юлда – кире кайту юк.

«Яр» дигәннең яралы йөрәгенә
Дәва эзләп, сүз кушам көннәремә.

Моң иясен терелтер рух табучы
Табиб бугай мин – бөек юатучы!

Юлыктым да җәрәхәтле җаннарга,
Яндым-көйдем, дару эзләп аларга...

Ә үз җаным дәвасын – наз чарасын
Кемнәр белде? Күрде кемнәр ярасын?

Сөю! дип, бу мәңгелек омтылышым
Юкка, бәлки? Кем бәһаләр очышым?

Бүген менә мин синең мәхәббәтнең
Зарын тыңлыйм – илаһи хикәятен.

Күк күзләрдә җанны өзәр матурлык...
Бармы көчем яшь моңны юатырлык?!

* * *

Пакь яшьлегең саклый алса ялгыштан,
Сакласын шагыйрь яшеннән – каргыштан.

Гомереңә җитәр, төшсә рәнҗеше –
Язмышыңда эз булыр, тап рәвешле...

Чөнки ихлас шагыйрь җаныннан аһлар –
Тәңресенә, шиксез, ирешер хатлар!

Шундый дога Кандалый хәзрәт кылды:
Ярга ялварганы – чын каргыш булды.

Гыйбрәт өчен калдырды яманатын!
...Юк, шагыйрьләр, фаш итмәгез яр атын.

Бары сезне яклый-аклый гасырлар!
...Сөймәсәләр, гаепләме матурлар?!

Сөйсә, алар – чын «фәрештә валчыгы»,
«Гөнаһлы» ярның да сез бит гашыйгы...

Аһ, саклый күр күңелеңне шул каргыштан,
Мәңгелек үзе таш атар язмыштан!

**ШӨН ДАСТАНЫ**

*(Цикл)*

* * *

Кем әйтте соң, ул, дип, Төньяк – төн кызы?
Шөн кызы син (бәлки, Сөндер?!) – көн кызы!

Сөн-һун, кыпчак көнбатышка узганда,
Сезнең илгә Төрки тәңре нур сызды.

Ул Нуръяктыр – Нократ ягы, гөл иле,
Шул төбәктән эзлим яшерен йолдызны!

Син – илеңдә, сине сагынып, Иделдә
Эзләреңне эзли Гаташ – җыр сузды.

Мең еллардан, бәлки, сиңа сәлам бу!
(Синнән көтәм сөн дастанын, Шөн кызы!)

* * *

Тәнеңнән яз тоташып минем тәнгә
Җаныңнан наз сарылды бүген җанга.

Күк һәм Җирнең «Амин!» дигән сәгате!
Мәңгелекнең илаһи сәгадәте...

Тик табынганга тәнеңә (мең кабат!),
Җаның белдерсә дәгъва бер, шикаять?

Икесе дә калдырмады битараф:
Җан, тән тәңгәл, камил синдә бар тараф!

Аңлатырга табалмыйм бер матур сүз,

Телем бәйле – бәхетем итте һушсыз!
* * *

Хисләремне чылаттым гөл чыгында,
Назга мохтаҗ ир башым яшь хозурында.

Бакчаңда ут янган чәчәк – түзмәдем,
Шашып үбәр өчен аны, тезләндем...

Яшәртсен, дим, җанны таңда гөл суы,
Яшәсен Көмеш-су иле сылуы!

Сүрелмәсен бу наз – Ут-Яз сүнмәсен,
Сөеп белдергән хис бушка булмасын!

Хәлсез гашыйк – баш куйдым тезләреңә,
Утлы чәчәк шәүләсе – күзләремдә...

* * *

Сезнең үзәннәрдә ул кич адаштым.
Юл күрсәтте, кем диген – бер адашың.

Йолдыз атлы, Зөһрә йөзле үзе дә –
Сердәш булды уй-хискә авылдашың.

Шул яшь йолдыздан гел сине сорашты
Сахра гизеп арган хыялый башым.

Аннан җанга тынычлык алдым гүя,
Күгегездән яңа йолдызлар ачтым.

Үзен күреп сөйләштем гүя, рухта
Адашмадым, нурда җаныңа аштым!
* * *

Мин – яратырга яралган бер гашыйк!
Яр гамендә чыккач хис ярдан ашып,

Ташып, бер көч (силме?) сиңа китерде,
Гүзәллеккә тезләндерде шикелле.

Кызгандымы яшьлегең, яз сулышы
Назлады, һушка килергә булышты.

Гөлләр исе килгән ут-учагыңда
Өр-яңадан яшәрдем шул чагында.

Туңган канны җылытты юрган-чәчең,
Ачы-татлы чын шәраб иттең яшем!

Тик яр булырга яралган буй кызга
Мөкиббән җаным һаман җамын суза!

* * *

Ник кабатлап: «Сөбханалла!» – димәдем?
Күз тидергәнмен бит – шуны сизмәдем...

Ярамый шул яндырырлык соклану!
Ут көче бар караштa да – белмәдем...

Тынычланган күңел, бәлки, һәрдаим
Үзе саклар дип Хак – үзе биргәнен...

Кара көчләр, көнчел күзләр күп җирдә,
Күрмәсен шулар гүзәллек сүнгәнен.
Юк, бу сырхау – түгел кырау (яз ласа!)
Китәр, ишетеп ул дога сүзләрен.

...Мең кабатла, Гаташ, «Сөбханалла»ны –
Чын әдәпкә чакыр – гашыйк күзләрең!

* * *

Без – Кучкарлар! Исемебездә үк көч бар.
Язмышка бер үҗәт караш, сүз, үч бар.

Тәкъдир язган нидер – чыксам шул юлдан,
Һәлакәттән, и Яр, бу җанны коткар!

Күр, чыгалмас кара төн бу карашың!
Чынлап тамы яшьлектә куркыныч бар?

Мин канатлы идем; син дә хыяллы,
Чиксезлектә юлдаш булыйк – очып бар...

Тик Көмеш-Су, гөл, матурлык илендә
Җирдә бер эз калдырыйк ике Кучкар.

* * *

Сездә – Нократ күген ябынган төнем!
Авылыгызда – сине сагынган төнем!

Әллә күңел, әллә күкләр чатнады –
Яңгыр койды – чыланган, туңган төнем!

Давыл ачты тәрәзләрне, шом керде...
Шигырь түгел, дога укынган төнем!
Ят иттеме әллә авылыгыз мине? –
Авыр уйлар, сезгә сыенган төнем!

Йә, ни әйтер авылың, укыгач моны?
Сездә – синсез хыялый булган төнем!

* * *

Улмы? – Ул... кагылган булыр утка ут,

Ике Кучкар калгач бергә тукталып.

Һәм кабынган нидер шушы мизгелдә, –
Кызу янар ике җанны ут алып...

Яшь Кучкарга тик чал Кучкар багамы?
Дөнья үзе карый сөеп, сокланып.

Нык баса бит җиргә көмеш яшь тояк,
Алтын таҗы куя күккә ukталып...

Ә мин Тәңремә эндәшәм: «Сүндермә!
Ни калыр миннән, бетсә бу ут янып?»

* * *

«Дагын», «дәген» аша белдем
Сезнең төбәк сөйләшен.
Ә күзеңдә – үзгә шивә:
Хис телендә эндәштең.

Утлы карашлар илендә
Сәердер сагышларым.
Моңсумын, – сөю фәненә
Гомерне багышладым.
Ачты, бел, бүген яшьлегең
Ул фәннең яңа язын.
Шивәсе дә тетрәндерә
Борынгы, милли назның!

Татарча матурлыкның соң
Кем аермас сөйләшен?
Ә син ишеттеңме, йолдыз?
Җан иленнән эндәштем,
Җыр телендә сөйләштем!

* * *

Өйрәт: ничек көнләшмәскә ярыңнан?
Урын алган күптән синең җаныңнан...

Хуҗа булган хәтта... синең тәнеңә
(Нинди корбан китергән соң Тәңрегә?).

Аңлый микән бәһасен шул мөлкәтнең?
Исраф итсә байлыгын чын дәүләтнең?

Җиңел килсә, бәхет кадрен кем белер?
...Гамь, моң белән яр сөймәсә, ирме ир?

Ярың – шаһтыр: таҗ кидергән яшьлеге,
Буйсындырган җаның егет шәплеге.

Ә бездәйләр, сүздән үрсә дә гөлтаҗ,
Көч-дәрманда яшькә ул көндәш булмас!

Тик... тәвәккәл: курыкмый шул ярыңнан,
Урын даулый бүген синең җаныңнан.

Кәгъбә саный ул гөнаһлы тәнеңне.
Кем диярсең, йә, шул сәер шагыйрьне?
* * *
Сыенсаң да бүген минем йөрәккә,
Сизәм: читтә миннән уең, еракта...

Уятса да ут-иреннәр канымны,
Беләм, яшькә – чын ялкыны җаныңның!

Шашкын хистән, аңлыйм бит, зәүкың арган,
Шәүләм аша ул читкә карый һаман.

Омтыласың, сизәм, аның янына.
(Миннән көлеп сөйләрсеңме ярыңа?)

«Камчысыннан бал тамар», ул яратса,
Гаҗәпмени тиңең сине каратса?

...Башым кочкан кулларыңда тере наз!
Тоям ләкин: түгел миңа синең яз!

* * *

Көн-йөзеңне капласа төн, Болытчәч?
Ку ул төнне, таралсын шул болыт, дәш!

Кил, Болытчәч, мин күмелим ул төнгә.
Чыгачакмын таңга көчле булып, яшь.

Йә яшерсен чәчең читләр күзеннән,
Хис эчендә без дөньяны оныткач.

Сал чәчеңнән юл, әйт: безне ни көтә?
Алда ниләр? Күрмим, күзгә тулып яшь.

Аяз гомерем кичендә гашыйк шәүләм
Чәбәләнсен яшь ятьмәңдә, Болытчәч!
* * *
Гашыйк Гаташ, җаныңа яшь яр остаз;
Ашык син, бел, бу фән өчен вактың аз!

Тезләренә омтыл еш баш куярга,
Аерылышуны сизеп, яшь коярга.

Күпсенер, дим, көнләшер бездән дөнья;
Озак тотмас, аһ, гөл исле куеныңда.

Арага керерләр тиздән, сизәм мин.
Күзләреңдә тагын күпме йөзәрмен?

Гашыйк Гаташ, яшәрт күңелеңне бераз,
Озаккамы сиңа ул чәчләр остаз?

* * *

Борынгы җыр, әллә сиңа кайтасы,

Әллә өр-яңа сүз эзләп табасы?
– Апасыннан матур микән сеңлесе?
Сеңлесеннән матур мәллә апасы?

Гел шул җырга, күңелем, әгәр кайтсаң син,
Ике матурның, әйт, кайсы тарта соң?
...Сер яшергән сихри караш иясе,
Исерткеч чәч исе, кайсы яктан син?!

Чишмә башын эзләп хисләр кайтмасмы?
Әмма яшьлек көлеп каршыламасмы?
«Бу гөлләрем сиңа...» дисә сеңлесе,
«Акылыңа кил...» димәс микән апасы?

Борынгы җыр, килә сиңа кайтасы...
* * *

Мин алданрак китәрмендер тегендә;
Милли ярлар, сез булырсыз телемдә!

– Без китәбез, – диярмен, – сез – каласы.
Яңа гасырны иңләп сез барасы.

Кайсыгыз соң аннан сагынып дәшәр
(Исемем үк онытмас, димен, яшьләр):

– Кабатланмас гашыйк Гаташ бар иде.
Сөелүне уйламый да яр сөйде...

Багышлыйкчы аңа бер яшьлек хисен,
Җан касәбез тулсын бер аның өчен!

Кемнең шулай тибрәлермен телендә?
Урын аңа, шиксез, оҗмах түрендә!

...Бәлки, әйтерсез исәндә – бүген дә?

* * *

– К-и-и-и-л! – димен.
Сабырым бетте,
Нишләргә дә белмимен.

– С-ө-ө-ө-й! – димен.
Соңгы бәхетем,
Ак биләүгә билимен...

– К-а-а-а-л! – димен.
Үз сагышым,
Берәүгә дә бирмимен.

– Я-а-а-а-р! – димен.
Мәгънәле ит,
Моңлы ит гомер көзен...

– К-и-и-и-л! – димен.
Исмеңдә – яз,
Исмеңдә – наз, гөл синең.

Кем өчен тик?! –
Белмимен...

* * *

Мин, ахрысы, өметемнең чигендә.
Диңгезгә багам – соңгы яр читендә.

Еларгамы бу халәт бик читенгә?
Уйларгамы – дөньясы ят, чит өн лә!

Гаепледер үзем – хисләр чиксезгә...
(Куелыр, дим, булып фәрман, чик сезгә!)

Әле дулкын килсә шашып, чигенә...
А, син, сөю, ачы бүген,чит миңа!

Соңгы кабыну ул үч мәллә?!
Үч кемгә?!
...һичкемгә!

Моңлану бу ялгыз хыял читенгә:
Җан гүяки бүген хәят чигендә!

* * *

Иреннәрем тияр-тимәс касәңә,
Бер йотым тик, Гөл, авыз иттерсәнә?

Мәңгелек бу януым, дим, басылыр,
Чын ләззәткә капу җирдә ачылыр...

Су буенда суга сусыйм... Гаҗәпме?
Әллә үзем уйлап тапкан газапмы?

Ник татлы ул? Көчәя ләса уты...
Хисем юкса дәрьяларга юлыкты.

Җанда, бәлкем, инде нидер сүрелде?
...Ник ул бүген яшь шәрабка үрелде?

Тиеп утлы иреннәрем касәңә,
Кайнап очмасмы җан дөньям, әйтсәнә?!

* * *

Назларымнан качтың һаман, дидең: – Аһ,
Ярамый бит... Кит, аңлыймсың, бу – гөнаһ...

Читкә кудың гел кабаланган кулны,
Иреннәргә дә адаштырдың юлны.

Аннан үзең үк сыендың кочакка...
(Күзләрең тулган күл иде шул чакта!)

Тагын нидәндер куркып син сискәндең:
– Нишлибез без... Бу гөнаһ бит, и Тәңрем!

...Ихтыярсыз бактым да күк-һавага:
– Языкмыни, – дидем, – пакь хисем ярга?
Йөзем каралт, әгәр булса бу гөнаһ!

...Күзең – көзге. Яна битем... Йөзем ак!

* * *

Бөдрә яшь тал, нидән уйга талгансың?
Агымсудан ни карыйсың, бала, син?

Ышанмыйсың, бәлки, егылмасыңа,
Шунда бер җил һаман кагылса сиңа?

Узгынчы ул, шомарган алдакчы ул,
Иректе дип сөюдә – атаклы ул!

Чәчләрең сыйпар, назлар ул, мөгаен...
Дәртле көйләр чыгарыр, искән саен.

Ышанма җил сәнгатенә, алданма,
Инеш-ярдан аерылма, тамырың анда!

Җил тиз китәр – күп илдә бөдрә ярлар...
Минем кебек юатыр әнкә таллар!

# *III. Кальбеңә хис юлласам*
***(1998–1999)***

### ЛУИЗАЛАР ӨЧЕН ГЕНӘ... ТҮГЕЛ

Шул шигырьгә күзем төште кинәт:
«Тар күкрәккә бар галәмне төяп,
Туар берәү Туфан шикелле.
Һич шигем юк: Хәсәннәре туар,
Луизалар туу – икеле...»*

Йөрәктә – ут...
      Ник яклыйсым килде
Татарча да түгел исемне?

– Лу-и-за-за! – дип өзгәләнде
            Туфан...
Мин дә шулай табынып,
            җыр язсам,
Ләкин...
«Юлыкмасам шундый бер чәчәккә»,
Адресатка – яшькә ят калсам?

Нинди соң син, бүгенгенең Луы?
Нинди гөле «ахырзаман»ның?
Аңлаучысы?
      Алдаучысымы соң
Синең
Аяк аска җырын салганның?

Аһ, чәчләрең! Дулкын-шарлавыклар...
«Юрган булсын»

жаның сөйгәнгә!
Шулай дигән Кандалыйдай шашкан –
Гүзәлеккә баккан күзләремне
Сез ябарсыз, бәлки, сүнгәндә...

Сез, дим, Лулар... чын татарча сылулар –
Йолдызлары шигырь-гомернең...
Мин ышанам һаман милли Ярга,
Шуңа тагын иман китердем...

Шик белдерсә кемдер:
– Бүген тугры
Луизалар туу – икеле... –
Елар җанда идеал кыз сурәте...
Лу!
«Ул һәр яктан синең шикелле!»

* * *

Безнең ил –
Сандугач сайрар җир...

*(Керәшен халык җырыннан)*

Дөнья гиздем... Эзләндемме,
Булды мәллә җан чуар?
...Ни таптым синең туфракта,
Ник тезләндем, Янсуар?

Сувар йә Бүләрдән өнме?
Дәшәме Олуг Болгар?
Идел-йорт, илем йөрәген
Кемгә ачтың, Янсуар?

Илаһи кыл – борынгы ул,
Кем ялгар да кем уйнар?
Бирде бу сазны буй кызга
Моң-әнкәме, Янсуар?

Исәндә иске моң җирдә
Изге канны җан тояр.
Төрки сут – мөкатдәс ул сөт
Дәвам итәр, Янсуар!

Тетрәнеп мин салдым колак:
Мәңгелек моң. Кем туяр?!
«Сандугач сайрар җир»дә ул –
Илаһи җыр, Янсуар!

Агыла моң! Кем тыяр?!

* * *

Бу чәчәк балигъ түгел, бел,
Әле ул – бөре чәчәк.
Сак кагыл: күңел көченә –
Хисеңә түзмәячәк.
Бу чәчәк – сабый чәчәк!

Ул – гонҗә: таҗы-касәсе

Әле сер – яшерен чәчәк.
Тиздән бу илаһи мөһер
Ал гөлгә әвереләчәк.

...Әкрен, каләм, ишетә галәм:
Сүзеңнән күз тиячәк.
Гөнаһлардан тыш чәчәк ул,
Саф – чәчәкләргә чәчәк!

Ә үзе, аңа битараф
Калсаң да, рәнҗиячәк;
Гүзәллек шундый: күрми уз,
Мәңге кичермәячәк.
(Телләрен, бәлки, белмибез?
Күзләре: – Мине күрегез,
Яратыгыз!.. – диячәк...)

Нинди булыр, Гөл, бәхетең?
Син – тиңсез Вәгъдә илендә
Әлегә сабый-чәчәк!

* * *

Көтәсеңме янганымны,
Ут сулап... язганымны?

...Җилләп-давыллап йөргәч, бер
Яшенләп яуганымны
Күрергә җаның телидер!
Карашларыңны аңлыйм.
Рөхсәтме, башта үзеңнән –
Яшьлектән көчләр алыйм?

Тылсымлы шундый сүз чишмәң,
Тыңлыйм да сафланыйм бер;
Онытыйм гасырым шавын,
Киләчәккә багыйм бер.

Яздым күп яшереп Ходайдан (!)
Гөнаһлар, уйларымны,
Ялганнарга күнгәнемне,
Пакьлекне җуйганымны...
Яшереп чын вә сафлыкны
Эзләүдән туктавымны...
Ялгыш Иблискә биргәнне
Чын фәрештә Ярымны...

Оялыйм әле үземнән
Карыйм да раушан көзгедән,
Күзләреңнән
Укыйм да яшь җаныңны!

* * *

Гүя ләлә йөзеңдә тап-миңеңне
«Сөю мөһере» итеп Ходай бирдеме?
Ташкын чәчләр япкан ап-ак муеныңны –
Хава тәне дә шундый пакь идеме?!

Лаләгә тиң йөзеңдә йолдыз-миңне
Күреп, күккә ашкан – шашкан тик минме?
Күпме яшь Адәм чын сурәт-сүз эзләп,
Кичте дөньядан – тапмаган өченме?!

Яшь Лалә-Яр сере – табышмак тап-миң!
Уза гомерем... мин дә бер җавап тапмыйм...
Эзләүләрдә элгәрләрдән уздырдым,
Миңъяр дип, ник алмыйм тәхәллүс-ат мин?

Шуңа, бәлки, моң бар миңле йөзеңдә!
Якты моң катыш чал Гаташ сүзе дә.
Лалә йөзең, миңең, күзләрең үптем;
Гөл исле җырлар калсайде эземдә!

## БОРЫНГЫ ҖЫРЛАРГА ВАРИАЦИЯЛӘР

* * *

«Суда балык йөзәдер, шул...»
(Сандугач, ни сайравың?
Шулай кемне сайлавың?)

«Су салкынын сизәдер, һай...»
(Сандугач, дим, сайравың! –
Әллә җырыңда җаның?!)

«Авылыбызда бер чибәр бар...» –
Дип кемне мактый ярым?
(Сандугач, шул сайравың...)

«Керәшен халкы»н җырлары өчен
Җаныма яр санадым!
(Сандугач, дим, сайравың!)

Шундый татарча моңлы көй
Уятмасмы ил җанын?!
(Сандугач, сайра тагын!)

* * *

Сезнең тирәдә... козгыннар очадыр,
Безнең илләрдә йөрмәскә кушадыр.
Ак күгәрченемне күрмим күптәннән,
Су читендә суга сусап үртәләм.

Ага чишмә – дәрте күпкә җыры күп;
Шунда, йөрәк, күз яше итеп моңың түк!
Хисемнән, күкрәп дөньяга, очындым,
Сизмәдем: кошым кулымнан очырдым.

Урамнарга сыймый ялгыз җан җыры –
Урманнарны урый, төннән ял сорый...
Ак бәхетемне, аһ, ятлардан алдырдым.
Хәсрәт-утта гомеремне яндырыйм...

Сөю күгендә козгыннар очраса,
Юлын кисәр карчыгаң бар лабаса?
Алдырмагыз, кыюлар, кулдан ярны,
Аермагыз ак күгәрченнән җанны!

* * *

*(Синең җавап җырың)*

Ә сезнең соң күңелдә нинди кошлар?
Өй коргандыр ул «күл»гә аккошлар?
Каңгылдап, яңгырап килә тавышлар!

Сезнең илләрдә тик аккош моңыдыр,
Башка кошларны онытkансыз булыр.

Оегансыздыр тере шул аклыкка.
Белегез, көнләвем түгел аккоштан.
Җаныма тансык – талпына сафлыкка!

Берүк ак җан хәтерен калдырмагыз,
Каралмасын – сез күздән яздырмагыз!

Юлыкмасын пакьлек көнчел көчләргә,
Рәнҗеше төшмәсен күңел-күлләргә,
Ихлас дога белән багам сезләргә.

Илегезгә юл ник ачылмый һаман
Аккош мамыгыдай ап-ак бураннан?!

## ҖЫР ЭЗЕННӘН

Агыйделнең аръягында болыт тора.
Яңа ярлар иске ярны оныттыра.

*Борынгы җыру*

Агыйделдә таралгандыр инде болыт? –
«Яңа яр» дип, имеш, «иске яр»ны оныт...

Бездә әле көннәр аяз, матур тора.
Кемнәр кемне оныттырыр? Сагындыра...

«Ике күздән яшь китерә» кайсы ярың?
«Табак белән аш китерә» – сыйлый җаның?

Кемгә синдә хәйләң «...ефәктән дә нечкә»?
Нигә бу җыр якын шулай бүген хискә?

...Кул изим дә аръяктагы болытларга,
Күпер сузыйм «иске яр»дан «яңа яр»га!

Мин аларны килештерер сүзләр табыйм...
Заманнарны заманнарга ничек ялгыйм?

...Гыйбрәтле җыр... ә мин менә оныта алмыйм!

* * *

Алып бирим, җаныем, ак сабын:
Иртә сагынмасаң, кич сагын...

*Халык җыры*

Иртәләрдә уйлыйм,
кичләремдә сагынам;
Куркам йөземә моңнар сарылудан.
Җан гынам, –
Иртән дә, кичен дә сагынам.

Битләремне юам таңнан торып,
Алсулансын шул ак сабыныңнан.
Сагынам, –
Язмышыма исемең язылган.

Иртән син уемда,
кичен күз алдымда:
Сурәтең бармы җаннарым эчендә?
Сагынам, –
Көне-төне сиңа табынам...

Онытa алмассың үзең дә – күңелең синең
Күңелемә күчкән өченгә.
Сагынам, –
Моңнар китми йөздән, яргынам!

## АРЫСЛАНКАЙ КИЕК

«Арыслан ла киек» һич сикермәс, –
Биек таулар ашалай йөремәс!
Һай,
Тау аркылы арыслан сикермәс.

Арыслaндай ирләр күп тау кичәр, –
Ил юлында арганын белдермәс.
Һай,
Зәүкы өчен ирләр ил гизмәс...

Арысланкай илендә, ай, патшадыр,
Ил-дәүләте – дала-сахрадыр...
Һай,
Сахра безне нигә тартадыр?

Арыслан ла йөрәкле ир-егетнең
Дөнья гизеп даны артадыр.
Һай,
Ир-егетне даны тартадыр.

* * *

Безнең җанкайларны сорасагыз,
Мамык калфак башында,
Үзе унҗиде яшендә.

*Халык җыры*

Җаныем, чәчең чыннан дамы бөдрә?
«Арасыннан җилме йөгерә»?
Нигә калфак юк чәчеңдә
Шул унҗиде яшеңдә?

Буйларыңмы кечкенә? Син – «төш кенә»!
Җан матурлыгыңмы сөйдерә?
Ник калфагың юк башыңда
Җырга кергән яшеңдә?

Җаныем, чәчеңнәнме син юллар салган?
Күз тимәскәме ул таралган?
Нигә калфак юк чәчеңдә,
Чәч тузгыткан яшеңдә?

Чәчкәйләрең, күз-карашың, миңең белән
Шушы җыр өченме син яралган?!
Ник калфагың юк башыңда,
Яр, унҗиде яшеңдә?!

* * *

...хәйран калам
Яшь имәннең бөгелгәненә.

*Халык җыры*

Булырсың чын хәйран, очрый калсаң
Карт имәннең бөгелгәненә.
Каты, нык ул имән
Нидән башын игән?

Чал гашыйгың гаҗәпләнә үзенә, әй, Яр,
Синең өчен өзелгәненә.
Гасыр кичкән имән
Ябалдашын игән?

Калырсыңмы хәйран, колак салсаң,
Шул имәннең җан авазына?
Яңа язлар килгән,
Яшәргән чал имән.

Яшьлегеңдә татлы сөю хисе, әй, Яр,
Ник көчлерәк гомер азагында?!
Шуңадыр ир-имән
Авыр башын игән!

* * *

– Сине бит күпләр сөйгәндер? –
Илеңдә, дим, синең өчен
Бик күпләр өзелгәндер?
«Күзләреңә бер карарга
Чиратлар тезелгәндер»?

– Берәү дә,– дисең, – әлегә
Каршымда тезләнмәде,
Газәлләр сөйләмәде.—
Көләсең: – Шөкер, тирәмдә
Йөрәкләр исән әле...

– Минем мең яралы йөрәк –
Көтмим ди төзәлгәнне! –
Ничекләр ул түзә әле:

Һаман да эзләгәне...
...Яр, үтенәм! – Сизәсеңдер
Минем ни теләгәнне.
Соңгы тапкыр илһам көтеп,
Бөек җыр... теләнгәнне?

Хур булсын күзсез-хиссез шул
Йөрәкләр илеңдәге.
Мин сөя беләм әле!
Күр син дә тезләнгәнне!

* * *

Син, бәлки, Мәңгедән миңа
Су сораган гөлләремә –
Теләкләремә бүләк?
Яңадан тамырланырга
Аларга бакча-йөрәк?!

Син, бәлки, сузылган җырым –
Озак гомеремә бүләк?
Шигъри бу сусауларымның
Ханчасы – олуг теләк.
Ихласлыгы өчен җанның,
Ак теләк өчен бүләк?

Син – сөеп арган хисләргә
Егылыр өчен тирәк:
Бар җиһан өскә ауганда
Ышаныч соңгы, терәк
Җаныма – алтын тирәк...

(Беләм бит: гүзәл җенеснең
Иң яше, хәтта сабые
Һәр өнгә сизгерерәк—
Ир йөрәгенә терәк!)

Тик ни бирә алам үзем?
Ни генә бу хис диңгезем –
Сиңа чын дәрья кирәк,
Сиңа чын дөнья кирәк...

...Тирәгем шаулый – тетрәнә...
Ни сөйли синең йөрәк?

* * *

Әйттем:
– Якты күздә, кич җитәрәк,
Бәйрәмем булыр, – белсәң, –
Юатып: – Син шундый яшь! – дип,
Чәчәкләр миңа бирсәң,
Бәхетем шул булыр – килсәң.

Диден: – Аңарчы сөйсәң...—

Әйттем:

– Кичеп бусын имин,
Яңа гасырны күрсәм,
Синең яшьлектән, җырыңнан
Айнымый озак йөрсәм,
Бизмәссеңме «Чалбала»дан?

Дидең: – Сүрелми сөйсәң...

Әйттем: – Димәк ки, яшәсәм?
Ә «чакыру» килеп – китсәм?
Азак, аягыңа сарылыр
Ак чәчәк булып үссәм,
Һаман шул миңеңнән үбеп,
Җылы җил булып иссәм, –
Танырсыңмы мине ул чак?

Дидең: – Үзгәрми сөйсәң!
Мәңгелек, димәк, шул икән:
Сөюемдә мин исән!
Беләм, ләкин
Яшәрмен тик
Синдә, үзең дә сөйсәң!

Ашыкма, кич... хис исән...
* * *

Тигезсез без! Үз-үземнән оялам:
Җырда да мин, ахры, тиңең булалмам!

Сиңа ошармы ул? Нидер җитми күк,
Сизәм, сурәтләр ачылып бетми күк.

Төзәтерсең, күреп, беркөн хатасын,
Бүген мактаганнан ялгыш табарсың!

...Аксакалга бу шөбһә-шик ятмы соң,
Яшь гүзәлдә күрсә үз илһамчысын?

Ул – шагыйрә һәм, шиксез, өстен булса?
Гаҗәпмени каршылыклы хис туса?

...Ләйлә шигырь язганмы? Чүлләр дәшми,
Ул Мәҗнүне газәлләрендә яши.

Булган бездә, кем, яр-шагыйрәләр дә:
Төркиләрдә тиңсез Надирәләр дә!

Шулар янында дип синең урының,
Алдан күрүе бу, бәлки, җырымның?!

Киләчәгең белгәнгә ул оялган...
Бөек бул, яме!

Мин инде – булалмам...

* * *

Сиңа абый тиеш йөрәк өчен

Үкенмәмен, беләм.
Мин еРактан, гүя мең еллардан
Сине эзләп киләм –
Гомер, гасыр ахыры йолдызымны!
Синең белән керәм
Яңа йөзгә, яңа меңьеллыкка!
Бергә озак бармам...
Ахыргача, җырларыңнан исереп,
Табынудан армам.

Актарсак та бүген сөю язган
Җаным елъязмасын,—
Калын ул том – синсез! Яшь гомремә,
Нишлим, «соңлаган»сың...

Алда, бәлки, яңа яшәү-балкыш?!
Синең исмең белән...
Әле күп китаплык көчем, языйм
Шашкын хисем белән!
Тиңсез яшьлек яктысында инде
Юлым җай, ипле күк.

Әмма...Синсез шигъри җәем өчен
Язың гаепли күк!

Еш уйлана йөрәк, гаепле күк...

* * *

Төшеңә кердемме? Чынмы, сөеклем?
...Яшь җанда манзара каян ул тиклем?

Анда хәтта диңгезләр дә сыйганмы?
Җан кылың минем халәтне тойганмы?

«Йөрдең, дисең, борынгы ябынчадан,
Диңгез ярында – Байронга охшаган...»

Кулым белән ымлаганмын аръякка,
Шунда дип белгәнгәдер Яр – еракта...

Төш – шигъри өн... Җанда күптән давыл шул,
Синсез узган минутым да авыр шул.

Чынлыктан ул – хыял язган сурәтең...
Лаекмы мондый хөрмәткә, йөрәк, син? –
Кадерен бел мәңге тансык хис-йөкнең!

...Төшеңдә булса да ярат, сөеклем!

* * *

«Илдә –
Алты яшәр юлдан кайтса,
Алтмыш яшәр күрешә килә» –
Күркәм бу йола – калыр...

Гүя

Сәфәреңнән соң серләшәм,
Мин җырың белән сөйләшәм,
Унҗиде яшьлек шагыйрь!
Гомереңнең язып бер бабын –
Романыңның керешен,
«Әкияттәге кыздай, баеп»,
Өйгә кайтып килешең.
Китабыңны җилләр ача –
«Күз ачкан умырзая»ң.
Ялбыр ябалдашым – чәчем
Шул җилдә тузгый һаман.
Тайга ияргән шул аттай,
Кешнисе килә җанның:
Исертә яз гөле төсле
Шигырьләреңнең хуш исе!
Һаман
Иснисе килә җанның!

Бер ямь, төс артты – дөньябыз
Яшәрер, матурланыр.
...«Тугач та маңгаең үпкән
Фәрештәләреңнән» үтенәм,
Унҗиде яшәр шагыйрь!
Саклагыз, димен, җыр көчен...
Ил җаны җыр саклар өчен,
Җыр исәндә, ул калыр!

* * *

Куркытмыймы алда имтиханың, Яр?
(Очрашуны күчерү ихтималың бар!)

Тапшырырсың: мин ышанам акылыңа,
Сөйләрсең төрки дәүләтләр хакында.

Яд итәрсең олуг зат– хәкимнәрне,
Якларсың мәхәббәт колы ирләрне.

Кыйммәтле, дип, алтыннан – сөю хисен
Олыларсың, – гүя пәйгамбәр исмен.

Мисал итеп халкыбыз сүз сәнгатен,
Мактарсың, беләм, шагыйрьләр өммәтен!

Ә сөйләсәң шунда син минем хакта,
Багышлау укып үзеңнең китаптан?

Шагыйрьлеккә хәлфәң дә дәгъва итсә?
Юри сиңа гел кыен сорау бирсә?

Бармы чынлап «батыру» ихтималы?
...Без хисләрдә бирдек зур имтиханны!

Шуңа да, уртак горурлык хакына,
Бергә җавап тотыйк Ходай каршында!

* * *

Безнең хис өчен Шеллиләр шөллиләр,
Хафиз, Сәгъди: – Сезләр – Былбыл, Гөл, – диләр.
Ахматова, Цветаева ни әйтер?
Ә Бабич,Такташ фатиха бирделәр.

Байрон, Һейне, бәхет теләп, гөрлиләр,
Гете, Шиллер: – Сез – игезәк җан... – диләр.
Блок, Есенин әлегә эндәшми...
Рәми, Дәрдемәнд, Тукай кул бирделәр.

Вийон, Бодлер да хәерле юл теләр;
Сафо, Китс никтер моңсу иделәр.
Пушкин һәм Фет хисебезне аңларлар,
Туфан, Хәким: – Милли сафка кил! – диләр.

...Фал ачабыз шагыйрьләрдән көнозын
Бәхетебездән әле исерек тилеләр!

* * *

Синең беренче хисләрең –
Саф алтын шигъри сүзләрең!
Миңа түгел, үкенеч...
Шуңа «үч итеп» язганым
Миңа кадәрге дөньяңны
Онытторырга тиеш.

Минем дә шәп, алтын чагым
Синсез узган – үкенеч!
Чәчләрдә инде көмеш.
Языйм, димен, шундый шигырь:
Ул синсез узган елларны
Онытторырга тиеш!

Һәм алда җырыңның тагын
Минсез гомре... Үкенеч!..
Күбәләк-җан, сиңа көч:
Күктән карап, җирдә очып,
Ничек тә шагыйрәңне син
Күздән җуймаска тиеш!

Киләчәктә җыр алтының
Башкага насыйп булырын
Белү – түгел үкенеч.
Бәлки, бүген язганнарың –
«Минем өлешкә – көмеш?!»

Ул – саф алтын бәхтем! Миңа
Шулай ышану тиеш...

* * *

Чәчләреңә төрдең мине...
Ник күзләреңдә моң бар?
Әйтә күк: – Ни генә димә,
Безне аера... еллар,
(Арада күпме ел бар!..)
Шулар өченме моңнар?!

Эзләгән җаннар бер-берсен
«Мәңгелектә ни еллар?!
Мизгел алар!» – шулай уйлап
Сөйгән җан әле елар,
Аерылышсак... Мәңгелектән
Бер-берсен эзләр җырлар!

Еллардан – җанда язулар,
Синсез булганга шулар
Ярлыкар Хак... Инде җанга
Сарылган синең куллар.
Буйсыныйк шул кылларга без –
Хискә! – илаһи коллар!

Узганнар ни? Инде җанда
Мәңгелек өчен юл, Яр!
...Чәчләрең сөртә яшемне,
Миндә дә дымлы моң бар.
Миндә дә кыен сораулар...
Шуннандыр җанда җырлар.
...Җырга – җаныбызга ышан:
Бел, Мәңгелектә без бар!

* * *

Күпме хат-хитап бар гүзәл җенескә,
Алданмаска өндәп... байлык-нәҗескә,

Түрә, тәхеткә кызыкмау, алтынга
Табынып, Иблискә җан сатмау хакында.

Нигә күзне сезнең акча кыздыра,
Ефәккә төреп, тән... җанны аздыра?

Үз итә ник сафлык купшы ялганны?
Бәлки, әле теләп үк алданганы?

Аһ, хатын-кыз! Язмышыгыз – Хавадан:
Гөнаһ-нәфсегез... гади бер алмадан!

Ә син, тиңсез яр дигәнем, кыз бала,
Кузгалса рухың, кая ул юл ала?

Җенесеңнән үзгә, өстен калырга
Көчең бармы бүген, горур шагыйрә?!

Әллә мең-мең әбекәңне кабатлап, син
Тән-рух тапталган юлгамы атларсың?!

Гүзәллек, син – байлык колымы һаман?
Сине йолу әмәлен табыйм каян?

Шагыйрьдә Иблис кояшы – алтын юк;
Җыр язам, дәшми калырга хакым юк!

* * *

Мин китаплар бирәм Сиңа:
Бөекләрне укырга,
Көчлеләр дөньясында рух
Канатың ныгытырга!
...Ә шулар соң «ярдәм итсә»
Үземне онытырга?!

Китаплар – теләгем Сиңа:
Гашыйклар тарафында,
Чорларны хистән уздырып
Шулар күк яратырга!
...Ә үзем бәләкәй калсам
Зур җаннар арасында?

Бүләк китаплар биеккә
Дәшсен «син җанашымны»,
Белсәм дә тиздән мин Синнән
Аерылып каласымны...

Җәе узмаган җанда Син
Сандугач баласымы?
Сайравыңны тыңлап ятам,
Җәйдә түгел, кышкы көндә
«Җәйдем ак паласымны».

Уйлыйм Син җанашымны!

* * *

Бәлки, сине – бердәнберне
Артык иркәләгәннәр?
Матурлык, җырлар, мәхәббәт... –
Әллә иртәләгәннәр?
Бәлки,
Шулар иркәләгәннәр?

Бәлки, сине – нәфис гөлне
Чамасыз назлаганнар?
Ни теләсәң дә син, каршы
Килергә базмаганнар?
Бәлки,
Ай, Кояш – назлаганнар?

Бәлки, синдә бер хан кызы
Күрергә теләгәннәр?
Күкләр иңдергән тере сүз
Булганын белмәгәннәр.
Бәлки,
Җыр башың сизмәгәннәр?

Рәхмәт, унҗиде ел буе
Гомереңне нурлаганнар.
Җан яктыма әвереләсең
Булганмы уйлаганнар?
Бәлки,
Кемнәрдер нур алганнар?

Инде тик минем бәхтем син, –
Башкалар соңлаганнар.

Рәхмәт сезгә, шул бәхетемне
Үстергән, нурлаганнар!
Сүзне
Һәм безне зурлаганнар!

* * *

Ил табынына ярармы сыем бу?
Фәкыйрь, бәлки... Әмма ихлас уем бу!

Кайсыны, кем, садәләр авыр итәр,
Чын гашыйклар зәүкы-һушына китәр.

Янганнар җанына булыр сулыш, аш;
Сусын бирер нык сусаганга Гаташ.

Беләм бәям, чамам мин – чын тураган.
Ашаганга?.. Халкыңа бул яраган!

Атым – Рәдиф, тәнем – зәгыйфь, күңелем – саф,
Ахыргача бирсәйде Ходам инсаф!

Элгәрләрнең өйрәндем мин мирасын,
Аңладым төрки бабамнар колачын.

Омтылышта – шул мәктәпнең талибе,
Мәхәббәт моңында, кем, чүлләр гарибе!

Әйтә алдыммы шуны бу китабымда –
Шагыйрәгә – яшь Ярга хитабымда?

Аңа хатлар, илгә ләкин сыем бу,
Әһле гашыйклар! Нәкъ сезгә серем бу!

* * *

Әллә эссе капты җанга,
Әллә... өтә салкын?

...Әй, кадерлем, тик бер бактың,
Кая мине аттың?
Уттан алып, мине әллә
Бозлы суга салдың?
Салкын... тагын... ялкын!

Әллә янам, әллә туңам?
«Титаник»тан ыргытылган
Дәрьяга мин! Батмыйм...
Сине таптым, моң – яшәүнең
Тыңлыйсым бар ахырын.
Күзләреңә бактым:
Айсберглар эриме?..
Сөюдәнме ялкын?

Баткан корабтан икәү без,
Күз алдында тик ут һәм боз,
Бергә ялкын, салкын...
Бу – сөюнең соңгы төсе,
Күзләреңдә калсын!
Мин югалам эзсез... Ә моң

Синең белән барсын,
Мәңгелеккә калсын!

* * *

Безне генә күзләде бит
Йолдызлар, безне генә.
Йолдызлар сөенде дә
Үз итеп көлде генә!

Ул кичтә бар җиһан сөйде,
Мөгаен, безне генә.
Күккә ашар көч иде бит
Безнең һәр сүзебездә,
Хис тулы күңелебездә!

Безне генә яраткандыр
Йолдызлар, безне генә.
Шуннан бирле якты бер сер –
Балкыган күгебездә,
Хәтта һәр... эзебездә.

Җем-җем йолдызлар үз иткән
Бер безме Җиребездә:
– Без – иң бәхетлеләр! – дигән?
Шул нурлы сүзебезгә
Тугры без үзебезгә!..

* * *

Бармыни моңга имтихан?
Уйлыйм: мөгаллимең кем?
Шартлы сораулар беләнме
Чикли ул җырның иркен?

Кояш, айга оча рухың,
Уең – мәңгегә тоташ.
Чылбырына тисә дә таш,
Читкә атыла, туташ! –
Җаның күкләргә тоташ.

Синең үз дөньяң – язмышың!
Мәңгелекме, фанимы...
Үзең тудырган бәхетнең
Үзең язган кануны.

Сынау бармы моңга? Шагыйрь
Йөрәген иңләр соң кем?
Үзеңә-үзең җавап бир,
Бел: чикләнмәгән иркең.

Җыр – язмыш... Мөгаллим – кем?!

* * *

Бер карашыңнан кечерәйсен... «зурлыгым»!
Фида Сиңа «мин»легем, горурлыгым.

Сурәтең каршына Гаташ тезләнгән,
Хуплау көтә җанына яшь күзләрдән.

Хат-сүзләрең дә килер, дим, авылыңнан –
Сине үстергән киңлекләр ягыннан...

Урын бардыр миңа да урамыңда
Керәшен моңын сагынган җаныма?

Хисемнәндер эри гыйнвар карлары?
Уем – корабым, йөзепме бармалы?

Яр, кабул ит, ишет шушы өнемне,
Биекләргә ашкындырсын ул Сине.

Омтыл җырда йолдызларга, күкләргә;
Кул изәрсең, хыялыңа җиткәндә.

Тузан булсын юлыңда җан «зурлыгым»,
Шулай куша Яр өчен горурлыгым!

* * *

Һаман язсам – ул Сине сагынганга,
Илаһ санап, бер Сиңа табынганга.
Ә очрашкач... Әйткән, ди, шулай Мәҗнүн,
Назлап, яры чәченә кагылганда:

– Кит, Ләйлә: Ләйләмне уйларга ирек бир!
Мәҗнүндә ташкан җырларга хөрлек бир.
Кит, Ләйлә... тик җанымда кал, уемда.
Очышына рухымның җиңеллек бир, –
Гашыйк җаным гарешкә бер ирешер!

...Янсам мин дә – үз җанымда дәвамы,
Язсам, ядымда Син-җанаш авазы...
Тән җир булса, рух – күк... Күпме арасы?
Мәңгелекне үтепмени барасы?

– Кит, Ләйләм, Сине уйларга ирек бир,
Мәҗнүнең рухына иркенлек бир!
...Кайт, Ләйлә... Тик җырымда бул, җанымда.
Хыял газабыннан соң җиңеллек бир.
Шагыйрең җаны Хакка бер ирешер!

* * *

Яр! Күз салдым ялгыш мин язганыңа...
Миңа түгел, ят өчен янганыңа.

«Юлыктым, Лу, менә шундый чәчәккә» –
Иҗатыңа, озак тетрәтәчәккә...

Җыр – иркеңдә, канатлы, горур – очар;
Ихтыярың шул кошыңа ни кушар?

Бәлки, иң көчлесе шушы җырыңның?
Сәбәпчесе өзеләчәк кылымның...

Ә нинди кыл? Ялгыш өмет, хыялмы?
Чал гомерем көчсезлектән елаумы?

Үзенә бит тугры һаман яшь хисем:
Иренемдә тетрәнә җырдай исмең!

Шаһит булсын ул бүген янганыма...
Башкагамы? Юк, сиңа язганыма!

* * *

«Әтил суы ака торур...» –
Җыр картаймый... Ә йөрәк?!
...Карашларың – күпкә яшьрәк,
Нигә хәйләкәррәк? –
Күпме генә Кояш эчкән
Күзләрдә илаһи яз!
Әлмисактанмы Сезләрдә –
Олуг тәҗрибә?! Хисләрдә –
Ир җанын эреткән наз?

Яз, наз һәм җиңү ватаны –
Матурлык мәңге мәгърур;
Кабатлана һаман: яшь Яр,
Яшен оныткан чал ир!
(Күпме янып та, көлеңнән
Кабат яралган – терелгән...
Тагын «баш җуйган фәкыйрь»
Синдер, йөрәк... Ә бәлки син –
Шуңа да Гаташ – шагыйрь?!)

«Әтил суы ака торур...»
Ә хискә тугрылар, ахры,
Кимемәс – арта торыр...
Яшь карашларың горур!

* * *

Күнегә алмам сәер бу җиһанга:
Йә, ни генә үзгәрмәс бүген анда?!

Ай тотыла... планеталар парады,
Нишләр мескен иске бу Җир корабы?

Кешедә мәңгелек гөнаһ! – сизелә:
Көн саен сугыш, һәлакәт, зилзилә...

Ачулымы Кояш? Нуры – агулы...
Якынаямы шул дөнья ахыры?

...Ни уйларга, кадерлем, белмәгәнгә,
Әйттем: – Болар – мин Сине көнләгәнгә.

Ярамыйдыр – нахак сүз пакь җаныңа?
Җәзадыр шул – хаксыз елатканыма?!

Йә җавап бу, Яр, Син – горур булганга?

...Бик еш, сизми дә, җанымны кыйганга?

Гаҗәпмени булса?! Чиксез җиһан ла!

* * *

*(Киләчәккә карап, бер уй)*

Узып тик... илле (!) ел, мине онытсаң?
Нәкъ Зөләйха – яшь «Йосыф әлен дот»саң –

Киләп сарып, кулларыннан җеп алсаң,
Йомгак чорнап, кальбенә хис юлласаң?

Тартсаң аны ничек тә үз «уен»ыңа
(Ялгыш та алмасаң мине уеңа?!),

Кызу бер мич йә бер камин каршында
Эресәң син камил ир карашыннан?

Тап булсаң ләкин салкын таш бәгырьгә?
...Шунда бу шигырь иясен хәтерлә:

– Кадерен белдемме? – диген, – шул «Чалъяр»ның?
...Тезләнеп бит каршыңа, мең ялвардым.

Яшем тамды кулыңа, «Хуш!» дип үпкәч,
Бел: яндырыр көчлерәк – еллар үткәч.

...Тукта, Гаташ! Әле ярың яныңда,
Әле якты уйлар аның җанында.

Белмәсен ул шул киләчәк хакында!

# ***IV. Газәлләр***
***(1965–2001)***

* * *

Кайда ул ил? Илтә нинди юл? – Туран...
Баглымы шул илгә исмең, Гөлтуран?

Төрки ватан, Ана йорт – изге җирнең
Эзен күммәгән бит вакыт, ком, буран.

Тарих итеп, бактым синең күзләргә, –
Мәңгенең рух язуын кем укыган?

Чүлләр илен, гөлсахра, җил хәтерен
Уятсын диптер, Хак сине бар кылган!

Синең аша җанкавемнәр эндәшә:
Төркиләр! Сибелгән чәчәк-гөл сыман...

Чин-дивардан Әдрәнгәчә уйнаклый
Бабайлар даны, тузаны – үз томан!

Айнымас Иран шөһрәтле Туранның
Горур ярлар калдырган илһамыннан.

Төрки гөлләр исен онытмас Гаташ.
Милли дөнья исмендә ук: Гөл... туран!

## КАЛӘМГӘ ГАЗӘЛ

Сүзем сиңа, гаувасым, әй җитез каләм,
Тагын сине кара «диңгез»енә салам.

Сулыш ал да озын итеп, чум төпкәрәк;
Анда бер-бер кыйтга, бәлки, – күндер сәлам.

Савыт – тирән, иркенләп йөз, озаклап йөр,
Нәрсә тапсаң, ләкин уртак булыр, фәлән...

Гәүһәр эзлә түзем белән, әнкәй сүзе:
«Энә белән кое казу авыр, балам...»

Мин җибәрдем бу дөньяга, кыен юлга,
Мин җаваплы – һәлак булсаң шунда, каләм!

## МӘҖНҮН XX

Моны язды фәкать сезнең фәкыйрегез,
Сезгә мөкиббән ки, күптән әсирегез.

Сезгә тик бер якты булсын юлыгызда
Фәкыйрь җанын факел иткән шагыйрегез.

Өрегез дә сүндерегез ул факелны,
Билгесезлектән тик мине коткарыгыз.

Янсын әйдә җир өстендә балкып бары
Һичкем буе җитмәс бәхет утларыгыз.

...Моны әйтә күптән мәгълүм фәкыйрегез –
Сезне күргәч «теле ачылган» шагыйрегез!

## 1913 ЕЛНЫҢ ҖӘЕ.
## ЗӘЙТҮНӘ – ТУКАЙ КАБЕРЕНДӘ

**1**

Халкың уяна... Сиңа соң
ул каян иңгән йокы?!
Шагыйрь, тор, кабрең янында
кем әнә Коръән укый?!

Исемен мактаган китабы –
чын Кәламулла кулда;
Күз салмый аңа – яттан ла
ялкынлы сүрә укый!

«Васыяте»ңне дәфенеңдә
яңгыратты муллалар.
Ул, кушып күк аятьләрен,

кыз хисен бергә укый!

...Яд итәр гомере буена:
диварда рәсмең торыр!
Хаҗ юлын багышлар сиңа –
бел, Мәккәләрдә укый!

**2**

...Киләчәк әле күрәчәк:
табыныр чын кәгъбә – син,
Бу шуннан хәбәр – күр:
әнкәң яшедәй саф җан укый!

«Мәхәббәт сакчысы» киткән:
бу Мәңгелекнең йорты,
Тузан күк гөнаһы юктыр –
керсез пакь иман! – укый!
Җирдә әллә Гайсәнеме
юган хатыннар өне?!
Татар кызы ул – кабреңә
фәрештәң килгән! – укый!

Инде, Тукай, нәкъ мамык күк
җиңелдер кабрең ташы?! –
Баш очыңда... әнә ярың –
Зәйтүнәң Коръән укый!

## ЗӘЙТҮНӘ МӘҮЛҮДОВА-РӘСҮЛЕВАГА ГАЗӘЛ-ХАТ

Зәйтүнә ханым! Сезгә бу,
сезгә,Зәйтүнә ханым.
Гасыр ахырыннан хат барсын –
тагын мәдхия яздым.

Тукайга сез биргән илһам
чаткысы төште безгә –
Кабындым, сезне яд итеп,
ихластан уйный сазым!

Гүзәллеккә табынмаган кайчан, йә,
кайсы шагыйрь?
Сезне данларга телемдә энҗе-сүз
әллә аз? дим...

Байрон, Пушкиннар яр сөйсә –
шул хакта күпме роман!
Сезнең хакта да, ахрысы,
бер матур әсәр лазем?!

Сөенерме рухыгыз тик –
борчыйсыз, димәссез бит?
Мин горур: татарча хисем,
Тукайча газәл яздым!

Халкым күңелендә бергә сез –
Тукай һәм аның яры...
Моннан да зур милли тәхет

бармы, Зәйтүнә ханым?!

## БАБИЧКА БЕР ВАРИАЦИЯ-ГАЗӘЛ

Тетрәп калды мәгълүмегез – хис колы.
Мандолинда... җанда уйный кыз кулы!

Нурланды бүлмәм, яп-якты өстәлем –
Моңарчы тарау яткан кәгазь тулы.

Җанланды зәгыйфь сурәт – ут алынды!
Җәбраилнеңме канаты кагылды?

Ачыкланды гомер алда: максатка
Гүя кинәттән туры юл табылды!

Җырлады җан, уй-фикерләрем ташты,
Рәсүлемә вәхи килгәндәй булды!

Арынды гөнаһ уеннан яшь хисем,
Гүя җаннан әнкәм догасы узды!

...Миңлебай, әллә Әхмәтме? Абзыйлар:
– Алиһәм! – дим киндер күлмәкле кызны...

* * *

Аңладым, ниһаять! Сез – күз бугансыз,
Кара китаптан дәрес укыгансыз!

Югыйсә акыл җуйдырган сихерне –
Шундый сүзләрне каян Сез алгансыз?!

Аһ, ул җырлар! Чын булмагач наз, уты –
Икейөзлелектән Сез көч тапкансыз!

Фәрештә канаты белән сыйпагач,
Күз дә йоммый чын Иблискә саткансыз!

Эссе хис кочагында йоклатып,
Тантана итеп, упкынга аткансыз!

Ни максат белән дип, юләр, баш ватам:
Тагын бер җанны гөнаһка тарткансыз!

Каян дисәм чын мәхәббәткә нәфрәт:
Ярата белгән өчен үч алгансыз!

Шул көе әле үзегез җырда Сез,
Янәсе, сөттән ак, судан пакь калгансыз!

Ничек акланырга белми ихлас хис,
Ник көчле ул шулай чыннан ялган сүз?

...Ә ник үзем башны алып качалмыйм?!
Ник кирәк мин – җибәрмисез һаман сез?!

**СИНЕҢ ГАЗӘЛ**

– Болытлар, юлыгыз кая,
Казангамы, әйтегез?
Туган якларыма җиткәч,
сагынганым әйтегез.

Болытлар, кадерлем нишли,
күрерсез, бәлки, аны?
Һәр хәбәрен көтеп алам, –
табынганым әйтегез!

Ул рухымны күтәрәчәк,
чын сөюнең сакчысы!
Мин генәме, дуслары күп
монда аның, әйтегез!

...Тик һаман да шундый калсын,
заман дип үзгәрмәсен:
Ак хыялларда балкытсын
ихлас җанын, әйтегез!

Шау-шулы металл музыка,
«рок»лардан моңны яклап,
«Биек тауга менәмсең» дип,
еш җырласын, әйтегез!

Дөньясы шундый: күп бүген
хиссезләр, эшкуарлар...
Биектә калсын, юлыннан
тайпылмасын, әйтегез!

...Болытлар, аны, дусымны,
тиз көндә күрерсезме?
Уралда матур ядкаре
сакланасын әйтегез!

**ГАЗӘЛ. 1989**

Диденң: «Ышанам ки, тагын
синең йөрәк буш түгел.
Гаҗәпмени? Буш икән ул синдә –
димәк, хуш түгел!

Мөсәл дә раслый икән ич:
күр, Елан елы быел!
Шундый сөюсез, янусыз
сиңа, дим, тормыш түгел!

Әйт, шулай бит? Буш түгел бит
йөрәгең чуар, җаның?
Ә икебез бер аңлашу –
ул безгә булмыш түгел!

Син кайчандыр шашып яндың,
яшь идең, беркатлы, саф...
Аһ, ник гел шундый калмадың,
ә мин – шул яшь кыз түгел?!

Безне нык үзгәрткән дөнья:
башка син уеңда да...

Кабатлыйм: димәк, язмыш шул...
Ә бәлки, язмыш түгел?!

Беләм, мәңге күңелемдә
көләч сурәтең яшәр...
Соңлап килсә дә ярату,
ул – бәхет, ялгыш түгел!»

...Үпкәләргәме Рәдифкә?
Хисләр илендә кол ул;
Кайсы гашыйк күңеле күктә
һәрдаим биһуш түгел?
* * *

Ташлармынмы? Җыр ни ди: «Таш ярылсын...
Түгел, ди, һичкайчан ташлар ярым син!..»

Миннән күпкә акыллырак әйбәтем,
Түземлерәгем – нәкъ көткән парым – син!

Куркам: үзең, дим, беркөнне ташласаң,
Кирәксез санасаң мине, җаным, син?!

Әле без бербөтен: бергә тоташкан,
Мактый Гаташ та җанының яртысын;

Тәмам юләр түгел, аңлый шагыйрең:
Синсез мин җирдә нәрсәгә ярыйм соң?!

«Тау ярылсын, таш ватылсын – ташламам...» –
Газәлдә дә шулай җырла, ярым, син!

* * *

Әй, йолдызчы! Сиңа минем
бар зур үпкәм. «Ник?» димсең?
Пар түгел, имеш, Кучкарга –
миңа – ярның билгесе...

Йолдызнамәң нигә безгә –
кавышуны кызганса?
Күкләрме безне аңламый?
санламый ялкын-хисне?

Ялгыша барсы да, беләм!
без күптән ул яр белән
Аерылгысыз – бәйли җирдә
игезәктәй җан көче...

Моңсу бер уй яр йөзеннән
узды, син юраганга.
Ул вакытлы: аяз көндә
күләгә төшкән төсле.

...Әй, йолдызчы! Безгә дип син
махсус йолдызнамә яз,
Гашыйклар илендә тиң, дип,
сөя белгән һәр кеше!

* * *

Багышладым җанны сезгә,
милли гүзәлләр иле!
Табындым, үлмәдем,
ярлар, аядыгызмы мине?

Туганнан бирле янам ла,
чынлыктан качтым бугай, –
Ә сез хыялыгызга тиң
санадыгызмы мине?

Утыз елдан артык очам
сезнең кояш тирәли.
Тиргәлде җырым – сүзләрдән
якладыгызмы мине?

Күпме җирләр, илләр күрдем –
җуелмый сезнең сурәт,
Бүген дә, яшьлеккә дәшеп,
алдавыгызмы мине?

Шулай яратканмы әнкәм һәм Раббым –
юк үзгәрү!
Утта янып бетсәм, кабат
яңартырсызмы мине?!

Яшь йөрәк, ак күңел ярлар –
милләтем йолдызлары!
Аралагыз шиктән бүген
Гаташыгызны – мине!

* * *

Синдә, әйт, болан күзле яр, ниләр бар?
Карашыңда адашкан кемнәр алар?

Читтән көнләшеп күзәтәм: алдану
Бәхтен, дим, аңлый микән соң ул җаннар?

Үч итепме аларга, син арыслан
Күңлен аулыйсың, булсын дип патша-яр?

Син зурлыкка омтылгангамы шулай,
Өмет өзеп, мәй сорый сусаганнар?..

Сабырын җуйсын Гаташ та, дисеңме? –
Әллә ул гашыйкта инде сабыр бар?

Аның да, рас, мохтаҗ җаны илһамга:
Пыскып түгел, билләһи, дөрләп янар!

Синең хакта читтә бүген фал ача:
Бик буталчык тәкъдиреңдә язганнар!

Бу газәл исеме шуңа да билгесез:
«Болан күзле сагыш?» «Тәхет көткән яр?!»

* * *

Синең күзләр, кем, гасыр ахыры кызы,
Заман ахырыннан кач, дипме юл сузды?

Биектән баккан гүзәлгә табындым, –
Илаһ-көч әллә күктәнме кул сузды?

Сихри балкыш, күз читендә миңең ни?
Җирне күк белән бәйлидер шул үзе?

Чайкады бу караш моңда җанымны,
Һич өзелми зәгыйфь кыллар көй сузды.

Яшәрер, дим, шактый суынган хисләр –
Хәбәрче син: яндырачак нур узды...

Яттан укыйм гүя мин бу газәлне:
Утлы хәрефен аның синме, кем сызды?

...Заман ахырында да чын җыр – шул, Гаташ:
Тәхтенә күтәрә алсын буй кызны!

* * *

– Безнең якта алма диләр
бәрәңгегә, – дисеңме?
Кызыл алмам! – дисәм, инде
кимсетерме бу сине?!

– Ике алмаң тибрәнәдер күкрәгеңдә, –
дисәм мин, –
Бәрәңге хакындамы сүз?!
Күктән җиргә төшимме?

– «Сад»та үскәне – «буалма» бездә, – дисең...
йа Алла!
Ике битең – «буалма»дай алсу, –
шулай диимме?

Кайт тизрәк син... Саф мишәрчә
сүзләрең тансык җанга;
«Буалма»ларыңны сакла, урлатма,
дип өстимме?!

Үпкәләмә, телләреңдә сандугач
сайраган яр! –
Бу юлы Гаташ нык сагына
шул «буалма»сын – сине!

* * *

Бәхеткә, әлбәттә, яшьнең хакы зур!
Шуңа да бит сөйгәнең артык горур...

Ул – синең наз табынында яр-кунак,
Ә Гаташ – бер сыныкка мохтаҗ торыр...

Шунда да үзен бәхетсез санамас:
Хистән тәгам җыйган кайчан ач булыр?

Иркәләсәң яшьне яшерен җирдә, бел:
Чал сакчыгыз – янәшә төн уздырыр.

Уеңда – илаһи дөнья, син – шунда...
Шуңа хисеңдә биеклек, якты нур...

Яшь, бәхетле ярыңны сыйдырмый уй:
Йолдызга ашкан бәхетле рух – горур!

* * *

Синең бакчаңа кунган мин – нинди кош? –
Кума ләкин, җырым аңларга тырыш:

Ил-йортыңнан хәбәр ишетеп килдем,
Күргәнсең дип узган төндә шундый төш...

Былтырдан калган кып-кызыл алмалар
Алмагачта, – шуны коясың, имеш...

Юраучылар йөри хәзер баш ватып,
Күрәзәләр: булмасмы бер хәтәр эш?

Сугыш юкмы? Илгә афәт килмәсме? –
Йолдызларда күренмиме үзгәреш?

Борчылудан дәһшәт тулы күзләрең:
Яшькелт дулкыннарың давыл сизә ич...

Ни яшермәс Кыз җаны тирән моңда!
Тик үткәнгә, өзеп «Хуш!» дию тиеш...

Бакчаңда, бел: ул сиңа тугры күңлем –
Бәлки, йортың котын саклар изге кош!

* * *

«Дуслык урамы»ннан хат көтеп ардык,
Каләм һәм мин галәмгә сөрән салдык:

– Гашыйкка нидән салкынлык илеңдә?
Һава, җилендә, мөгаен, усаллык?!

Сандугач сайрата идем телемдә –
Моң юлына каян киртә-кысанлык?

Ышанганым минем ялгышмы – исмең
Булды дип төрки ярларга кушарлык?

Канатлар бирдең үзең чын хыялга –
Бар татар тарафларына очарлык.

Ничә еллар янып, җанда тәҗрибә
Юкмыни бер яшь күңелгә ошарлык?

Дошман күрмәс бу юлларны урамың –
«Дуслык» исмен аклар ул дип ышанийк.

Гаташта ихлас каләм – белсен галәм:
Сәер теләктән – нәфестән үч алдык!

* * *

Димәк... Сездә гашыйктан көлү уе!
Ялкыттымы хыялый күңел сые?

Мыскыллап соң бер мәхәббәт баласын,
Мыскал бәхетегез үлчәүгә сыйдымы?

Охшатып бер карт мәзәкчегә аны,
Яшь җаныгыз, йә, канәгать булдымы?

Гашыйк дивана илчесе – җыр кошым
Күңел талыгызга ялгыш кундымы?

Кыз зәүкына фида ир горурлыгым –
Әйдә, шат балкып йөрегез көн буе!

Ә Гаташта үзгәрмәгән бер хыял:
Рәсмегезгә лаек төс табу уе.

Таш белән бәргәнгә дә мин аш белән:
Шагыйрең, күр, алдыңа газәл куйды!

**БЕЗНЕҢ ГАЗӘЛ**

«Газаплар күрдем – шуңа да матурмын!
Сөйдем – шуңа яшәргә җан атуым...»

Бу газәлне башлыйм синең шигырьдән,
Үз хәлемнән эзлим дәвам, ахырын.

Аңлыйм синең җанны! Мин дә гомремдә
Чынлыкны шулай эзләдем, татыдым...

Чын сөю – тик газап, сагышлар юлы,
Мин дә ихлас шаштым, яндым, табындым.

Эзгә төштем – табылды бәхтем дисәм,
Кабат адаштым... Аһ иттем тагын мин:

Соңгысымы сине күргәч тетрәнү?! –
Бу, мөгаен, «бәхетедер» җанымның.

Ә син, димәк, газап күргәнгә матур?
Сөйгәнгә – яшь? Гел шундый бул, амин! – дим.

Гаташ та яшәүдән туймас. Телә, Яр:
Һич югында, хисемдә яшь калыйм мин!

**ТАГЫН БЕР УРТАК ГАЗӘЛ**

«Кем сез? – мең сүз дәрьясыннан

табар мин көткән – берне?
Белсәгез: аһ, шул сүз миңа
булыр иң-иң кадерле!»

Кем мин? – ярты гасыр яшәп,
шул сораудан тетрәнгән?
Бу бер яңа йолдызныңмы
йә гөлнеңме зар теле?!

Бәхетен көткән бер нур-затның
йә бер илаһи моңның
Эндәше, бәлки, җиһанга?
Әллә бер сәнгать төре?

Үзенә игътибар сорый кем?
Ихтирам, сөю көтә?
Яна ут, өмет балкышы,
эзләнә, яши – тере...

Һәм көткәне аның – минме?
Җавапмы – соравына?
Шул уй өзә җанны яңа
җыр ишеткәннән бирле.

Бел, йолдызъяр! Мәңгелектә
бар үз урның, ак нурың,
Шул нур яктысында табыйм
син көткән сүзне... Берне!

**ФӨЗҮЛИ ГАЗӘЛЛӘРЕ**

*(Тәрҗемәләр)*

* * *

Хәрабәләр иле, бәлки,
яраткан безнең Җиребез?
Әмма күпме хәзинәләр! –
күмелгән байлыклар, дибез.

Тышкы дөнья алдый кайчак,
алданма, күпне күргән ир!
Яшерен матурлыкны күрми
фәкать акылсызлар, дибез.

Шулар кыстый: «Хәмер эч!» – ди,
тик бу заман ахырында
Шәраб – күптән кан төсендә,
бирми ул шатлыклар, дибез.

Аңладык без: дөнья фани,
аңа ышану ярамый,
Сөләйманга хәтта ул көч! –
безгә – гел сагышлар, дибез.

Фөзүли, янәшә яздың
«мәчет» һәм «мәйханә» сүзен,
Акыллыга санап сине
әллә ялгыштылар? дибез...

* * *

Миндә сәрхуш халәте... Йә,
кем әле дустым минем?
Хәят ни ул? Кайда сакый?
Шәраб ник юк? – белмимен.

Ярыма дәшәм: тынгылык
табылыр, бәлки, җанга?
Ә тынгылык ни? Кирәкме
гашыйкка ул? Ни диим?

Хәятны аңлау, гыйлемле
булу – чын хәкимлекме?
Белмичә берни, бәхетле
яшәүчесе күп җирнең!

Әй, Фөзүли, фөрьядыңа
бар дөнья хәйран калган!
Җан теләп алган газап бит...
Кемгә зар, аһың синең?!

* * *

Йа Раббым! Исемең җанда
мәңгелеккә яралган.
Пәйгамбәребез нурлаган
Күк, Җир белән ялварам...

Гамь тулы күңлем корабын
йотсын сөю диңгезе, –
Мусага изге хәбәрче –
Хозыр белән ялварам.

Артса да газаплар йөгем,
язмышым юлында мин,
Аһларга, газапка лаек
шул яр белән ялварам.

Кара аерылу төннәрен
кавышу көне яса!
Гөл исле, нур төсле таңнар –
сәхәр белән ялварам.

Ярдәм ит, ярдан еракмын,
адаштым, бер юл табыйм! –
Безгә хак юл биргән рәсүл
исеме белән ялварам.

Түзем бир, Раббым, бу кайгы-
газаплар дөньясында!
Күпне кичергән әүлиялар
исеменнән ялварам!

Кабул кыл догам, ярлыка
Фөзүлидай колыңны...
Рәхимең төшкән догачы
рухлар белән ялварам.

* * *

Бу яшерен сөюне җилләр
Гөлгә сөйләгән, диләр.
Җил, ил авызын каплар кем? –
Ишетеп, ил хәйран, диләр...

Күпме хис коллары исерек
матурлык шәрабыннан!
Ә без – шаһтыр. Син – Ләйләме?
Мине, бел, Мәҗнүн, диләр.

Дошманыма баш иеп, син
көндәшемне сөямсең?
Хакмы шул? Рәхимсез ул дип,
карты-яше сөйлиләр...

«Чин иленнән пот-һәйкәл ул,
чәч бөдрәләре – зөннар*»...
Аһ, кяферләр: көнләшүдән
көфер сүз ич көйлиләр...

Фәрештә дип атап элек,
хәзер ни күрделәр, йә?
«Ул – бер афәт илгә, шиксез,
һәлакәт!» – дип сөйлиләр...

Сөю хастасы булганнар:
«Чәчеңдә дәва бар», – ди...
Ә табиблар: «Сөю – үтмәс
чир ул, сөймә яр», – диләр...

Яратудан тыючылар безне
ялгыша Җирдә!
Язмыштан узмыш бармыни?
Алар нигә «бар» диләр?!

* * *

Йөзең – бер нур... Тик дошманым
мәҗлесен яктырта... ник?
Ә миңа ул – яшен уты,
кагылса, яндыра... ник?

Ятларга бит гел наз, шәфкать
вәгъдә итә карашың;
Миңа кадала ук булып,
гел яра калдыра... ник?

Кавышу көтә: чәчәк атар
ул көнне җан гүяки,
Ел да язда гөл, яр исен
китереп җил шаштыра... ник?

«Йолдызың Айга бик якын
килмәсен!» – ишетми җан.
Риза юлдашы булырга,
гел шунда калырга... ник?!

Баш куйгач кулыңа Фөзүли,
«кул селтәде дөньядан», –
Кулга ияләшкән шоңкар
битараф тау, кырга... ник?!

* * *

Үзең бирдең, язмышым, аһ,
кулыма хис тезгенен.
Мәҗнүн дә җиталмас мине –
җилдердем, җиһан гиздем!

Исертте сөю – калдырдым
намазны, гөнаһлы мин!
Ут шәрабы тулы касәм –
эчтем, ләззәттә йөздем...

Сәрви-кипарисың ни ул,
мактыйсың, бакчачы дус:
Сәрвидән дә зифа буйны –
күрдем гүзәлнең үзен...

Күңелемне фаш итте яшьләр –
хур итте илгә мине,
Яшь чишмәсенең үземе –
сертотмас булды күзем...

Һаман шул – сөю колы мин,
горур ярыма тугры,
Күзләр – моң йорты, йөрәгем –
гамь дөньясының үзе...

Аһларым угын, Фөзүли,
Күккә атыйм синең күк;
Үч алыйм: күп ишеттем ич
Тәңренең каһәр-сүзен!

* * *

Сөю газаплары уттыр...
Әмма, Аллам, ал мине
Тынычлыктан – яндыр, көйдер,
ялкыннарга сал мине!

Мең әрнүле колыңны бер
мәрхәмәттән ташлама;
Тоташтан яндыр – мәңгелек
чын януга сал мине!

Газаплар бит үз иттеләр
күптән бу йөрәгемне,
Мәхрүм итмә, тагы да көчле
газабыңа сал мине!

Мөртәт димәсен сөйгәнем,
кальбемдә чын денем – ул,
Горур таш булыйм, эремәм –
тәмугыңа сал мине!

Тагын да гүзәллек өстәп

ярыма – мине яндыр.
Яр өчен тиңсез януның
җан утына сал мине!

Фәкыйрьлек, юклык күңелгә
һич кенә дә ят түгел,
Дан-шөһрәт – ертык чүпрәктер,
изге уйга сал мине!

Яр өчен янудан гамем
бер шәүлә итсен тәнем,
Саба җиле белән илт тә
яр куенына сал мине!

Фөзүли күк артык горур
булудан сакла берүк,
Гамьсез үземә кайтарма –
китмәс моңга сал мине!

* * *

Чын гашыйк шул: кем яры өчен
кызганмый хәтта җанын...
Җан – газиз дип куркып сөйсә,
хисләре ялган аның!

Җананга багышла җаның!
Сөюдә – шулдыр зурлык.
Башкача икән, шик белдер
«януы»на янганның!

Сөйгәне өчен җан бирүче
ул мәңгелеккә ашар,
Шул безгә иң гүзәл үрнәк,
аты – чын дастан аның.

Күбәләктән үрнәк алсын
җиһанда яр сөйгәннәр:
Утка бара – белми, сизми
янып көлгә калганын...

Кимлек ул, үзең «сөям» дип,
тыныч, тын күлдәй булу,
Дулкыннары ташса, күңел
күмә, шашып, ярларын.

Мәхәббәткә дару юк, ди,
әҗәлгә, имеш, бар ул...
Җаны хакына даулый тик,
яулый гашыйклар ярын.

Һәм җаныңны яр кулына
тапшырган көнеңдә син,
Мин бирүзем, димә, белми
гашыйк Фөзүли данын!
* * *

Гыйшкыма һич дару тапмый

инде табиблар арды.
Арсын соң, шуны белмәгәч,
гашыйкка дәва бармы?

Гөлчәчәк телен беләмсез? –
Ни ди ул минем хакта?
Былбыл да моңая шунда,
бик тәкәбберме яры?

Каушудан татлыдыр видаг
чын гашыйк Мәҗнүн өчен,
Безне аерган, сөенгән
җаннар шуны аңлармы?

Ярга зар һаман – аның соң
бармы бер-бер гаебе?
Хәлемне белми ул, бәлки,
Әллә соң хәбәрдармы?

Нишләргә соң? Котылырмынмы
бу богау, тозак, аудан? –
Гүзәлләр хәйләсе тота
миндәй диваналарны!

Күбәләк, утка очма, бел:
янып бетәчәксең син,
Сөю көл итсә минем дә
мисле күбәләк җанны?

Яр сараен оҗмах санап,
сагын, ела, Фөзүли!
Күпме юлчы елый, уйлап,
туган ил, ерак ярны!
* * *

Йөзләреңдә гөлләр бармы?
Кунам, ди, былбыллар да!
Энәсе бар гөлнең, диген,
яман күздән сакларга.

Нәркисләрнең, лаләләрнең
нидән башы иелгән?
Гүзәлләрнең һушын алды
күзләрең, чәчең – багъда...

Гөнҗә-бөреләр ачылган,
исмеңне әйтергә дип,
Син ул гөл телләрен назлы
сүзләрең белән бәйлә!

Тын йокыңнан уян ла, яр,
җаныма яра уйма,
Җан кошым ансыз да күптән
талпына сәмаларга*!

Җан, яраң иреннәрен кыс,
укларыннан кач ярның,
Хәлең сиздермә – серемне
белдермә син ятларга!

...Теләкләр колы синмени
бу җиһанда, Фөзүли?
Сабыр ит, көт: күрешер көн
булыр, ул әле алда!

**ГАЗӘЛ-ТӘРҖЕМӘ**

Кайда син, көткәнем, җаныма
ут ягучым, кайда син?
Күземнең нурыдыр син, тиңсез
байлыгым, кайда син?

Иреннәреңнең тәме һәр шәрабтан
татлы иде,
Күрмимен күптән, йөрәккә кан саудырдың,
кайда син?

Син – гөл йөзлем, назлым минем, –
нәркистер күзең төсе, –
Тик чәнечтең дә, мәңгегә мәҗрух калдым,
кайда син?

Әй, кайда хәзер тынычлыгым, дим,
сабырым минем?
Тынлыкны ватты мәхәббәт, сабырым яндырдың,
кайда син?

Уклардан, авыр сүзләрдән сакланыр
калкан идең,
Каш-күземнән ул калканны инде салдыр,
кайда син?

Мин – күбәләк, янсам да, тик утыңа
барам һаман,
Синсез – утсыз хәлем тагын да авырдыр,
кайда син?

Башка дус, яр һич кирәкмәс,
синнән иде аерылмасам,
Син – гүзәлләрнең гүзәле, бер җавап бир,
кайда син?
Кайда син – җир һәм күк кызы,
тиңсез җайдагым минем,
Аерылу – агулы ук, җанымда ул, күр,
кайда син?

Чәчләрең хушбуе – мишек,
ул Татар иленнәнме?
Мин, юләр, чәчең исенә хәтта колдыр,
кайда син?

Саба җиле белән килсен
сәлам булып хуш исе.
Мин янам... инде түзәргә әмәл юктыр,
кайда син?

Мәңгелек исерек хисем – син,
син булганда оҗмах – ник?
Син – кәүсәр, оҗмах өстәленнән ризыктыр,

кайда син?

Барча диюләргә каршы мин
күптән ачтым сугыш,
Син – изге чик, син гел кирмәндәй булып тор,
кайда син?

Булсын Нәсимиләр бүген
бөек мәхәббәт шаһы,
Аларны лаек тәхтенә син алып бар,
кайда син?

## *V. Гөлбалага хатлар*
***(1996–1998)***

* * *

Изгеләр, дидем, сез мәдәт бирегез!
...Ирештеме догам? Ярдәм иттегез.

Мәйданда – яңа диваным... Нинди ул?
Элгәрләр – тиңсез остазлар, әйтегез?

Шимальдә шәрекъ гөлләрен үстергән
Бер фәкыйрь мин – газәлдә шәкертегез.

Төркигә гарәп, фарсыдан юл ачкан
Сез – Сараи, Нәвои – ишетегез!

Идел-Уралда бу бабта – «Фөзүли»
Дип ат алган Шәмсетдин Зәкиебез...

Язылды Тычкан елында... Йә, Гаташ,
Бер Ходайга һәм ярга өметебез!

* * *

Күземнең нуры, бел: газәл башладым.
(Күңелем гөле, бу – сиңа багышлавым!)

Хәтердә авылың исеме яңарды:
Юлыккан иде шунда бер яшь җаным...

Дөрләде җыр канда ул чак, буй кызга
Ялварып, яшь койды Ыкка яшь чагым...

Соңыннан – ни? – җилме кисте юлымны? –
Килмәдем «кыйналган» җиргә башка мин...

Күңелнең гөле, күз нурым! Сиңа ник
Яшьлекнең яшерен ярасын ачамын?

Шул көннәрнең пакь хыял-өметеннән
Яралып, бәлки, алдыма басканың?

Шул чактагы кебек яну-тетрәүләр,
Бүген дә хис давылыннан шашканмын.

Яшьлегемә бул син аклау хәбәре:
Гөнаһлымы? Укы соң Гаташ җанын?!

* * *

Гөл туташ! Сиңа дәшәмен: ярлыка!
Дивана гашыйк әдәбен ярлыка...

Аның гомер ядкаре синең алда:
Ялгышкан – язмыш каләмен ярлыка!

Табынган күпме исемгә, йолдыз дип,
Күкләргә ашкан гайбәтен ярлыка!

Фани дөнья гамен-шөгылен куеп,
Гел «Яр!» дип яшәү әхлагын – ярлыка!

Очратканчы гомерен – җан сәфәрен,
Исраф хисен – мәхәббәтен ярлыка!

Күреп сине, үткәненнән ваз кичкәч,
Алда дип белгән хәятын ярлыка!

Гөл туташ, бел: соңлап уянды Гаташ, –
Күз ачкач, шашкан халәтен ярлыка!

* * *

Сүзең балы җам – гөл таҗыннан артык!
Күзең нуры – җанга ялкыннан артык!

Яшьлектән, йә, дәрес алу – языкмы?
Сабый күңелең карый акылыннан артык!

(Гомер хакына табылган тәҗрибәм!
Ярым хакы – синең хакыңнан артык!)

...Чырагтыр син: чәчләрең төсе миңа
Күзем эчкән кояш – яктымнан артык!

Каләмем, әйт: сүздән бумы Ярга таҗ? –
Харәзми йә Хафиз данынннан артык?

Ә бу мизгелдә кем лаек ул таҗга? –
Бармы синнән – Гаташ ярыннан артык?

* * *

Яннарыңнан куган – ул мин түгелме?
Җаныңнан аерган – минем күңелме?

Бәйгесендә сүзнең нишләсен бу баш?!
Гөлбаладан үзе теләп җиңелде.

Хис тулпарым алга чыгарды яшьне –
Җил белән узышу әллә җиңелме?

Моң күлләрем! Нидән арткан суыгыз? –
Күздән аккан ни ул кайнар? – түгелде...

Яныңнан... юк, җаннарыңнан кума, Яр!
Гаташка ул соңгы хөкем түгелме?!

* * *

Бакчада алтын өләшә сентябрь!
Соңгы көне... Әле син дә, мин дә бер...

Уңачакмы бу төсләр, сихри балкыш?!
Бизәкләре көзнең бүген безгәдер...

Такташыбыз каберенә килдек бергә.
Шашкын чор дәһрие! Рухың сизәдер?!

Тугры калырга яшьлеккә, хыялга
Бүген дә бит йөрәкләр ант бирәдер?!

Булсак та башка заманның баласы,
Безне дә, бәлки, хис биек күтәрер?!

Карт наратка сөялеп, күккә бактык...
Алтын язмыш язсын җырга сентябрь!

* * *

Сары яфрак – моңлы хатыдыр көзнең?
Ул – хәбәрдер... Җил, яфракны ник өздең?

Күп афәтле Күсе елыннан сүз-хат.
Ник һәр хәрефе салкын, шомлы ул сүзнең?!

Ул кимерде, бел, минем бәгъремне дә:
Бер елъязма – сары моң эзе йөзем...

Синең баштан да ул урап узмаган:
Җиле тигән! Ярый биргән Хак түзем!

Яшьлек белми үлемнәрне, ул – яшәү,
Тик тидертмик көнчел язмышлар күзен...

«Барлык борчу-кайгылар җилгә очсын!» –
Шулай укыйк, Гаташ, бу хатын көзнең!

* * *

Гомер таңында, җитәкләп, кулыңнан
Алдым сине – адашмассың юлыңнан!

(Кагылдым мин фәкать бармак очыңа –
Сискәнеп гүя сабыйлык җылыңнан!)

Өнсез калдым аннан ихлас тетрәнеп,
Табигать бүләге – яшьлек җырыңнан.

Юл башың бу! Минем дә шундый яшькә –

Йөрәкләрдән, бел, мәрхәмәт кылынган.

Фатиха бирде агайлар! Рәхмәт, дим,
Раббыма – мәңге бурычлы колыннан!

Инде сиңа изге юл тели догам;
Ышан: күңелеңә ихлас дус булыр җан!

Гаташ акылы да (төштән соң!) ялгышмас:
Җитәкләп алдың син дә бит кулымнан!

* * *

Язларың саныннан синең
өч кабат артып киткән
Мин күргән кояш! Шагыйрең
бихисап гомер кичкән...

Бирде гөлләр касәсендә
дөнья чын шатлык, моңын...
Туймадым һич! Җаным юкса
дәрьяга ятып эчкән.

Матурлыкка таба бу юл,
сәфәре – мәңгелеккә;
Суыткан күпме йөрәкне,
күп өметләрне кискән!

Хыял һәм мәхәббәт – бергә,
шул – яшәү мәгънәсе лә...
Бу илдә бәхет тапканның
гүренә ал гөл үскән...

Язларың санынча язсам,
яд итеп газәлләрне,
Әйтерләр, бәлки: «Гаташ та
калдырган һәйкәл хистән!»

* * *

Инде... Мин – синең укучың, бел, бала!
Бирде быел шундый бәхет бер Алла!

Яшьлек килде киләчәктән җыр булып, –
Янәшәмдә якты күзле Гөлбала.

Үзем теләп иярдем яшь тай – хискә,
Сүз башлыйсың – хыял атым кузгала.

Остаз иттем, күңелеңә күңелем бирдем:
Төзәт бу шәкерт хатасын – сызгала!

Юлның инде ахры дип ялгышканмын:
Бер генә кат яшиме җан – дөньяда?!

Гөлбала, дим, ташлама Гаташ җанын:
Ялт иттерден – күптән инде нур анда!

* * *

Кариэм, дим, бармы сабрың?
Әйт, белеп яшь яр кадрен,
Сагынып бармы көткәнең –
ут янып, сызып бәгърең?!

«Яшь гыйшык келәт вата, ди,
карт гыйшык – пулат хәтта!»
Шундый көч-куәт бирсә хис,
мактыйк без ярның «җибер»ен!

Яшьлек соңындамы син, Җан? –
яндыра, дисең, җанан.
Бәхетебез йорты саныйк соң
күкне без – Ходай чатырын!

Сүз-битәрдән саклар безне,
яшерер кинә-күздән;
Бүген без тәхеттә – шаһ бер,
вакытмы әйтер ахырын?!

Уку сабырың җитеп, кариэм,
бу чын гүзәлгә газәл...
Соңгы юлы: – Шашма, Гаташ!
Йә ташлар елар... Акрын!

* * *

Язам – сиңа хатым барып җитәрме?!
Күпме сүзем кала – язып бетәрме?

Чәчәге күпкә бөгелгән гөлдер җан:
Гаме күптер! Яшьлегең үз итәрме?

Түзмәде ярлар шашкын җан йөгемә,
Синең дә наз кылың моңга түзәрме?

Берәүне, бел, күккә дәштем мин кичә;
Җәберсенеп, җырны читкә этәрде...

Аңламады: табыну белән аны
Матурлык иленә биек күтәрдем!

Инде түгел аңа – сиңа язганым:
– Бисмилласы... Гаташ, сүзең җитәрме?!

* * *

Йа Ходай! Миңамы бүләк – кулъяулык?!
Кулга алдык, тараттык – хәйран калдык.

Мең еллардан мирас ил бизәгедер –
Халкым күңеленең төседер бу яулык!

Гөл чигелгән, шунда – бөре чәчәк тә...
Аһ, телләрен белергә! дип уфтандык...

Тик бер хыял итеп яшьлектә көттек,
Күр, бүген насыйп итте! дип сокландык...

Нәкъ Хәлил без, алдык вәгъдә билгесе...
Галиябану өчен җанны кызганмыйк!

Ни көтә алда? Ни сәхнә ахыры?
Саклап булырмы бәхетне? – уйлау юк...

Яшәү матур, Гаташ, гөлләр – мәңге яшь, –
Кулда бит сөю әләмең – кулъяулык!

* * *

Гашыйклар яше ашлаган гөл кыры! –
Мәйданың гыйбрәт өченме чакырды?

Июль кызуы чәчәктәй, җан балкый,
Нинди дәртле, иске бу фонтан җыры!

Якында – каен урманы, сукмагы...
Тоташкан гүя анда да җан нуры...

Шаулы шәһәр эчендә аулак утрау! –
Шунда килде каян йөрәкләр туры...

Каушап, сердәш гөлләрдән ярдәм сорыйм...
Ошармы сиңа, бу сүзләр матурмы?

Кыргый йөзем куагына яшердем...
Ут яна йөзем – сулышың ялкынлы!

Гөлнең яшьсез керфеген үптем, дидем:
– Күкләр дә ишетсен, Гаташ, антыңны!

* * *

Хатыма әгәр тамса яшь – ни диим?
Яшь – ут ул, бәгъремә тоташ – ни диим?

Сүз дәрьямда күбәйде гади ташлар,
Тирәндә энҗе-асылташ – ни диим?

Лаекмы бу наз-сурәт яшьлегеңә?
Булмаса, көл мисле кояш! – Ни диим?

Уй ярымны сарган үткәннең моңы,
Син бүгенгемә шат юлдаш – ни диим?

Җанга салкын, аңлаешсыз бу заман,
Мәңгелектән бул нур-юлдаш – ни диим?

Төшлегеннән соңгы дәвере – җырны син
Биеклеккә чакыр, эндәш! – Ни диим?

Йә, җавап бир, яшь хискә төр... Әмма, бел:
Авыр сүз күтәрми Гаташ – ни диим?!

* * *

Кул изә һаман миңа, яр, кул болга!
Бел: инде бергә без җирдә – бер юлда.

Кул болгап озат – теләктә кал, бала,
Күр: чәчәк изи юлчыга гөл-дөнья!

Кул болга, убылсам уйда упкында;
Тирәндә энҗе эзлим мин чоңгылда!

Буш чыксам да, шат каршыла; елмайсын
Бит чокырларың: чын байлык – без монда!

Кул болга: илһамга минем юл ач син!
Язганым ашсын-ирешсен йолдызга!

Җан үзе дә, ашыгып, ашса Күккә,
Бәхиллек бул Мәңгелеккә – кул болга!

* * *

Бәхетемме, бәхетсезлегемме?
Кем дисен газәл? Кем син?
– Бәхтең мин, күптән көткәнең... –
Сүзсез, син шулай дисең!

Ник мең төрле сорау җанда?
Бу шашудан ни булыр?
Мин югалттыммы әллә соң
үземне аңлау хисен?

Алданаммы? Йә алдыйммы
Сине, җырымны... Җирне?!
Ник бу җил китерә һаман
исерткеч яшь гөл исен?!

Кайда үлчәүләр? Кем белә
күпме моң, сагыш җанда?
Дөрләрме мең кат мәҗрух хис
мең дә бергә яр өчен?

Бүген дә иске яраңнан
газәлеңдә күпме гамь!
Үлем көтсә алда, Гаташ?
– Гашыйклар үлми! – димсең?!

* * *

Күпер аръягындадыр җан,
бирге якта тик гәүдәм!
Кичә-төн үтәм, күперегез
хуҗасы күптән шәүләм!

Күперләр кичеп кенә дә
ярлар ялганмый мәллә?
Ә безне ни аера, Яр? –
Сорыйкмы Хактан ярдәм?!

Күпер аръягында бәхетем:
бу ярда синсез гомер...
Алда ни язган? Юкса бел:
ниятем изге – вәгъдәм...

Узганнар йөген (күп гөнаһ!)
иңнән ташлап булса, аһ! –
Бер гомердән икенчегә
бармы күчкән бер адәм?

Күперләр соң нинди анда –
бәхетлеләр ярында?
Ә бәхет яшерендер, булса...
Кем әйтер кичкәннәрдән?!

* * *

Ни генә әйтер ак кәгазь? –
Онытыла күп сүз – кала.
Языла җанга! Серле күз
балкышыңнан эз кала!

Нинди ул – чорга лаек сүз?
Гасырны каргау җыры?
Халкым, киләчәгең бармы? –
Күп кавем телсез кала...

Бетәрме кадимнән Иран
көндәше Туран нәсле?
Бәлки, шул җәүһәр тарихта:
җырда төрки Кыз кала?!

Оныттырмас халкы данын,
мәхәббәт шагыйрьләрен! –
Мәңгелеккә булыр сакчы:
чын татарча Күз кала!

Язның нәкъ үзедер син, Яр,
үзгәртер нур-көчең бар;
Бәлки, милләт тә яшәрер?
Соң түгелме: көз – алда...

Күңелеңә тапшыра Гаташ
быелгы җәй алмасын.
Тетрәнә җыр, хисләр таша,
сак кагыл син, Кыз бала!

* * *

Очратудан әүвәл җирдә җисмеңне,
Белгәнмен күптән җиһанда исмеңне!

Хәбәр биргән хәтта тууыңнан яз;
Китергән җил, буй үскәч, гөл исеңне!

Искәрткән бер илаһи өн гүяки:
– Бәхтең алда, – дип... – Яшь сакла хисеңне...

Балкый жаным: мәгарәдән чыккан ул –
Сихри нур килеп чакырган өченме?

Синсез гомерем – төнен юлсыз барганым
Түгелме ул, капшанып, көтеп көнне?

Гаҗәпмени Гаташың «күккә ашса»;
Шашты күрүгә, «Яр!» диде ул Сине!

* * *

Ник яшь зәукың тик яңа җыр тели, Яр?!
Бел: гашыйгың борынгы көй көйли, Яр!

...Бу залда соң нинди шаулы җыр бүген?
«Шоу»ның «моң»ын җан тоярга тели, Яр!

Ут урнымы сәхнә? Төтен йә томан...
Җыр шашканмы? Җырчы әллә бии, Яр?

Чор башка, җыр... Син – киләчәк баласы,
Мин үткәндә, артта калдыммыни, Яр?!

Гаташ – хәйран... Син гашыйк чор җырына...
Хаклы булса яшьлек? Кичер мине, Яр!

* * *

Нур илендә гөл син! Гөлгә сокландым...
Гөл янында нурлар! Сезгә сокландым.

Ым белән тик ук-керфекләрен аткан
Наз-вәгъдә белдергән Күзгә сокландым.

Ык тарафында челтерәр чишмә күк
Табигый аккан яшь Сүзгә сокландым.

...Шунда, ахры, газәлең ахыры, Гаташ,
Буй кыз атлы бөек Сергә сокландым!

* * *

Яндырды ник язганы син – баланың? –
«Хушыгыз... Сезне сагынып калам мин».

Борынгы хатлардан үрнәк намә күк,
Укыйм бабайлар... Балбаллар сәламен...

Йолдызларга ашкандыр күпме гашыйк!
Җандашлар кай тарафында Галәмнең?

Сагынадыр безне алар, көтәдер,
Күкләрдән аваз ишетәм һаман мин!

Чыгаргандыр юлыма шулар Сине –
Милләтнең гүзәл мәхәббәт дәвамын.

Мәңгелек ни? Гашыйкларга ул – ватан!
Хатыңны шулай аңлый җан – янам мин!

* * *

Кем кагылган синең сердәш каенга?
Ак тәнендә яра, аккан каны да...

Син кочкансың аны, апаң күк күреп,
Бар да туган сиңа туган ягыңда!

Бу язда бит килде кайгы сиңа да:
Зур югалту уйган эзен җаныңда!

Яныңда, аh, булмадым юатырга,
Каендай сызып елаган чагыңда...

Иртәнге чык-яшь кибәр, китәр кайгы...
Тик җыр башың – язмышың! – шул языңда...

* * *

«Сәерҗан» мин күпләр өчен, күрәм мин.
Кайчак хәтта үз-үземнән көләм мин.

Яшь карашың кызганмасын чал башны, –
Язмыш буенча, Яр, йөри бирәм мин.

Ә йөрәкнең яралы күпме кылы!
Сөюдән өзелер алар – сизәм мин.

Әмма сине үлемсез итәр җырны
Уйнармын соңгы кылымда – беләм мин!

Шул бәхтемә олуг хак куйса дөнья?
Түләрмен бер сәер җаным белән мин!

* * *

Өч айлык нарасый – өмет... үсәрме?
Көн-ай санап, җан бәхетен үлчәрме?

Ул көтә: зур үссен бәхете! Язмышын
Синең исемең белән бәйли – исәрме?!

Ник мәңгелек тарафына күз ата, –
Бу гомерне юкса ак, пакь кичәрме?!

Соңгы очышка әзерли илhамын, –
Канатлары бәен яры чишәрме?

Әhле гашыйклар! Ул сезгә багышлар
Илаhи дип белгән шушы хисләрне...

Өч айлык сабый – өметем! Гаташның
Хыялын тагын чынбарлык кисәрме?!

* * *

Ил картлары! Рәхмәт, төшкә кердегез.
«Диңгез кичерер димче»ме идегез?!

Күздән кичереп яшь Гөлне бәхтемә
Әдәп-вәкарь белән бәя бирдегез.

Куеп нәсихәт-вәгазьне, онытылып:
– Сөбханалла! Милләт кызы! – дидегез.

Тамак кырып, әйттегез мәдхияләр,
Нидәндер кызарган олпат йөзегез...

«Аһ, яшәреп, кабат яшәп булса!» – дип,
Зәңгәр күзләр сафлыгында йөздегез...

Гаташка – кан, тарих тавышы идеме
Төштә сез биргән фатиха-сүзегез?!

* * *

Сүзләрең – җыр, гел яңгырап барыр, дим!
«Сагындым, бел... Сагынам. Сагынырмын!» –

Шулар белән бүген минем җаныма
Ефәктән дә йомшак, матур кагылдың.

Җыр сүзең, дим, гади һәм бөек – анда
Борынгы һәм мәңгегә яшь сабый моң!

Шул моң белән кавышкан җанымны да
Бәхетле, дим, хәтта бөек саныйм мин!

* * *

Миллион халкы булган Казан – синсез – буш!
Мин дә синсез калдым ушсыз – чын биһуш...

Күктән кошлар очып үтте... Ишеттем.
Синең исмеңнән әйтәләр: «Биһуш, хуш!»

Узар алар сезнең йорт өстеннән дә.
Ак каурыен калдырсын бер моңлы кош...

Хат язарсың шуның белән... Беләм тик:
Каләм тоту – яшь кулга «бик кыен» эш...

«Ямьле вә хуш» авылда син... Нигә соң
Уем борчулы?! Җан түгел һич тыныч...

Миллионыңнан берәүне уйлыйм, Казан!
Юат мине, болай сагынмаска куш!

* * *

Сокланырсың бу Диванга: «Язган...» – дип,
Горурланырсың: «Ут-китап! Янган...» – дип.

Әмма әйтсәң: «Бу шигъри сүз-сурәт тик
Хыял бары... Аслы, бәлки, ялган!» – дип.

«Кемнәр салсын колак гашыйк зарына?
Күзеңне ач, бүген кырыс заман!» – дип.

«Матурлык ни? Хуҗа аңа башка көч;
Кара, патша: Җирдә кем пакь калган?» – дип.

Гөнаһланам гына булыр, җаныңа
Шундый шикләр, уйлар керә алган, дип.

– Тәүбә! – димен, искә килеп... Син дә әйт:
– Хаталанды Гаташ... Кичер, Аллам! – дип...

* * *

Иң матур шигырең Синең ни? Беләмсең?
Ул – яшьлегең: тиңсез шуның белән Син.

Тик унҗиде яз күргән наз иясе!
Бардыр хакың – сүзләремнән көлсәң Син...

Матурлык бит күзеңдә үк: күк төсе!
Тугач ук шигърият таҗын кигән Син.

Ни генә ул Сиңа Гаташ язганнар?
Бөек үрнәк – камил газәл икән – Син.

Унҗиде яз – кояш, табигать җыры!
Ахры, Тәңре каләменнән иңгән Син.

* * *

«Бозланган» булса күңел, ул,
әлбәт, яшькә тиң түгел! –
Баш ияр мәллә андыйга
ут күңел, тиңсез бер Гөл?

Ул горур Гөл буй бөгәрме?
Иелә калса хәтта,
Ятка тулы касәсендә
агу гына бирер гел...

Елмаюмы ал йөзендә? Мыскыл –
җан сөймәгәнгә...
Әйтә гүя: яшь бу бәхет
синең тәхетең түгел, бел!

...Акылым җуеп, Гөл дип, мин ул
атылдым яшь катына;
Шашып сөйгән ихлас җанга,
әйтегез, кайчан җиңел?!

Гөлбала, аһ! Юкка, валлаһ! –
Бу энәң – кинәң миңа!
«Боз»мы? Күр: ялкыннан сиңа

чын аять язган күңел!

* * *

Синсез дөньям кошлары – ни? Кәгазьләр...
Рух очышка мисал булыр бик азлар...

Шул кошлардан да бит моңлы җыр көтеп,
Баш иделәр миңа гөлләр-раузалар...

Җан тавышымда – тәҗрибә авазында –
Бар салкын ярларга кайнар вәгазьләр.

Үзгәрттемме, янып, мин бу дөньяны?
Һаман сөюдә шул: сәүдә-базарлар!

Бирерме чын гашыйкка заман бер хак? –
Үлгәч, «аңларлар», кыйссалар язарлар!

Синле дөньям: «Үзең яз, – ди, – зур хисне!»
«Биек оч!» – дип, җаныма дәшә язлар!

* * *

Биек күтәргәннәр – егар төслеләр,
Сурәтләреңдә кемнәр ул көчлеләр?

Нык куллардан төшерми үстергәнме
Милләт кызын ил агасы ишеләр?

Яшь хыялны күкләргә караткандыр
Юл башында әнә шундый кешеләр!

Ник аларны куенына алган соң җир?
Язмышларның көчледә ни үче бар?

Ә шагыйрьне тәкъдир үзе саклыйдыр! –
Мәңгелекнең без белмәгән көче бар...

Тусак та монда, җаныбыз күктәндер:
Тик хыялга – үз, җиргә без – үксезләр!

Рухны шуңа биектә йөртүче без –
Язмышларны җыр итүче «көчсезләр»!

* * *

Авыр бу ел! Гел гамьсез булганнар – юк...
Югалтулар күпме! Табылганнар – юк.

Өметләрнең, хис-хыялларның кабрен
Ябачак гүяки кыш – тик карлар юк!

Сузылды көз – туңа сөюем гөле:
Соңгы чәчәкләрен назлар куллар юк!

Ярның да үз гаме: хәсрәтле җаны;
Белми – яшьтә озак авырганнар юк!

Сорымы көн? Карамы төн? Моңсыз күз...
Агарачак бәхетебез – бураннар юк!

* * *

Сүнгән учаклар терелгәнме, җаннар
Ник ут яна? Кызумы шулай җәйләр?

Нинди җепләр, яраткан бу җаннарны
Өзелмәслек, ныклы итеп, ни бәйләр?

Үтте җәй дә... Алда – көзләр. Ник һаман
Янган хисләр ут сорый – юләркәйләр?!

Йөзеңдә тут – шул учак-ут шәүләсе!
Сүнсә утлар, яндыра теләккәйләр.

Сөю бәйләсен җаннарны мәңгегә!
Ул – тансык ут: яныгыз, бәгырькәйләр!

* * *

Коткарырга теләп сине ялгыштан,
Җан көзгесе – күзләрдәге сагыштан,

Араларга сагыну-газапларыңнан,
Кемнәрнеңдер сүзе, хаксыз каргыштан,

Коткарырга теләп җилдән, давылдан,
Тәгәрәгән ташлар, ямьсез тавыштан,

Араларга заман гөнаһларыннан,
Дошман мәкереннән дә куркыныч «дус»тан –

Туктатырга уйлап Сине, вакытны,
Бар Галәмне – кулыңнан кысып тотсам

Йә торсам җанымнан сине җибәрми,
Саклармынмы котылгысыз шул уттан?

Яклый алырмынмы яшьлек, сөюдән?
Шул бәхеттән көнләр куктән – язмыштан?

* * *

Җирдә шул кабатлана, Яр: Күбәләк
Йөри Гөлне йә бер утны тирәләп...

Әмма ул Гөл, үзе сөймәгәннәргә
Ачулы гел! – гүяки бер тигәнәк.

Җаны салкын, хисе ялган булганны
Куркыта ул: «Чәнчермен, бел...» – дигәләп...

Утка кереп күпме Күбәләк көйде...
Көлендә яңа Гөл үссә ни гаҗәп?!

Без дә мәңгелек Күбәләк-Пәрванә.
Яндыра Ут... Чәнчи Гөл (язмыш-фәләк!)

Күбәләктәй җанга көч, Яр! Матурлык
Чакыра гел: сөй, якынай... бул һәлак!

* * *

Шигырең шәрабын бер авыз итәргә –
Кирәк булган ничә дәрья кичәргә?

Сусаган җан! Гомер уртасын узгач,
Килде мәллә бәйрәм арган хисләргә?

Багышланган касәң, сизәм, ут тулы;
Яшьлек сүзең исертмәсме? Нишләргә?

«Тора, дисең, яшәү тоташ ялкыннан...» –
Шуңа эссеме сүрелгән кичләрдә?

...Яндырды шигырь шәрабың – җавабың...
Дивана җан! Тели һаман эчәргә...

* * *

Илбашының юлы бүген – Иранга!
Якташың ул... Кагылырмы Ширазга?

Сәясәттән бушап, форсат табармы
Шигырь кәгъбәсенә дә баш куярга?

Ул Сәгъдиләр Гөлстанында бүген
Түгел дәһри: юнәлде рухи Хаҗга!

«Хөрәсән ялкаулары» дип, мөгаен,
Татар шагыйрьләрен алмас мисалга?

...Беләсеңдер, Яр: без – Таһраннар өчен
Үз халык күптән! Мәгълүм бу дөньяга!

Фарсы-төрки арасында юл иске:
Суытмадык эзне, хисне азга да!

Илбашыбыз – шуңа Хәйям кунагы;
Шагыйрь булып кайтсын илгә – Казанга!

* * *

Төнге шәһәр гашыйклары! Килегез,
Шашкан җаныма сез бүген кирәгез.

Урам ташына баш салган халәтем,
Хисләр яндырган сәгатем! – күрегез!

«Мең дә бер»ме? Аннан да күбрәк кичә
Узды йокысыз күзләрдән – белегез.

Яшерен рухлар, борынгы ияләр! Сез

Уйларыма нурдан бер юл бирегез!

– Бу Казанда булды шанлы гашыйклар!
Бул аларга чын дәвамчы! – диегез.

Шул яну да уятмасмы кыз җанын? –
Илаһи бер дога кыйлсын берегез!

* * *

«Яр» сүзеннән качма! Үзе Яр атлы
Тәңрең сине яр булырга яратты.

Яндырырга йә сүндерергә түгел,
Күңелләрне балкытырга яратты!

Бирде сиңа ул шундый илаһи көч:
Ярты дөньяны нурыңа каратты.

Буй кыз хакы, җирдә өстен синнән ни?
Бер карашың ук гомеремне яңартты...

Алдым мин дә шундый кодрәт сөюдән:
Җан өрдемме? Сүз-сурәт чәчәк атты...

Тәңребез, бел, нәкъ үзенә тиң итеп
Яратты безне – шуннан бу Яр аты!

* * *

Ә мин хәзер төн-кичәләр кешесе –
Чүлләр үтеп, серле сахра гизүче!

Сөю дәрвише мин – ярын урлаткач,
Эзләп, уй-атта моң-дәрья кичүче!

Караңгыны ярып бара күңелем, ул –
Йолдыз көтүләрен бушлай көтүче...

...Нур иленә еракмы юл, әйт, күңел?
Шунда минем төнемне көн итүче!

Тик, көн тугач, сер – ак хыял югалса?
Таң-чишмәдән алсу өмет эчимче.

* * *

Бирсә миңа сөю хакын бер Аллаң,
Рәхмәте, мәрхәмәте киң, бел, һаман!

Соңласын яз, килсен салкын – барыбер
Атып чәчәк, тулышачак җан алмаң!

Табигатьнең илаһи кануныннан –
Сөюдәндер! – җаннар сизгер яралган.

Яшьлек күгендә моң-болыт тик кунак –
Гамь дөньясы да бер бездән калмаган!

...Үтмәдеме читләп зур хис Гаташны?
Кабат сөю хакым булса, бир, Аллам!

* * *

Рәхмәт, Газәл! Ярдәмеңә таяндым,
Назың берлән – Яр җанына таяндым.

Хезмәтеңә тайяр булып, Гөл туташ,
Гашыйкларның базарына таяндым.

Бәһа куйдың зәгыйфь бу җыр кошына,
Канатландым – мактавыңа таяндым.

Бар дөньяга төрки сүзне таныткан
Шагыйрь ирләр мәйданына таяндым.

Яр каршында гаҗиз башыңда, Гаташ,
Мең сорау... Бер җавабына таяндым!

* * *

«Алты гына» аймы күргәнгә Сине?
Мин «борынгы мирас» димен хисемне.

«Алиһәм» дип табындым Җир кызына...
(Гөнаһлы җан! Языгын белмисеңме?!)

Әмма Синсез, яшәвеңнән хәбәрсез
Гомерем өчен кызган бер бәхетсезне!

Һәм минмени чын гашыйк дип ат алган?
Күр бу ялган «шаһ»ны – таҗ, тәхетсезне...

Гүзәллеккә «көнем өчен» бакканмын,
Денем өчен түгел! Кичер юньсезне!

Сине күргәнче һәм Синле дөньям бар!
Аңлый Гаташ, башка ялгышмас инде.

Тапса да бәхетен тик гасыр ахрында,
Мәңгелеккә хәзер ул җуймас Сине!

* * *

Көзләрме тик? Күзләрең бит сихерли:
– Матурлыктан ачтың яңа бер сер, – ди. –

Алтын төсләр булып күчсен җаныңа
Уй дөньяңны балкытачак фикер, – ди. –

Әнкә телдә ихлас сүз белән килгән
Җан шәүләсе, моң рәсмедер – шигырь, – ди. –

Хис-сурәтең тик җәй узгач чәчәктә?!
Җимешеннән чын гамь тәме килер, – ди.

Кызганмый як җаныңны бу утта – ян!
Түгел бер мин, аны Галәм күрер, – ди.

...Газәлеңә, Гаташ, Ярың фал ачты:
– Куз-күмереңнән үрләр ут. Ул – гомер! – ди.

* * *

«Газәлләр ятлап үсәсең,
ахры, шуңа гүзәлсең!» –
Җаныңны күрә белгәннәр,
сөеп, шулай сөйләсен!

Газәл ватаныннан – кайсы,
Шам, Ширазмы уеңда?
Миңле төрки Яр карашын
тойдыңмы нәркистә син?

Газәл багы – Ирәмдәдер,
ни дип өзелә былбылы?
Әйтәме: «Илең моңыннан
язмыш мәхрүм итмәсен!»

Газәл белән өйрәндеңме
илаһи сөю телен? –
Мәңгелек серен? Шундый Яр –
кемгә илһам бирмәссең?

Газәл диваным ит сәйран,
җаның, аһ, булса хәйран!
...Гаташ – сакый, шәрабы – җыр,
мәңге сусау сизмәссең!

* * *

Син якында, Егерме беренче йөз!
Сиңа бер җыр җанымда – Ярга бер сүз:

– Арды, ташып узган чорлар сагышын –
Еллар моңын откан гашыйк ике күз!

Гөлбаланың гөл исле хуш уйлары! –
Җуймассызмы мине мәңгелектә сез?

Бу диваным – ярсу бер ел йомгагын –
Егерме бердә, алып бер, сүтәрсез!

Сагыштан, бәлки, куярсыз чайпалып,
Мине саклап йөрткән диңгез-күзләр, сез?!

...Егерменче йөздән Гаташ аһы бу:
Нишләр дөнья минсез – рәдиф-газәлсез?!

* * *

Сиздекме без... сизмәдекме – ул узды:
Йөрәкләрне очраштырган ел узды!

Бер мизгел ул – бер ел Галәм каршында,
Ә бит җаннан гүя мең давыл узды!

Тузгыды чәч, елгадай – яшь... сөртер кем?
Маңгайда эз сызды – Язмыш-кул узды.

Йөрсәк тә без икәү тапкан сукмактан,
Рухта, бәлки, һәркем үзгә юл узды?!

Әмма уртак тоташтырган уй юлы –
Яктырды җыр – илаһи нур гел узды...

Беренче бу – җирдә бергә әйләнү;
Түгел нәүбәт-гомер, бер ел... шул узды!

* * *

Икәүләп илһам көтәбез:
мин – синнән, син – Алладан...
Күңлеңнең килсә рәхиме,
мин җырны һич алдамам.

Күзләреңдә күк томан ник?
Борчылу бер, моңсулык...
– Никтер җан бушанды, – дисең, –
куркам яза алмаудан...

Сүзләрең – үзе үк шигырь,
иң ихлас, табигый җыр!
Ә минем җырлы бу халәт
синең җанга ялганган!

Күрәм: күп анда хыялның
ишеген ачар сүзләр!
– Көттердегез ник бу юлы? –
дип сорама алардан...

Тик язып өлгер: ташыр бер,
ташынып килер җырлар!
Аһ, шул бит бәхте шагыйрьнең...
Аерма, Ходай, һаман!

Җыр дөньяңда югалып син,
онытсаң да барлыгым,
Өркетүдән куркып бәхтең,
ул чак мин тын да алмам!

**КЫШКЫ ГАЗӘЛ**

Йөзеңнеме өтә ут – ялкынлы хис?
Йөрәгеңне! – тоймас ул салкынны һич.

Дөнья гүя бүген сиңа эссе җәй!
Кышкы күк тә ак хыял чатырың ич.

Бага шуннан ай, йолдызларның күзе:
Җирдә – гөлләр, пакь җаннар ачылыр кич!

Хис кичәсе... Ашкын уйлар зөфафы... –
Мәңгелектә ул язылып калыр ич?

Матурлык, син әллә вакыт гөлеме?
Галәмара утмы ул – яндырыр көч?

* * *

Чайпалыр да ташырдыр җанымнан хис!
Чайкалыр да егылыр алдыңа сүз!

Яшь матурлыктан исергән бу башым
Кулыңа ал – колак сал аһыңа, түз!

Яшерен дип белгән уйларым, сез күптән
Көнгә чыккансыз – зар-җырга тулгансыз!

Бәһа бирегез шул халәт-хәлемә,
Яр күзләре – иң биек йолдызлар – сез?!

Чайпалды да түгелде хис – гомеремдә,
Фаш булды сүз – ышан: гөнаһсызлар без!

* * *

Ут янам... ә синдә – зәңгәр салкынлык.
Җыр язам, хат... меңгә бер җавабың юк.

Сихерләде мәллә сине көнчел көч?
Әллә минем бу бәхеткә хакым юк?

Буш чәчәк атса хыялым агачы?
Һаман да илдә шәп исем-атым юк?

Билгем – Кучкар, фигылем – ут... Балыкка
Йөзәр дәрья – яшем... Ник юк якынлык?

Ни аера һаман бу чиксезлектә?
Аңлар өчен дә, гомер, шәт, вактың юк?!

* * *

Күңелем аңламыйсың, и Яр,
бәлки, балалык белән?
Телем алмыйсың – үртисең,
ахры, наянлык белән?

Яшь ярга тиеш үзгә наз,
кирәк сүз кушу аңа
«Ефәкләрдән нечкә хәйлә»,
шигъри чаялык белән.

Күпме акыл бирде дөнья –
сабак күп калдырдым ник?
Яшим хәзер мәхәббәттә
шактый наданлык белән.

Хис – карт шәкерт, урны һаман

мәдрәсә сәкесендә;
Сиңа пакь догам – ант итәм
ак җан – намазлык белән!

Хак бу сүзем, бел, Гөлбала:
чал башым синең алда
Иелгән – көл сипмә аңа
берүк хаталык белән!

* * *

Минсез ниләр били синең җаныңны!
...Аякларың кочкан – шашкан чагымны

Искә аламсың? Минем елап тезләнгән,
Синең салкын, горур, таштай чагыңны?

Мин һаман да шул халәттә, күзләрем
Эзли күктән шунда ашкан чагыңны.

Йолдыз идең, ай идең син ул кичтә! –
Мин белмәм дә бугай башка чагыңны!

Туган көнем һәм «төш»ем, ахры, димме:
– Йә, җиргә төш! – дип «уяткан» чагыңны?!

* * *

Быел сүзен дөнья бик кырыс әйтте:
– Бала булма! – диде ул. Дөрес әйтте.

Икейөзле күзгә карап алдаса,
Чынын гүя, бәреп, туры дус әйтте.

Караштанмы аңлап арган җанымны,
Назлы бер сүз яз карашлы Кыз әйтте.

...Синнән гайре бар да – үгет йә киңәш,
Сабак бирде сабыйга – дәрес әйтте:

– Башың җуйма сөеп бу яшьтә, Гаташ!
– Зөлфәт – үлмәс! – диде, Мөдәррис әйтте.

* * *

Ник килмисең? Бәгыремне ник өзәсең?
Минсез үзең ничек шулай түзәсең?

«Гашыйкҗан»нан, дим, шулай качып булса,
Үз җаныңнан нигә әле бизгәнсең?

– Киттем, – дию, карарың белдерүме?!
(Бу газәл әле бетмәде – китмәссең...)

Сине – миңа, мине сиңа караткан
Җыр язмышын – шагыйрә син! – өзмәссең!

Тәңре хаклар, дөнья яклар хисләр бу!

Салкын булса да җаның, фаш итмәссең!

«Башын киссәң, тагы үсә тал»... Ә сөю?
Соңгы гомере бу Гаташның... Кисмәссең!

* * *

Юлбарыс елының кыен язы бу!
Кырыс – гүя чал ирнең яшь яры бу!

...Ямьсезләнә ник күз алдымда дөнья?
Ахырзаман! Шуның шомлыклары бу!

Матур, дисәм, дус-ишләр... Күр: карт, төссез...
Мин – яшь, имеш... Хыял шуклыклары бу!

Нинди язмыш: яз белән көз – бергә без,
Табигатьнең, ахры, ялгыш пары бу.

Әллә күкләр шулай кушканмы, Гаташ?
Хисләрнең саф, илаһи, кайнары бу!

Быелгы сәер яздан җыр – сиңа, Яр.
Сүрән генә елмаеп, әйт: – Ярый бу...

* * *

Нишләтим җанның шашынган гадәтен?
Бу – сине көтеп, ашкынган сәгатем!

Кәгъбә иттем сине – күңелем юнәлттем.
Сиңа барсы – сәҗдәм һәм гыйбадәтем...

Ходайдан җәза булыр... яшь яр өчен –
Белгән догам онытылган халәтем...

Аһ, бу көтү! Хәбәр көтү! Наз көтү...
Дөнья сөйләр, дим, тиздән, риваятем...

Тик ишеттер тавышыңны, бер җавап бир! –
Аңла димим аксакал мәхәббәтен!

* * *

Җырда ярый зарлану... бары – Ярдан!
Ул мең яхшы иргә, дөньяга зардан!

Сакла, Аллам, күз яшен кәсеп итеп,
Йомшаклыкны бер һөнәр кылганнардан!

Кызгандырып теләнгән хәерчедәй,
Елап, шәхесен сатуга барганнан!

Мөнафикъ шагыйрьдә ул зар – җиңел дан –
Дәрәҗәгә астыртын омтылганнан.

...Яр өчен зар яши тарих җанында.
Мирас алтын җырлар – шул елаулардан!

Синең дә, Гаташ, газәлең – ихлас яшь...
Аерырмы Яр бүгенге ялганнардан?!

* * *

Рәнҗешемме төшә, яшем катымы?
Үз-үземне тиргим ничә кат инде!

Күңелемнең мондый гадәте каян? –
Ярын каргау, үч... ир өчен ят инде!

Йә хисләрем уты, караш сихреме? –
Күз көчемне сыныйм йөз кабат инде!

Хаста хәлеңә аптырап калды баш,
(Менә, Гаташ, тагын җавап тап инде!)

Бәлки, сүздән – күп мактаудан тия күз?
Язмасам мин, яшь тиңнәрең шат инде.

...Терел! – кайтар тилереп язган чакка,
Һәм шул хакка булса да ярат инде.

* * *

Нишлим соң? Юаныйм укып,
Тукайдан бер моң-җырын:
«Син чабак тик Иделдәге,
күрсәтәсең койрыгың...»

Йә, ни әйтим син – Балыкка,
шундый оста йөзгәч соң?!
...Йолдызы шундый булгач, дим,
тотар шул Хак боерыгын...

Үзгәрүчән, шома, матур –
аерылмый ялган, чыны...
Файдасыз – күпме чәчсәм дә
үгетемнең орлыгын!

Үз юлыннан тайпылмыйча
барачак галәм кызы!
Үпкә сүзе нигә, шагыйрь?!
Аңлат хисең зурлыгын!

Кермә нәсихәт багына –
анда гашыйкка юк гөл,
Һич оялма, җырла һаман,
алдану горурлыгын!

Ахры, шул язган Гаташка:
олылау шундый ярны,
Йолдызчылардан ким белми
ул җаннар йолдызлыгын!

* * *

«Синдәйләргә – ихлас җанга – авырдыр?
Раббым, шундый гашыйкларга сабыр бир!»

Сүзләреңнән яшәү эчте гариб рух –
Сеңлем, назла җанны шулай тагын бер.

Мәҗнүннәрне якла – зурдыр савабы! –
Дога багышла – әрвахлар хакын бир!

Моң сарган ак башын сыйпа берәүнең –
Бәлки, Җирнең бер әүлия ярыдыр?!

Матурлык эчсен күзләрем яшьлектән! –
Байлыктан бит зәкят алу ярыйдыр?

* * *

Газәлләргә тиңсез азык – гүзәлләр!
(Сөймәү үзе – шиксез, язык, гүзәлләр!)

Күпме җырга – безгәчә һәм бездән соң! –
Гомер биргән, күпмесен Сез – өзгәннәр...

Гашыйк җаннар, бөек ирләр, ярлыкап,
Сөйгәч, холык-фигълегезгә түзгәннәр!

Үзгәртергә мөмкинмени Хаваны? –
Алар Адәм васыятьләрен белгәннәр.

Ә ничек бар шулай Сезне яраткан
Шагыйрь кадерен белгәнме сез, дилбәрләр?!

Зәүкы өчен, уйнап, җаннарны кыйган
«Шаян»нар, чын гашыйктан тик көлгәннәр,

Сезнең онык бүген мине газаплый;
Бөекләрдән, бәлки, киңәш сүзләр бар:

– Нишләтсә дә гүзәл яшь Яр – бәхиллә...
Тик яшәсен Гаташ аһы – газәлләр!..

* * *

Сиңа ошармы бу бүләк – ядкарем?
Ни кичерсәм, язган Көн-дәлекләрем...

Ниндидер бер сихри нурың кагылгач,
Җанда үскән яңа Гөл-дәлекләрем!

Янган минем яшьлекнең шәп китабы! –
Көле – монда, Сиңа Көл-дәлекләрем?!

Күңел-дәлекләрдә яңа бәхетемме?
Булыр мәллә буш Өмет-дәлекләрем?!

Бел, дәфтәрем – түгел антым көннәргә –
Ай, елларга!.. Ул – Гомер-дәлекләрем!

* * *

Мең сорауның тапса бер җавабын, дим,
Җан дөньяңның гаувасы – җаным минем

Дөнья серен ачкандай аваз салыр! –
Бүген гамьнән шаулый тик каным минем!

Син – борынгы төрки кызга тиң, горур,
Ахры, очты, күп кайнап, сабырым минем!

Яшәү фәнен гашыйклардан укыдым –
Тик тойгыга китте акылым минем!

Ник калдырган соң алар ут мирасы? –
Варислыкка лаекмы асылым минем?!

Синең дөньяң – өр-яңа гасыр, ә ул
Бәяләрме бу хис-алтыным минем?

Бүген зур хак дауласа Гаташ, шаулап,
Ни иртәгә сиңа ул даным минем?!

## *VI. Миңгүзәлгә газәлләр*

***(1998–2001)***

* * *

Туганмын, бел, мин дә... Син туган елда!
...Булганмын кем Сиңа кадәрге юлда?

Кыйлганмын ни дога, кемгә табындым? –
Күп аллалы – потлы иде ул дөнья.

Пәйгамбәргә кадәрге яшәү, бәлки?
Пәйда булдың – килдем чын, дөрес уйга.

Кырык елда кырык юлга чәчелгән
Сүз-гамәлнең җыйдым мин очын кулга!

Һәм ваз кичтем, валлаһ, Синсез иҗаттан.
Имзам – хәрам синнән гайрегә – җырда!

Хәмер, ялган, гөнаһлар сарган җанны
Юсын синең күңелеңнән изге дога!

Бел: сөюдә нәкъ яшьтәш сиңа Гаташ,
...«Тарих башы» диик Син туган елга.

* * *

Төштә – кем? – көткәнең үзе – Яр килде.
...Назларың бүлде дә: «Инде яз! – диде. –

Яңгыраса исемем шашкын хисеңдә,
Киләчәккә шул әллә бармас? – диде. –

Төр аны син сулмас гөл – тиңсез җырга,
Саф яшеңнән яралсын алмаз! – диде. –

Ян да син яз, яз да шатлан – бәхетеннән,
Шул язмыштан чын гашыйк армас! – диде. –

Хыял эчсәң былтыр тик җан җамыңнан,
Дан-шәраб койсын быелгы яз! – диде. –

Әмма җырда күккә ашсаң, бел, Гаташ:
Җуйма мине – җиргә төш бераз!» – диде.

...Тәнкыйть «сөюче» мин эреп тыңладым;
Яр-шагыйрәм! Төштә дә остаз иде...

* * *

«Сусадым», «яндым» дип, нәфсем,
син кайларга очмадың?!
...Гөнаһ-тауда кунып, таңда
шуннан иде төшкәнең, –

Башың күтәрергә кыймый,
оялып көн-күзләрдән,
Саф күңелләрдән качыйм дип,
булды тирләп-пешкәнең!

«Тәмам түбән төштем, беттем
ил каршында» дигәч, соң
Ничек тураеп кабаттан
шат халәткә күчкәнең?!

Каян бу – онытылу фәне?
Ни ул – чара, дәвасы?
Аңлаталмыйм... Тоям ләкин
зуррак теләк үскәнен.

...Тезләреңә (кәгазь итеп) яшем язган
тәүбә, Яр!
Нинди ул! Шулай кабул ит,
үзгәралмам һич тә мин! –

«Уттай кызган, Гаташ, җаның...
Еракмы әле кичкә?» – дим...

* * *

Әй-йа, күңел! Тәүбә кыйл, кайт
Хакка, «Аллаһу!» – диген.
Хуҗа Ясәвичә, син дә
сәҗдә кыл һәм: «Һу!» – диген.

Шагыйрь рухы, сүнмәс хисе
сыяр шул иҗеккә дә!
«Валлаһи, ике дөньямда

чын ихлас сүз – бу! – диген. –

Бөек мәүланадан васыять! –
мең еллык изге аять!
Бүген дә син, денсез гавам,
кальбең-рухың ю! – диген. –

Тән белән пакьме без, Мәүлам?!
Кичмәде кемнәр җирдән,
Саф иман, гөнаһ-языкны
уйларымнан ку! – диген. –

Бакырганига рәхмәт әйт,
Ясәвигә кайт кабат! –
Бул шигыреңә тугры, ләкин
эчтән: «Ләйләм! (Лу!)» – диген.–

Тәүбә кыйл, тәүбә, нәфсем, Син
гел чәчләр тозагында,
Ә ул гөнаһмыни? Сөю –
мәңге яшь калу!» – диген.

* * *

*(Бер мәҗлес хатирәсе)*

Зөһрәсе исмен телгә алу
тыелган, аһ, Таһирга;
Җыруына кертсә ярын,
тиеш баш югалтырга!

Йә илдән сөрәләр аны –
аерып Зөһрә-җаннан.
Әзер зур сандык-язмышы,
дәрьягамы атарга?

Ә ул газәл әйтә әле,
саз чалып... Яшерен аның
Нәфрәте хаин ханга һәм
җанкара Кол батырга!

Ерак патшалыклар алда –
Шад, Бәгъдад, Ирәм иле...
Кайдан да кайтачак шагыйрь:
Зөһрәсе – җыр чакыра!

Әле хан, бикә бәйрәме:
ялгышыр тиздән Таһир,
Яры исемен әйтер, сизми –
сөртенер җыр атында!

...Әй, Гаташ! Түгелме шушы
чын мәхәббәтнең шаһы?
Зөһрәгә – үзенә хыянәт
мөмкинмени Таһирга?!

* * *

Узды бу яз... Гөрләде, тынды сулар,

Басылмый ник җаныңдагы ярсулар?

Җирдәге бар сил-ташкыннар шундамы?
Ул ил-халык гаменнәнме борчулар?

Сәясәткә сәяхәт иткән җан тиз
Тынлык сорар: туйдыра шул шау-шулар!

Мохитме? Күр: күпме көнче, гайбәтче,
Хөсетлектән «илһам», ямь табучылар...

Ә Гаташың көтә көн-төн язганын...
Юләрдер ул: «Яңа китап! – ди, – шулар...»

* * *

Йә, авылда көннәрең шәп үтәме?
Укып Ахматова – «Анук түтәй»не!

Күзалласаң яшерен сөю юлларын,
Уең ерак Парижларга китәме?

Күңел язы кумирыңның бер җәйдә
Шунда узган... Ул да татар бит әле!

Анна... Белла – гөлтаҗмы урыс башында, –
Бу газәлем тарихка әр-битәрме?

Авылыңда син, сызам эчтән: көннәрең
Минсез уза... Шик-уйларым бетәрме?

...Ахматованы укып, дим, сагынсаң,
Гаташны түгел, яшь, горур бүтәнне?

* * *

Ил хәтерендә калырмы бу кичәләр? –
Безнең хискә сарылып җилләр исәләр!

Аһ, кадерлем, сизми дә калдык: күчкән
Күңелебездән басмага сәхифәләр.

Сәер, кайнар безнең сөю шигырен
Бу дөньяда ничек кабул итәрләр?

Мәңгелегендә дә булып матбага,
Берәр бит багышлап безгә бирсәләр?

Аерыммы без, бергәме ул дөньяда? –
Иркәкләр һәм корткалар, кыз-бичәләр?

Оҗмахта да ачлык игълан итәр җан,
«Җанашыңнан аерым яшә!» – дисәләр.

Чыккан Гаташ яры белән журналда...
Буяу исеннән сәрхуш без – исәрләр!

* * *

Шагыйрәм! Күр: тагын Шигырь бәйрәме!
...Бәйрәмеңә сөю, зур хис бәйләме:

Эссе, якты, нурлы, чуар... мең төстә!
Шулдыр, бәлки, уртак хыял – әйт әле?!

Күз-карашлар безнең кайда төбәлде? –
Балкый алда милли хөр рух һәйкәле!

Быел да ул дәште мәйданга безне, –
Очрашсын җаннар – гөрләшик, әйдәле!

Яшә, Тукайлы сәхнәбез! Шунда бит
Без – тигезсез икәүнең тиңсез роле!

* * *

Хаксызга әйтсәм каты сүз,
җавабыңда, яшь күңел:
– Бу – сезнең хөкемме? – дисең, –
ләкин ул гадел түгел!

...Тауларга бәрелеп, кайта сүз, –
ярсып, дулап йөрсә җан:
«Зыялым, кайда сабырың? – ди, –
затың бит җаһил түгел:

Күпме нур иңгән җаныңа –
төшкән Күкнең рәхмәте –
Кодрәте бу! Бел, бәгъзеләр
догасы кабул түгел!»

...Син хаклы, уйда күп зәхмәт! –
Куар, дим, кай «Карәхмәт»?
Һәм хөкемдар түгел гашыйк,
белә бит: камил түгел!

Танырдыр Гаташ гаебен,
өметсез димә аны...
Холкым... Яшь җаныңа, бәлки,
яр булу җиңел түгел?!

* * *

Кем ул? Экранда сурәте кем дисең?
(Гаташ, әллә гөлдәй сулган йөзле син?!)

Тамак төбе белән, ашыгып сөйли...
Сүзләрендә мәгънә бармы? Нинди соң?

Сәясәттән, сәнәгатьтән бихәбәр, –
Газизем, нинди яшәүгә өндисең?

Дөньяның иң вакытсыз вакытында
Ник син хисләрең тарихын сөйлисең?

Каян килдең, кай йолдыздан? Җирдә тик

Сөя белгән җаның ник яшермисең?

...Шул сурәттән мәллә син мине танып:
– Ул минем пәйгамбәрем, изгем! – дисең.

* * *

Шатмы хисең? Сездә бит Пасха бүген:
Олы бәйрәм илегездә – олы көн!

Мәңгелек яшәү билгесе – буяулы
Йомыркага да төшә булыр күзең?

Алсулаткан бит очыңны яз, кояш,
Оялудан мәллә ут яна йөзең,

Үпкәч күпләр, дип: «Гайсә терелеп туды!»
(Уйда күрәм ачык берәүнең эзен!)

Казанда мин, кулымда кулич, сиңа
Ишетеләме: «Чынлап терелде» сүзем.

Гаташ җанына да бәйрәм олы көн,
Сөюдә булгач пакь иман Син үзең!

* * *

Миңгүзәлгә бу газәл-хат Миңъярдан,
Язгы сәлам миннән – сабырсыз җаннан!

Шартлап ачыла бөреләр хисемнән,
Бу – тәбрикме җанкардәш туганнардан?

Лаләләрнең сере күзендә... Сүзсез
Гөнҗәләр – якты җыр белән тулганнан.

Васильево – урыс саласында мин;
Шунда – мәчет, илһам алам азаннан...

Янсуарда ниләр? Көннәр, һавалар?
Нинди көчләр таптың җаныңа яздан?

Аерылганга өч көн... Күп бу! Шуңа мин
(Миңгүзәлгә Миңгаташ!) газәл язам...

* * *

Ни телим синнән, һинд гөлем? Тик «Телим!»
Дип кычкыра, яшеренми, күзем, телем...

Чәчләрең тузгыган чакта мин шашам,
Ә нинди назда сихерли көлүең?

Сүз-гамәл, тән-җан туктаусыз сугышта,
Кем җиңсә дә, мин ул – корбаның синең!

Үпкә, каһәр утлары сүнде күптән,
Тоташ дәрт-ялкын биләде күңелем...

Яндырган яшерен бу утның соңы ни?
Яңа гасыр! Сиңа шулай керүем...

«Яратырга телим...» дигән Гаташ мин,
Чынлап, «бөек сусау» мәллә гомерем?!

* * *

Йә, әйт: кем мин сезнең яшь «даирә»гә? –
Исмем белгән һәр шәкерт, талибәгә?

Әйтәләрме: мең ел соңлап туган җан!
Әмма мәгърур һәм хистә «галибанә»...

Ни ямь бар – бу матди, кырыс дөньяда
Алданмаса берәү чын «шагыйранә»?

Бик акыллы, тик залим булганнар күп!
Ул диванадыр: «итүче шөкранә».

Табынып гел сөйсен син – сеңлебезне,
Газәлләрдән «гөл үстерсен тирәңдә»!

...Йә, нинди ул сезнең яшьлеккә Гаташ?
Сөйләрсеңме шулай син «мәхбүбә»м дә?!

* * *

Җаным! дим, наз сорыйм синнән тагын мин,
Шаштым бугай, оныттым «языгы»н мин!

Багам сиңа – сүзем шул: ике күзем
Һаман ач, бел, көтә җан азыгын, дим.

Чәчләреңнән аяк очкача – мәйдан,
Үбүләрдән шунда дастан языйм, дим.

Гөнаһмы хис, мәҗүси көч Гаташта?
Язмыш язуыдыр, шәт, «азуым», дим!

Пакьлә җанны, ю яшеңдә, беләм бит,
Җиңә алмыйм бу теләк-арзуым мин!

* * *

Җанан, нәнүс! Укы – рухта һаман үс...
Безгә бәхет «аз юрый» Нострадамус:

«Фетнә башы» ди ул, Балкан бәхәсен...
(Гашыйкка да аң булып тору фарыз!)

Беләм, үсәрсең фикердә... Бу Җирдә –
Дөньяда ник артмый акыл бер карыш?

Фаразлар: тик афәт, һәлакәт алда,
Хакмы шул сүз: «бар да ахырына бармыш...»

Алайса, ник арта ярату хисе?
Бетү алдыннан алдыймы соң язмыш?

...Җанан, нәнүс! Кочсын Гаташың сине,
Җанымда үс... Үлемне уйлау – ялгыш...

* * *

Агыласыз, меңьеллыклары Җирнең!
Ашыгасыз – кушуымы Тәңренең!

Егерменче йөзнең ахрыннан карыйм,
Таныйм җан узган юлларны, кадерлим.

Мең газаплы, ләззәтле хис тарихым!
Җирдәге һәр эзеңне мин хәтерлим.

Һәйкәлләрдән, сөю, күпме хәрабәң!
Нинди чорлар аша уздың, хәтер, дим.

Лаекмы соң яңа меңьеллыкка мин?
Гөнаһлардан тәүбә, хисап әзерлим...

Йолдызым сүнсә тиз яңа дәвердә?
Мең саваплыдыр – хис табар әҗерен.

Сиңа сакларга мәхәббәт маягын!
Бул дәвамчым, бул догачым хәзер, дим.

Синең хакка күккә ашсын соңгы җыр,
Күкрәгеңә салам башны, кадерлем!

* * *

«Сихри бер миң саклый гаурәт алмасы... –
Ди төштә кем? Әллә гөнаһ алласы? –

Төн ягында, күз төшмәс урында, – ди, –
Гаҗәеп тап – нәкъ лаләләр ярасы...

Йөзендә – илаһи мөһер... Бу – башка, –
Чиксезлектән әллә йолдыз карашы?

Ә бәлки, ул уй-теләктән яралган,
Нәфеснең сер төсе, гөнаһ баласы?

Ник саклана шул билге күздән яшерен,
Бармы көн белән кавышу чарасы?»

...Уяндың да шашып төн уртасында,
Гаташ, нинди газәл иттең язасы?!

**ДОГА**

*(А.Ниһат Асьядан)*

Моң яңгырап торыр манараларым
Берүк азансыз калдырма, Иланым!

Килсен һаман изге бал кортлары, син
Умарта-йортсыз калдырма, Илаһым!

Шул манараларны күккә әйләгән
Изге язусыз калдырма, Илаһым!

Чын мөселман йортын, халкымның рухын
Син рамазансыз калдырма, Илаһым!

Йә ку, тарат көтү күк калган илне,
Тик һич чабансыз калдырма, Илаһым!

Ә безне сөенечсез, су-һавасыз,
Ягъни ватансыз калдырма, Илаһым!

Чын мөселман йорты булган Ватанны,
Аһ, мөселмансыз калдырма, Илаһым!

**ГАЗӘЛЛӘР ДИВАНЫН ТӘМАМЛАУ**

Егерменче гасыр! Сау бул, исән бул!
Дияр вакыт... Әйтербезме: без бәхил!

Корыч куллар, таш җаннар дәвере булдың,
Тик кешедә яшәү хисе исән, бел!

Бездә дә сау милләт уе... Җилләрең
Татар өчен һаман каршы исә гел...

Искитәрлек: юлыксак та каһәреңә,
Без һәр чорда ташны тишеп үскән гөл!

Туган тел! дип җырладык телсез килеш,
И газиз тел! Утлар, сулар кичкән тел!

Шуңа Казан – төрки рухның мәркәзе,
Түгел Ташкент, Бакы яки Истанбул!

...Сөя белгәннәр гасыры! Узмый тор,
Гаташның бу диванына ватан бул!

# *VII. Робагыйлар бакчасы*
***(1991–2001)***

**БАГЫШЛАУ – БАШЛАУ**

* * *

Робагый, син – борынгы сүз бостаны! –
Бул бүгенге язарымның гөлханы.
...Сөембикә илхан! Нугай кураең
Моңнары бу: бездә аның илһамы...

* * *

«Нәкъ Казан арты»ннан – изге тияктән,
Тукай әнкәсе күмелгән төбәктән
Килә һаман бер өн – җырга фатиха,
Тарихи наз булып милли йөрәктән.

* * *

Аерма халкым гаменнән, йа Раббым! –
Тугач та бу җанны илгә караттың.
...Мәхәббәт орлыгын салдың син аңа,
Ихлас хис, пакь яшь өчен дип яраттың.

* * *

Җыр ике мең ишеген шакыганда,
Багышлавым – ул Сиңа, гадел Ярга.
Китабымны ирештер яңа йөздә
Исемемне яд итәр гашыйкларга!

**ӘЛЛӘ ДӨНЬЯДА БЕР ЯШӘП КИТКӘНМЕН...**

**Соң түгелме?**

Чит-ят җирнең кояшы үз түгел ник? –
Йөзем үскән яктан кабат күчендек...
Кан кардәшләр илгә кайта, туфрак, аһ!
Бабайлар ник синдә калган? – Төшендек!

**Дәрийгъ**

Шаулы заманның болганчык су-җыры
Күпләрне моң чишмәсеннән аерды...
Колак түгел, җанда сафланып болак,
Ул бәндәләр, дим, милләткә кайтырмы?

**Шагыйрь, җиһангир...**

Яр данлаган Хафизны кызганган бер,
Ярлы санап, аяган Аксак Тимер...
Хафиз җыры ничә җанны баеткан! –
Синең байлык кайда? Сөйлә, җиһангир!

**Бүгенгебез**

Илаһ саз, син тоташ моңнан гыйбарәт,
Нинди көчләр кылларыңда, Тәңреме, әйт?!
...Сезнең шул саз да уятмый – таш җаннар... –
Шундый без бүген, әй, Тукай, Дәрдеменд!

**Үзгәрмәгән**

Тукай да сәяхәт иткән... җай булган.
Әстерхан, Уфада озак – ай булган...
Пайтәхетне дә күргән... әмма горур
Рух тәхтендә чын таҗлы Тукай булган!..

**Гасыр башы йолдызлары**

Ялгыз булганмы Тукай? Юк, бәхеткә...
Казанда таянган Фатих, Сәгыйтькә...
Гаязга дәшкән: «Кайтчы!» – дип. Сыйган бит
Берьюлы ничә арыслан тәхеткә!

**Шагыйрь үзе белгән булыр**

Оренбур да чакырып дәшкән бугай –
Бармаган ул. Ә барган булса Тукай?!
Җылыныр идеме җаны?.. «Кайда да
Бер кояш» бит?.. Үзгә, бәлки, читтә ай?

**Сөйләшү**

– Тукай, Дәрдемәнд бер очрашкан булсалар,
Бер илаһи гәп, дим, алар корсалар?..
– Шәп манзара... Тик ул табынга, Гаташ,
Без сыймасак әгәр – чакырмасалар?

**Шагыйрь язмышы**

Гомер юлын сүтеп, берәү шагыйрьне
Җырыннан гайре күзаллый алырмы?!
...Үз юлыннан үткән Тукай язмышы, –
Җыр-тәкъдирдән узып шагыйрь барырмы?

**Әйтерләрме...**

Әйтерләрме: «Каһәрле шул елларда
Бар дөньясы гүя акыл җуйганда,
Денле итте бит безне шигырь-вәхи,
Чын аятьләр онытылып торганда!»

**Бер Ходайдан**

Егерменче гасыр татар шагыйре!
Азмы изде сине дөнья җәбере...
Өстеңдә иде Газраил тырнагы...
Язарга көч... ул – Хакныңмы әмере?!

**Тиз айнырсың**

Син дә, шагыйрь, иркәләү-назга хаклы.
Күрдең ләса яла, бәла, нахакны...
Ә исереп бер йоклап алсаң сөюдән,
«Айны» дип ник заман?.. Йә яр яңаклый!

**Бәгъзеләр**

Утыз ел әләк ташып, тарат гайбәт,
Ошакчы бул, ялачы – яз шикаять.
Аннан, оялмый, күкрәк сугып әйт: йөрәк

Халкыма чын мәхәббәттән гыйбарәт!

**Шулай ла...**

Көнчел, хөсетле бер җан бугай ла...
Андый түгелләргә дошман бугай ла...
Шул үзен тиңсез каһарман күрсәтер
Ярлык сорыймы милләттән? Уф Алла...

**Яңа пәйгамбәр кайда?**

Пәйгамбәрлек юлы ни? Потка каршы
Чын Тәңре өчен дау һәм үлем тарихы.
...Бүген дә потка табына күп кяфер,
Ник бетми бу Әбү-Җаһил варисы?!

**Лутилар бар**

Лут пәйгамбәр чорыннан гөнаһлары...
Ник күбәя шуларның тарафдары?
Фәрештәңә дә тиярләр... йа Раббым,
Шул гөнаһтан коткар без татарларны!

**Яшерен, «гөнаһ»лы сөюебез өчен тост**

Әдәп-әхлак «ирке» канат җәйгәндә,
Ихлас җанны бик азлар санлаганда,
Безнең сөю – пәйгамбәрлектер, Гаташ,
Табигый хис көлкегә саналганда?!

**Җырда ни генә юк бүген**

Нинди фал бу? Арка бирдек әдәпкә,
Җырда – фәхеш, исерек рухы, гайбәт лә...
Ир – зәкәре, хатын – фәрҗе дәртендә, –
Әдәбияттан качтымы гаурәт тә?

**Гөнаһым – үз башыма**

Гаепле мин: гел аны хурлап тордым,
Барын яшереп синнән, югын арттырдым...
Көткәнгәме ирештем?.. Юк, Сиңа аны
Кызыклырак күрсәттем – яраттырдым!

**Вәгазь генә димә...**

Парың белән күренгәч, шәп ханым, дип,
Килсәләр дә «гашыйк булып», җаным, дип;
Парыңнан аерылсаң, кайсы шуларның
Кулын сузар, Бул мәңгелек ярым! дип.

**Бергә икән – бергә**

Уралдым мин гамь-моңга, сизмәдем дә...
Бәлки, ураганмын аңа сине дә?..
Шулай булса шатланыр идем, тагын
Бергә без, дип, хәтта зар хөҗрәсендә!

**Соклану**

Җаның юктыр йә ул таштыр, билләһи!
Җаны бар күптән яратыр, билләһи.
Күккә ашкан «аһ»ыма исең китми,
Ну, дим, мишәрдә характер, билләһи!

**Үземне юату**

Тормыш – кыйбат, назлар арзанайганда,
Ихласлыклар онытылып барганда,
Гаташ җанын аңламавың гаҗәпме? –
Тынычландым, юрап дөнья яманга...

**Үткәндәме... үтмәгәндәме?**

Күрешүләр көтмәдем мин – бәндә,
Күрештердең, Уфам, көтмәгәндә.
Үткәндәме булып кайттык? Әллә
Яңа юлга бактык – үтмәгәнгә?!

**Үз нәфсемә, башкага түгел**

Рөхсәтсез – канатсыз сиңа очалмыйм!
Ичмасам, тиргәнеп гамьнән бушаныйм.
Бу халәттә кемгә нәләт? Нәфсемә...
Бәласе булыр, башкадан «үч алмыйм».

**Башкалар өлгергәнче**

Ни җырым бар – сиңа барып җиткәндер,
Ни серем бар – кәгазь барын түккәндер.
Бер хәбәр бир! Һич югы, хурла җырны...
Өлгергәнче гайбәт... йә «дус» – бүтән бер...

**Өндә ни күрәчәкмен?**

Төш күрәм: даным ирешкән һәр җиргә –
Сезнең атаклы авылга... Сембергә...
Хәтта син дә җырларыма баш идең! –
Тәгаен бу – өнемдә сүгелергә...

**Үз шигыреңне көтеп**

Ә синдә күпме илһамдыр яшьлектән,
Ул – ачкычтыр сер-сихерле «ящик»тан.
Тиңсез шагыйрә бул! Ә мин укучың
Булырмын, җир яңгыраткан шатлыктан!

**Ничәнче кат яшәү бу?**

Әллә дөньяда бер яшәп киткәнмен?
Һәммәсен бер күргәндәй хис итәмен...
Хәтта сөю таныш... Мең еллар элек
Синең өчен үлмәдемме, иркәм, мин?!

**Тагын исердем**

Күңел яшьлегемдә барын кичердем,
Җиткәндер, дидем, картлыгы хисемнең;

Башка китеп елмаюың ширбәте,
Бал сүзеңнән үсмердәй нык исердем.

**Җанның үз кайгысы**

Тыпырчына тере җаным учыңда! –
Әллә кайларга очарга очына...
Ул мең елдан Җирен сагынып кайтса,
Очрата алмам сине дип борчыла.

**Хиснең чишмә башын уйлап**

Исемең оныткамын: Гөл йә Ал ханым...
Истә синнән хистә сабак алганым.
Сөя белми, надан, дип бер кугач син,
Бу көнгәчә юк аттестат алганым!

**«Мемуар яза» калсаң...**

Күпме гыйшкымны фаш итте язганым,
Тәнкыйтькә дә азык бирә «азганым»...
«Яр» дигәннәр яклап бер сүз дәшмәде,
Соңгы өметем син, аклап яз, җаным!

**Сиңа тайяр җаным**

Мәңгегә, яр, бу җаным тайяр сиңа,
Җан сафлыгы – пакь яшьләр... алар – сиңа!
Һәр кич синең офыгыңда баеп, җан
Терелер иртән: мәңгелек таңнар – сиңа!

**Хәзер мин елыйм**

Әй еладың син бер... кем җырлаганда?
Борынгыларның моңын тыңлаганда.
...Яшьләреңнең тоям тозын иренемдә –
Син киткәч тә... шул мәлне уйлаганда.

**Синең хакта түгелме?**

Ачылганын сизәм иске ярамның,
Ишетсәм башкортның «Кәрвәнсарай»ын:
«Янмай микән йөрәккәе кис ятканда...»
Янмыйдыр шул... – Синең хакта бу, ярым...

**Җыр да «заманча», бәлки?**

Байлыкка алмаштың шагыйрьне, димме?!
Әллә мактыйммы миллионер иреңне?
Куркам, бүген җыр да инде башкадыр, –
Фәкыйрь хатынын сөю дан китерерме?!

**Үз-үземә аптырыйм**

Гомер узган саен күрәм: начар мин!
Язгым белеп, язмыштан качалмыйм.
Бер дивана гариб мин, һөнәр белмәс...
Кемнәргә гыйшкым ачмадым! – нахал мин...

**Күпме сынарсың, дим...**

Үтми ник сине сөюем газабы?
Бәлки, җиңеллек китерер азагы?
Тәңремдер син! Ул да шулай бирә бит
Яраткан колына зуррак җәзаны...

**Бәхетемнән аермагыз**

Сукыр теләгә ике күз... Ә мин – шат,
Сукыр итсә дә илледә мәхәббәт.
Тик җитәкләп йөртсен генә гөл ярым,
Шул бәхетемнән көнләшмәгез, җәмәгать!

**Шагыйрьләр язмышы**

«Булмаганны сөйләп, жендәй, чүлләрдә
Яши» ди шагыйрь турында Коръән дә.
...Ә «булачак» юлында күпме шагыйрь
Башы китәр – әйтмәгән пәйгамбәр дә.

**Бер тар күңеллегә җавап**

Ни үзгәрсә заман, үче адәмгә ич,
Юк, барсы да һаман шигырь җанына көч:
Тик «тырнасын» каләм, шул да җырга дошман,
«Ашка төшкән» проза «тараканы»на көч!

**Шунысын да онытма**

Елыйсың, «бездә, дип, гаруз, бәхер үлде...»
Чү, бетеренмә алай син, бахыр, булды.
Бел, халкыңда бу йөздә, кояш күрми,
Карында ук ул ничә шагыйрь үлде.

**Әйбәт кеше**

«Дустым!» дип, җайлап, дошманлык эшлиләр
Бу заманда «дус»лар синең ишеләр.
Күз дә йоммый аннан «сылап сыйпый»лар:
– Ә барыбер, без бик әйбәт кешеләр!

**Шигърияттә «ирекле» чор**

Ирекле шигырь! «Чын ирек тудырдык»,
Кемгәдер без зур мөмкинлек булдырдык.
Баш ватуга җырда ничә ел китте!
Шаккатуда Парижларны уздырдык.

**Кайбер ханымнарга**

Күз-Кояштан, яңгыр-сүздән бикәсен
Яшереп, саклый ир-хуҗа шәмсиясе! –
Тар булса да, «ирек» сагындырса да,
Чишмә юлын пакь тотар ир киртәсе...

**Укучыма, баштан ук**

Робагыйлар күңелеңә хуш килмәсме?

Укучым, аһ, җан азыгы бирмәсме?
Кинәң калса йә киңәшең булса, яз!
Кабул итәр, шиксез, Гаташ «фирма»сы!

**Нинди генә сәүдәләр юк...**

Гаҗәп булмас, кайсы ки, бәгъзеләргә
Очрашканда шулай әйтсәң әгәр дә:
– Җан сатуда нинди уңышлар синдә;
Базарыңда гөрлиме сәүдәләр, йә?!

**Бөекләрнең шигырь мәктәбендә**
**рәдиф-шәкерт булгач**

Горурлан, «фәннән чыкмады» башларың!
Авыр дип, укуны ташлап качмадың!
Идән юдың, бил бөктең хәлфәләргә,
Иллендә үк хәреф таный башладың?!

**Йомгакмы, уймы...**

Булдың, Гаташ, Хәйямнар бакчасында,
Робагыйлар яңгырашы җанында...
Әһле каләм ни әйтер дип уйлау юк,
Яратмый яр, дисең, таш атса шунда?!

**ӘЛВИДАГЪ**

* * *

Йә, бу алтын җырга хак та алтынмы?
Илһамчым, әйт, ничек түлим хакыңны?
Зурмы, нәниме – һәйкәлең куярмын,
Алтыннан булмаса, сүздән коярмын.

* * *

Җырда сине тагын күпме күтәрим?
Аштың җиденче катына күкләрнең...
Менгән саен ераклашсаң да миннән,
Төшә калсаң, бел: җирдә дә көтәрмен.

* * *

Ачы сүзеңә дә ачуым килми – ник?
Яратуым гел арта, кимеми – ник?
Салкынлыгыңнан ялкыным үсә тик,
Дөньям яна – бер сиңа күренми... Ник?

* * *

Хистән исерек идем, һаман айнымыйм.
Яшьлегең җиңде – җиңелдем, аңлыйм мин.

Егылган килеш йолдызга кул сузам,
Бар бик сәер гадәтләре җанымның.

* * *

Аерылу һич көтмәгәндә булдымы?
Куркып уйлый идем күптән мин моны...
Барсына рәхмәт; үкенәм шунсына:
Гөлгә күмалмадым киткән юлыңны.

* * *

Күпме сер җанда – чишәргә хакым юк.
Гафу сорап баш исәм дә хакым юк.
Хис кенә, аек уй өчен акыл юк...
Һәм акыл җуеп сөйсәм дә хакым юк!

* * *

Сездә ниләр? Бездә көзләр, «нәзкәй бил»!
Кемгә ничек? Минем бәгърем кисә җил...
Соңгы сүзең кырау булса да җанга,
Үҗәтләнеп, анда әле үсә гөл.

* * *

Хат язармы яшьлек! Үткән – ни аңа?
Күпне кичергән йөрәк еш яза ала...
Үлемме йә ярлыкаумы, Алиһәм,
Яз, бер хат-хөкемең белән җәзала!

* * *

Минем өчен язмыш кулы булдымы,
Чәчләреңнең тузгыды да дулкыны,
Ияртеп китте еракка... Йөрәккә
«Саклан, упкын!» димәдең лә ул көнне!

* * *

Матур уенга маһир син, билгеле,
Беләм бу фәнне димисең, билгеле...
Хауа әбекәң ун мең елдан үрелеп,
Кайчан биргән горурлыкка өлгеңне?!

* * *

Ярый әле калды миндә сурәтең...
Шуңа карыйм, килсә сине күрәсем...
Сөйлим аңа, шигырь укыйм, баш иям...
Дәшми рәсем, ачуың зур, күрәсең...

* * *

Сиңа каршы юләр хис баш күтәрде,
Көнләшүем, шигем дулкыны бәрде...
Хәзер тынган, бик юашланган күңел,
Җәй узган шул, көннәр көзгә үзгәрде.

* * *

Бер «гөнаһлы» уй килә гел, көн туса:
Бүген хисем сиңа сәер тоелса...
Аңлар аны киләчәк... Сине анда
Моңнарында алып барса бу кыйсса!

* * *

Синең миңа ни әйтсәң дә иркең бар...
Барсын да гафу иттерер күркең бар...
Әмма мин дә бәхетле, күр: сөюнең –
Урлап алмадым! – шаһ тажы – бүркем бар.

* * *

Синең күзләр, ни әйтим, тиңсез алар...
Яшькелт-соры... тапсыз, гөнаһсыз алар...
Карашыңда гүя асылташ яна,
Артык горур... ә бәлки, әрсез алар?!

* * *

Гашыйклар газәлләр язар, гүзәл яр!
Рәдифтән, газәл соңында, рәдифләр...
Исемеңне рәдиф алдыннан язмадым:
«Илгә фаш булсак», нәселең гаепләр!

* * *

Яшь табигатьне аңламыйм, янәсе...
Мүкләнгән, мыжык бу җаным, янәсе...
«Безнең бәхәс, үпкәләшү, сүз, – дисең, –
Буыннар арасында дау һәммәсе!»

* * *

Бу акылсыз эндәшләрем куркытса,
Йә оялтса сине, илдә сүз чыкса...
Ашыгып баш тартма, гөнаһлы җирдә
Чын бәхетең нәкъ менә шушы булса?!

* * *

Әллә каян килә аваз яңгырап:
– Барсы да үткәндә инде, бел, ерак...
Тезләренә баш куйган чагың уйлап,
Эзләренә яшь кой... Бу көй – «Әлвидагъ»!

**ТАРАФЛАРГА – ХАТЛАР**

**Миннән аерылгач**

Йә, әйт: синең яшь күңел канәгатьме?
Тулпар – ерак... турыгызда кем аты?
Иярсез тай булса, егып качса ул? –
Атланмадым әл дә, дип, әллә шатмы?

**Яшем тота калса**

Һаман оныта алмыйм – моңа бәхилдер...
Рәхим-шәфкать белми ярлар... Ә син бел!
Синнән калмас уем... Китсәң, кайда да
Сине бер тотар шигырьдә яшем, бел!

**Йомшак сүз ишеткәч**

«Сөйгәнем...» Миңамы шулай дигәнең?
Тәкәббер яр сүземе бу, гүзәлем?
Кырыс күзгә, битәр-әргә күнде җан,
Кинәт йомшап куйсаң, түзми үлсәм мин?

**Хис бишеге шунда**

Икәү йөргән урыннар искә төшеп,
Хатың саен сорыйсың: «Урман ничек?
Таныш сукмак, карт таллар?..» Шулар ласа
Бала хисне алдап тибрәткән бишек.

**Сәхибҗамал – Кандалый даны**

Сәхибҗамал абыстайның оныгы
Түгелме син? Пәрәү кызы туруны?
Рухи бабам, шиксез, Кандалый хәзрәт,
Илгә фаш булса да сөю – урынлы!

**Башны иеп киләсе бар**

Аның ире, имеш, бизнес короле!
Королевасы ниндирәк? – кара әле...
Шикәр кебек йөзеннән байбикәнең
Мәрхәмәт көтәр көн, бәлки, бар әле.

**Олы җанлы ханымга**

Алиһәләр таҗын йөрткән ханымга
Багышлавым – колы иткән ханымга.
Зур гөнаһлы уем да аңа – моңарчы
Ярлыкарга көче җиткән ханымга!

**Базар хәле – гел хәтердә**

Ефәкме, атласмы иде күлмәгең?!
Белмәдем, шашып кочтым тик тезләрең, –
Ә ник истә калган «Ирекле хаклар
Кайчанга үсәр?» дигән сүзләрең?

**Сәер көнләшү**

Синең белән күреп, күпләр «Ай, шәп пар!»
Дип сокланыр дисәм бүген, матур яр...
– Мөгаен, түрә хатыны... – ди ирләр.
– Тунын күр, аһ... – дип «бәяли» хатыннар.

**Шуннан куркам**

Исем китми «Волга»лы күршеләр дип,
Күп мал таба хәзер чос кешеләр дип...
Чын байлык – Син... Урлый алмыйм, куркам мин,
«Мәкәрҗә»дән ирең кайтып төшәр дип.

**Ай-һай!**

Ала карга килеш бөркет булмакчы!
Тәһарәтсез Күк катына бармакчы...
Янмый гына гашыйк данын дәгъвалап,
Язмый гына шагыйрь аты алмакчы!

**Нинди яну булгандыр**

Быелгы кыш... кош оча алмас салкын...
Юлга чыкты миндә ул нинди ялкын?
Поездларны, вокзалларны ут алды,
Сиңа капты килгәч, китте ис-аклың!

**Яшьлек халәтендә**

Яшьлек үтә. Яшьләр үсә – яңалар,
Җырлар түгел кичәгечә – яңа алар...
Ярата белгән өчен дә безне Хак
Һаман бер халәттә тотып җәзалар!

**Олуг юбилей җитсә**

Олыгайсак беркөн? Чын картлык килсә?
Җанны гамь авырайтса, тәнне чир җиңсә?
Нишләрсең, Хис? Безнең сергә илле яшь,
Юлга чык, дип, Уралдан җилкәй иссә?

**Оныклар дәвам итсен**

Ялкын тулы бу хатлар кемгә, дисәң,
Мирас алар дөньяга безнең хистән.
Сөю сүзе! Бездән дә шәбрәк итәр
Оныклар язсын – язганда без истән...

**Эзләдем, таптыммы?**

Бай Уралның бер фәкыйрь төбәгенә
Килдем нигә? – кышын, язын, көзен дә.
Хәзинәме, ниләр эзләдем әле?
Киткәч белдем, күпме гәүһәр күзеңдә!

**Чәчләреңне сагынып**

Чәчләреңдә шарламалар... Исемдә!
Күзеңдә шаян тамчылар... Исемдә!
Шул чәчләрне ябынып йокламадык ник
Бәхетебезнең саф яшьле иртәсендә?

**Онытып булмый**

Төшме, өнме идең, һич аңлый алмыйм,

Назларыңны тоям гүяки, таныйм.
Яшьлегең бер сихерләп исертте лә...
Ахры, мәңге шул мәлдән айный алмыйм.

**Переделкино истәлеге**

Ул кышның хәтердә ак, җылы бураны,
Уйда таныш станция перроны...
Поезд алып китте сине, мин шунда
Соңгы үбүеңнән шашып тораммы?

**Яшьлек мәңге узмаса?**

Вакытлар да сине оныттырмаса?
Йөрәк шулай «акылга утырмаса»?
Нәрсә булыр – ул шашкын хис «гаебе»
Җуелмаса бездә? Яшьлек узмаса?

**Язмыштан шагыйрь качармы?**

Такташ хатынының күреп яшь якташын,
Ул гүзәлгә гашыйк булсаң, Гаташым,
Упкынга илтсә дә сөю– язмышың...
Язмыштан кем – Такташмы? – баш тарткан соң?

**Синең күзләрдә калган кич**

Калды бу кич синең күзләрдә, кичер!
Килсәм аны кабат эзләргә, кичер!
Ихлас хисем, шашкын бу җаным өчен
Очрый калсаң төрле сүзләргә, кичер!

**Тагын мишәр авылы шул**

Әйт, нигә соң һаман Бүләр ягына
Омтыла җан, Көрнәлене сагына?
Керәм дип анда бер гүзәл багына,
Юлыксаң җыр, мишәрләр таягына?!

**Котылу юк, ахры**

Горур гүзәлләр, аһ, сәбәп табарлар,
«Тиңсез хисләр»не дә кире кагарлар.
Сөеп үлсәм дә, исемемне синдәй бер
Матур, тик салкын мәрмәргә язарлар!

**Әйтерсеңме?**

Борын заман түгел, шушы елларда
Инфляция ханым хан булганда:
– Үзгәрмәдең, рәхмәт! – диярсең кебек,
Тамак өчен шаһлар да сатылганда.

**Үз йортында**

Тугры бер яр эзләп читтән хәятта,
Үтте яшьлек... Гомерем уза хәтта...
Әйттең очрап: Күрше, ник күренмисең?
Оныттыңмы? Без – сездән өске катта!

**Көнләшмәсеннәр**

Көнләшмәсен миннән синең хәләл яр!
Килешми миңа – мәҗнүнгә – хәрам яр!
...Көнләшсә, шушы җырларны ул язсын,
Ә Гаташка илһам килә, хәбәр бар.

## БЕР ЙОЛДЫЗНЫҢ НУРЫ

**Кереш**

«Мең дә бер кичә»дәнме ул? Кем сүзе?
Гашыйк җанга, бәлки, Җәбраил үзе
Әйтә төштә: – Сине аңлар бер яр бар, –
Эзлә шуны... Ул – шаһ Әфраим кызы...

**Ак канәфер сүзе**

Бүлмәдә бүләгең синең – ак чәчәк:
– Күңелеңә, – ди, – гаҗәп аклык иңәчәк!
Яңа йолдыз калкыр анда... Көндезен
Янса да ул, исемен Чулпан диячәк...

**Каләмнән – сиңа сәлам бу**

Сиңа ихлас фатихам бу – каләм бу!
Юл башында теләгем бу – сәлам бу!
...Ничә кояшка табындым... Гаҗәпме
Тагын берәү чыкса балкып? Галәм бу...

**Гади бер көн иде**

Килдең – «Ирәм гөлләредәй» күрендең,
Бүлмәм шат авазга, нурга күмелде.
Язмыш каләме язды – Хак куштымы
Ямьләтергә сиңа шушы көнемне?!

**Сурәтең шундый бугай**

Яшькелт күзең, алма битең, каш – кыйгач...
Эшләпәңә капса утың, ялкын чәч.
Күзем туйган кебек булса, нур эчеп,
Сизәм ләкин: күңел карыным тагын ач!

**Күпме теләк үлде?**

Бактым да эзләп үземне күзеңдә...
Ай-һай каты караш икән үзеңдә:
Ихтыярсыз кызардым – шактый әрсез
Теләк туып, үлде «тыйнак» йөземдә!

**Башта ук күккә күтәрдем**

Кагылырга кыймыйм өрфия тәнгә,
Кулларымны бәйли ни ул бу мәлдә?

Җаным белән җаның аңлашты юкса,
Түзәм, Алиһәм дигәч син гүзәлгә...

**Горурланырсыңмы?**

Бер күрүем җитте – хис шашып китте,
Дулкынланды уй-тойгы, ташып китте.
Үлдем, беттем... Йә, тантана ит, ханым,
Кайтмас юлга тагын бер гашыйк китте.

**Ак канатлы**

Сурәтеңне тиңлим Югары затка,
Фәрештәгә сине охшаттым хәтта.
Әйтерсең күк: җырың да күккә ашсын,
Тотын миңа... тик канатны каралтма!

**Бу елдан бәхет көтимме?**

Бу язда да сөю – яшерен сер, чәчәк...
Ирләр аңа юл эзләп баш ватачак
Эт елы бу! Бәхетле итсәң мине,
Дошман нишләр? Дусларым шаккатачак...

**Без яраткан шәраб ни?**

Хафиз Ширази йә Хәйям касәсе
Исерттеме безне ул кич? Нәрсә соң?
Әйттек: «Йөрәкләр дәвасы – мәңьеллык
Шәрекънең шигырь шәрабы яшәсен!»

**Бу заманга да хас**

Кем сөйли шаһның алтынчы хатынына
Гаҗәеп саф «мәхәббәте» хакында?
Тетрәп киттем, оялу хисе дә әле
Калган икән бит гашыйклар халкында!

**Ахматова искә төшеп**

Кулыңда, аһ, нәфис перчаткаларың...
Берсен җирдән иелеп алдым, ханым...
Ахматова искә төшеп, тезләнгән
Хәлдә калдым! Җиңелеп калдым, ханым.

**Гашыйк бу баш**

Учларыма кысам сине, газиз баш,
Нишлим, җәллим, башсыз, акылсыз булгач...
Мең дә беренче кат исмең кабатлап
Елый Гаташ, тик бер көнгә аерылгач.

**Борынгыча хис**

Нindидер көч ханәмнән кубарганмы?
Син юкта, шашып, бүлмәңә барганмын:
Ишегеңә шигырь укып, ачыл, дип,
Тупсаңда йоклап киткәнмен – арганмын...

**Аһ, зодиак билгеләре**

Нинди җиңел сөйләшү сеңелең белән!
«Бизмән» билгесенең телен мин беләм...
Кучкар белән Үгезбозау очрашса,
Гел сөзешә – йә, нишлим синең белән?!

**Бары сине уйлап...**

Сеңелеңә иң матур сүзләр әйтимме?
Күрмичә апаңны мактыйм, мин тиле...
Гөлдәй әнкәгез алдында баш иям,
Бәлки, уйлап бер үзеңне... тик сине?!

**Сезнең бүлмәдә бер уй**

Нинди телдә сөйләр бәхтем йолдызы?
Гитарада фәкать урыс җыр-сүзе...
Йә һинд көе... Ярый бар үзебезчә
Елмаючы сез – ике татар кызы!

**Кем исеме?**

«Гөлфәмә» дигән яңа сүз ишеттем,
Гөлнең яңа төредер дип хис иттем...
Белдем: татар хатыны исеме! Ходаем,
Кодрәтең, Күк кызынамы иш иттең?!

**Юатыгыз, гөлләр**

Күктән – затың, исемеңдә нур-балкыш бар.
Тик ник салкын? Җанда шуңа сагыш бар.
Бик тәкәббер туганыгыз, яклагыз
Сез мине, гөлләр! Миләүшә, ландышлар!

**Фән арыткан булыр**

Студентка булсаң, бер хәл – аспирант...
Шул акыллы мәгърурәдән наз сорап
Уңармы җан, килгәч, качып китсәм мин
Фән арыткан йөздән куркып, аптырап?..

**Бәйрәм көн килерме?**

Сусаган саен мин җылы сүз-назга,
Ераклаша гына өмет бу язда.
Ни бу, и Яр? Суфыймы мин, гашыйкмы?
Таңы юк төн... Гаете юк ураза...

**Кыз күңелендә ни уй?**

Син таләпчән! Тәнкыйтең-фикереңә
Колак салам, хәйран мин белемеңә!
Ә үзеңә багышланган шигыремне
Тик мактыйсың... Ышан кыз күңеленә!

**Ачыктан-ачык язам**

Рәхмәт сиңа, миңа килгән нурың бар,

Җавап булсын! Сиңа ихлас җырым бар.
Яшеренмичә, янып омтылуым хак...
Көнләсәләр? Гайбәткә дә урын бар...

**Шулай булмасмы?**

Куркам, яшьләрчә уеннарга тартсаң,
«Арбаңа утыртып, җырың җырлатсаң?»
Ансы бер хәл... Чал баштан көлеп туйгач,
Ил-көн каршында кыйнатсаң, елатсаң?!

**Җанымның бәхете**

Күпме елатты җанымны бу хәят!
Гашыйк, имеш, җиңелдем мин мең кабат...
Бәлки, әдәп белергә дә вакыттыр?
Йә, сөйгәч, сөелү тиеш, ниһаять!

**Мин түгелме?**

«Бәхет бирәм дияргә юк хакы да,
Байлыгы юк, чамалы акылы да, –
Күккә дәшә, хыялына чакыра»,
Шулай дисәләр «әфәнде»ң хакында?!

**Сөйлиләр**

Көлә дус-ишләрең: – Күр, баламыни?
Хыялый бер – җир йөге аңамыни?!
Ник кулларын селтәп һаман очына?
– Шагыйрь бит ул... – Ала-ай... Диванамыни?

**Җанымны син аңла!**

Янды бу җан! Алдымы бер шөһрәт-ат?
Юкса бүләккә лаек ул мең кабат.
Күрсен соң кем? «Бөек хис»не аңлардай
Зирәк хан юк... Кемгә илтим шикаять?!

**Нәфесең зур, ай-һай!**

Ни тели, әйт, чама белмәс бу җаның?!
Нишлим тагын? Янмадыммы мин? Яндым...
Илгә тиңсез гыйбрәт ит мине дисәң,
Ә бу җир ни? Язмадыммыни? Яздым.

**Көлке түгел**

Рәхмәт, сөю, гамьле иттең чал башны...
Шат, ваемсыз дип кем әйтер Гаташны?!
...Бүген дә ул, ярын каһәрләп, аңа
Бәетме... васыятьме язып маташты...

**Алдан күрү миңа да хас**

Төштә күрәм барсын дисең алдан ук,
Яшисеңдер төшеңә өн ялганып,
Мин дә күрәзә... уеңны бик беләм,
Тик күз йомам – яшим сөеп... алданып.

**Аякларың авыртмыймы?**

Әллә азагын уйламый, матурым,
Сине бу хис кыясына чакырдым.
Аякларыңны канатса кыен юл? –
Кызганып куйдым үзеңне, акыллым!

**Шулай итсәң, ә?**

Хурларга иде сине бер сүз белән...
(Мин, ахры, тик назлый торган сүз беләм.)
Тиргәп, каргап китәргә иде, – иртән
Килеп җитәргә, үкенгән йөз белән.

**Үссә... үлсә...**

Синең җанда тиңе юк бер гөл үссә?
Минем җанны шаштырса ул, көйдерсә?
Һәм тилмертсә? Өмет өзеп, мин киткәч,
Үзе тетрәп, чәчәген койса? Үлсә?!

**Олыгаюның әйбәт ягы**

Шат дисеңме? Уйныйм гына – башка мин...
(Оялчан йә кызу идем башта мин!)
...Читен хәлгә куяр идең, яшь ханым! –
Үз-үземнән көлә белгән яшьтә мин...

**Җанның бар җәүһәрен**

Әле авыр хәлем! Сөеп, бөләм бит,
Җанның бар җәүһәрен сиңа бирәм бит.
Таланган күк ялангач ук калсам? Юк,
Байыйм җырга... җыр кадерен беләм бит!

**Сүз... эз...**

– Сәер дә, түгел дә кебек бер халәт...
Ни булса да, – дисең, – ихлас син, рәхмәт.
Башны әйләндергән сүзне еш тыңлау
Ярамыйдыр, бәлки? Шулай да рәхәт.

**Саубуллашу**

Менә – җырларым! Шәп чыкты, күр имди.
Илһам бирдең, яттан сөйләп йөр имди...
Фикер, сурәтен күзеңнән урладым, –
Китәм дисәм, хәзер рөхсәттер имди?!

**Эзләп барганда**

Газәленнән аерылган мин – рәдифме?
Кәрванынннан торып калган дәрвишме?
Эссе комда эзләрең, мин аларны
«Сине уйлыйм» дип укыйм гел – ялгышмы?

**Аһ, шулай булса**

«Гөл сулары сибәрләр» ди сөйгәннәр.
Су ташый кызлар, кемнәргә сибәрләр?
Аh, яшәртсә гөл суыгыз, тагын бер
Сезгә хезмәт итәр идем, чибәрләр!

**Бу юлы – бәхет өчен тудым**

Туган көнең... Мин дә кабат тудыммы?
Ялкын-балкыштан синең бар булдыммы?
...Заман – авыр, яңа гомер – газаптыр,
Әмма синең өчен тудым бу юлы!

**Мәҗнүн җаны сине эзли**

Төн. Сахра. Чулпан калкыр да таң атар,
Еракларда шәйләнер синең чатыр.
Китим, бүген җырым кунды куенында,
Ә иртәгә чатырга җанны чакыр!

**Чынлап картайсак?**

Әйтә Гаташ: «Мин чынлап шаштым бугай,
Яшь йолдызга кул сузмас идем болай...
Газаплырак хәзер хис тә... Картайгач
Нишләрбез, җан? Әле илледә шулай...
**Үтә күрсәм дә, чигенмим**

Белсәм иде уеңны минем хакта! –
Бәлки, көлке – гыйбрәт итәрсең ятка.
Ярып карыйммы җаныңны... Сөйгәч бер,
Үзгәралмам, нидер тапсам да хәтта!

**Җавап бир, йә...**

Шигырь белән бирсәң иде җавапны:
Булса да ул миңа авыр, газаплы,
Алдаусыз яз... Ак кәгазь бит гөнаһсыз,
Аның алдында без бердәй җаваплы...

**Укучылар булмаса**

Уемда шәүләң, өстәлең җанлана!
Минем күк шигырь язамсың син анда?
Языйк та, яр... укыйк бер-беребезгә,
Шигырь аңлаучы азайган заманда!

## САГЫШЛЫ СӨЙЛӘШҮЛӘР

* * *

Ишетәм өн – килә ком-даладан бер,
Гашыйк җаннар гына белгән аһәңдер:
«Мең ел юлда Мәҗнүнең, чүл-диңгездә,
Син, Ләйләм, чатыр-корабтан хәбәр бит».

* * *

Бу кадәр мөкиббән китеп илтифат
Итмәвеңә әрнеп әйттем, ниһаять:
«Тик яндыручымы син яна белмәс?

Хис, назмы ул тумыштан җаныңа ят?!»

* * *

Гашыйк җаным күтәрде күккә сине,
Менгән саен тик моң сара йөзеңне.
Нигә алай? Бергә түбәнгә очсак,
Син шат тояр идең мәллә үзеңне?

* * *

Алдансам да хистә, үзем алдамыйм:
Шәрран яра күптән синең алда мин.
Нигә сине куркыта ихласлыгым?
Миңа ник ошый илаһи алдавың?..

* * *

Нигә мендек? Бу – Күк, Илаһ дөньясы!
Мин – янган таш, син йолдызшаһ буласы.
Илтер сине яшьлегең чын тәхтеңә,
Мин – картаеп, бу күктән куыласы.

* * *

Горурсың шул... Биектә дә син тыныч.
Минем сәер башны кисәр күк кылыч.
Йә гөнаһларым өчен җиргә атсаң,
Хыялдан... егылып төшсәм? Куркыныч...

* * *

Бар асыл ташларын җанның алдым да
Ташладым беркөнне синең алдыңа.
«Күтәргәнчә ал... Әллә соң авыр бик
Күз яшьләрем? Кыймыйсың кагылырга...»

* * *

Эчемдәге – тышымда! Күр: йөземә
Язылган анда уем да, сүзем дә.
Укы ихлас дөньямны, җаныңа сал,
Гыйбрәт ал һәм... нәрсәдер яз үзең дә!

* * *

Илһам качты – кызу көн... җанга эссе!
Әллә тәмуг бүген үк сыный хисне?
Бер юл яздым, кайда юлларга аны?
«Син оҗмахтамы? Искә ал Рәдифне!»

* * *

Иртә яз бу! Рух сау булсын, туганнар,
Гөлләр ачылыр – нур көтә торганнар.
Ә бу җырлар – сөеклем бакчасыннан,
Милли түтәлдән! – кузгалак, суганнар!

**КЫШКЫ РОБАГЫЙЛАР**

* * *

Килгән иде сиңа кем? Җәбраилмы? –
Хәбәрчесе булдымы Җәбраныңның?

Мин дә тойдым ул шагыйрьдә балкышын
Ходай дусты пәйгамбәрләр җанының!

* * *

«Милли, нечкә сурәтле газәл-җырлар
Кәрваның бар, ул кайчан сәфәр чыгар?
Гүя, – дисең, – ай нурында дөяләр...
Килә һаман моң-сахрадан юлчылар!»

* * *

Юктыр хәзер җанда, уйда башкалык,
Янып көйдек бергә, уттан качмадык...
Әй сынады бу ел: гамь тәгамен без,
Яшебезгә манып, байтак ашадык!

* * *

Бәлки, Гаташка хисең дә юк түгел,
(Булса да ул – инеш, ташкын ук түгел...)
Күңел диваным тиңсез җыр, беләм мин,
Борынгы көй: сиңа ул кызык түгел!

* * *

Әле бәхәс гарше-күк тирәсендә,
Бөекләргә инкяр сүзләре синдә...
Аямыйсың берсен! Гөнаһлы җиргә –
Миңа чират, бәлки, иртәгесендә?!

* * *

Таудан аска төшеп барган юлымда
Очрадың да, җанны әсир кылдың да,
Тагын юлым тауга менә... Күрегез:
Күпме яңа гөлләр инде кулымда!

* * *

Күктән аерылмас булды бу күзләрем!
Анда сине күргәннән соң үзгәрдем:
Айда булдым, уйда, күпме йолдызда, –
Көндез дә күренә тәпи эзләрең.

* * *

*(Диссертацияңне уйлап)*

Бер пишкадәм мин яшәү мәктәбендә,
Бел, мин – надан... Тормыш гыйлеме синдә!
Ә хыял һәм хис бабында мин – остаз,
Шикләнми ал мисалга фән эшеңдә!

* * *

Тик мәчеңә синең назларың, ярым,
Аһ, шулай миңа кагылса кулларың!
Йә җанымны сыйпаса җылы сүзең!
Шуны көтеп җырымда – «мияу»ларым!

* * *

Мин дигәнчә түгел, дөнья, агышың!
Ятьмәңдә, хыял, алтын... тик сагышың!
Ихлас йөрәккә лаек өлешме бу?! –
Мирас булыр кемгә фәкыйрь «табыш»ым?

* * *

Йөз дустан да газиз күргән бер дусым
Дәрәҗәгә менде, – бәхетле булсын!
Тик аның каршында мин төштем ник?
Аңлый алмыйм бусын, – хәерле булсын!

* * *

«Мисле миңле лалә төрки гүзәлләр!» –
Мең ел! – шулай сөйли фарси газәлләр!
...Иренеңдә миң мактау көтә синең дә, –
Нәслең Туран иленнәнме әллә, Яр?!

* * *

Робагый! дип күңел куйдым быел мин.
Дүрт юл кысасында булдым быел мин.
Чит күрмәс, дим, Иранның иркә гөле!
Рухына күп дога кылдым быел мин!

* * *

Ширазданмы китерә җилләр исеп
Сәгъдиләрдән мирас ул гөлләр исен?
Каян белгәннәр фарсылар безне, Яр?!
Хуплыйлар, күр, ничек бу хисләр хисен!

* * *

«Ирәм багы»нда йөрдем мин хыялда,
Лалә касәсе – хис тулы пыяла!
Күпме эчтем аны, ахырын уйламый,
Шуны сузып торам, имеш, сиңа да...

* * *

Искә ал бер! Түгел «борын заман»да,
Күп «шәй»ләре җайсыз, кырын Казанда
Без бәхетле булдык бер ел! – Бер көнең
Гасырга тиң, шактый кыргый заманда!

* * *

«Дөнья – чиксез дәрья, тормыш – корабль,
Батмас өчен тугры дуслар таба бел!» –
Көне буе шул җыр ник пароходта?!
Ярага тоз сипсә кемдер – харап ул!

* * *

Каютамы? Гөл оҗмахы бар бүлмә...
Сөйгән җаннарга гел иркен – тар бүлмә,
Арабызда диңгез дип, ник карашың
Кисәтә: «Бел, батасың... Керә күрмә!»

* * *

Без табынган шәркый, төрки шагыйрьләр
Бу мәлдә, мөгаен, сине әрлиләр:

«Рәнҗеттең энебез җанын... Болай да
Ярасы төзәлмәс иде... җәл», – диләр.

* * *

Табынуым озаккамы сузылыр?
Әле бездә уены һәм чыны бер...
Әле син таҗ-тәхетле төштә кебек,
Аһ, бер мәлдә уянсаң, кыен булыр!

* * *

Пышылдап әйттем, тик ил ишетте.
Сиңа хисне, хуплап, дөнья иш итте...
Күкләр кабул итмәгән салкын сүзең
Мине түгел, җирне бугай өшетте!

* * *

«Булмады шул, – дисең, – үз Рәмием минем!»
Шулай аңлыйм бу «милли гам»ең синең:
Рәми булса ук атучы гашыйк яр,
Уклар үтмәс чын калкан – җаның, димен.

* * *

Бар дөньяга шәрран яра бу хисләр
Кисәме сезнең тынлыкны, күл-күзләр?
Камыш-керфекләр ник ярсып тирбәлә?
Шик белдерә әллә безләргә сезләр?!

* * *

Алтынсу бөҗра ураткан ай күргәч,
Йөзен сагыш сарган гашыйктай күргәч,
«Аман!» дип, син аңа әйтә белдеңме? –
Һәм миңа шул мәлдә искә төшергәч?!

* * *

Табарсыңмы Арча томаннарында
Югалтканны Казан бураннарында?
Бәлки, эзлисең үзеңне? Мине дә
Тапмассыңмы шул моң урамнарында?

* * *

Кайда ярларың? – тезеңә баш куйган,
Яшь койган – гөл храмыңа табынган?
...Храм-кәлисәң дә шул ук... кайда алар? —
«Башка дингә кучте» әллә ахырдан?!

* * *

Сине сөйгән һәм син яратканга – сүз
Әйтмәскә ант бирдем – калыйм имансыз!
Сиңа ни дим? Гашыйкларыңны җәллим:
«Азат җаннар! Сез дә коллар булгансыз!»

* * *

«Укучым!» – дип дәштем озак... «Кариэм!» –
Дип тә искечә бер әйтеп карыем?..
Ник җавап юк? Тавышым зәгыйфь, бәлки?
Ә бит ишеттергән Тукай абыең!

* * *

Юл башында чын дус, сердәш идек без:
Хыял – уртак, ә тапканнар – гел тигез...
Мал-дәрәҗәме аерды? Ник әле
Ихласлыктан – шигырьдән сез киттегез?!

* * *

Кем ул җырлый? – «Карурманда атларым...»
Белгән каян – канатлы, шәп чакларым
Урманында мине егып калдырган
Алтын-җирән, ялкын яллы ат барын?

* * *

Хискә ул чак Акыл әле ят булмыш,
«Бар дөньяны кочам!» дигән чак булмыш.
Киңәйдеме дөнья – җитми колачым,
Акыл, белдем, синең сүз дә хак булмыш!

* * *

«Ә ник томан каплаган «Йолдыз-тауны?» –
Пир Солтан* бит гел кабатлаган аны! –
...Төрки дөньяда матурлык – яшерен, сер.
Көтимме, Яр, шул томан таралганны?!

* * *

Ирешсен сиңа җырларым! – пакь яшем...
Ә битараф калсаң? Гел куркып яшим...
Илһамчым – син... Язганым «тетсә» бирәү,
Сөенерсеңме? Йә йолкырсыңмы чәчен?!

* * *

Әйттеләр: – Кем... Улмы сине яндырды?
Оныгың булырдай бала – ярыңмы?
Дидем: – Килә... киләчәктә яшисем,
Шуңа бирәм яшь кулларга җанымны!

* * *

Һаман җанны борчып тора уем бер.
Олыгайгач, уй да, ахры, кыендыр...
Булмавыбызмы без дә картая белмәс,
Олпат булмас, нәфесен тыймас буын бер?!

* * *

Моңнарым бар... әмма шатлык бирүче
Булса иде җырым – сөендерүче:
Мәхәлләгә яңа кием кидереп,
Үзе искегә дә шат бер тегүче!

* * *

Ялкында булып бер, янып чыныккан
Курыкмый ул башкача инде уттан...
Бүген яндырган ут – сиңа хисем ул! –
Су сибеп тик сүндерүеңнән куркам.

* * *

Ахыргача сине аңлау кирәкме?
Юк, мин алай өйрәтмәдем йөрәкне!
Чынлык – шикле... аннан өстен күрик без

Үзебез тудырган хыял-сурәтне!

* * *

Сизәм: күңелдә урыныңны зур иттем!
Җирән чәчне, күр, илаһи нур иттем!
– Лаек түгел мин моңа... – дигәнең юк,
Мактый торгач, ахры, нык горур иттем!

* * *

Мин дә мәшһүр гашыйк җирдә, янәсе,
Беләләр дип йөрдем илдә һәммәсе...
Исмем дә ишетмәгәнсең! – шаккаттым:
Менә шул, дим, «дан тиз узу» бәласе!

* * *

Утыз ел, аһ, бушка узган шигырьдә –
Мине син белмәгән вәйран гомердә!
Языйм тагын утыз ел, насыйп булсын
Хәйран итәргә – җаныңа керергә!

* * *

Яшьлек! Сиңа кайталмасак тагын без,
«Хис давылы»н картлыкка да алырбыз,
Көндез кызларга сүз кушып, әгәр кич
Җил чыкмаса, күзләргә дә барырбыз!

* * *

Кайда ул көлеп күз кыскан яшь гөлем! –
Гөнаһлардан өстен калган яшьлегем?
Җиттеме, һәр яшь парга кырын карап,
Сиңа да, Яр, вәгазь укыр яшь минем?!

* * *

«Белсәң, – дисең, – минем ни уйлаганым! –
Күк белән җир арасын буйлаганым...
Бер Газизил – җаным... Юк, сөймәс идең
Син дә хәтта, сизсәң кай дөньядан мин?!»

* * *

– Тик гөлләрме су сорый? Минем күзләр
Күпме эчте! Чишмә анда, диңгезләр...
Ә йолдызлар, – дисең, – каян ала көч?
Гаҗәпмени, сусаса яшь йолдызлар!

* * *

Син булганда янсам да ләззәт утта,
Никтер аңлыйм моны синсез минутта...
Бергә чакта хис кыза, болыты юк,
Жыр яңгырым да коя, күр, син юкта...

* * *

Хатларың башлана иде: – Шагыйрем!..
Бу эндәшне хәзер кайда калдырдың?
Шигең бармы әллә «даһилыгыма»?..
Шигырь кадере дә юк илдә, кадерем!

## ҖЫЛЫ ЯЗДА ЯУГАН КАРЛАР

**1995 тә язылган беренче юл**

Бисмилла! дип язып китик бу юлны,
Былтыргыдай, шигырь итик бу елны.
Җир, күк әле имин бугай... Без дә бит
Мәхәббәтнең шул ук күндәм бер колы!

**Фатиха алдым**

Язганың ни, каләм? Хис ташкан хатмы?
Күккә ашар моң-ялкыннан хисапмы?
Колак салдым, йолдыздан алдым хәбәр:
«Безләр – разый... Башла яңа китапны!»

**Ә илһамчым?**

Мин дә догада дип, фәкать ишарә –
Хуплау көтсәң дә син, Гаташ-бичара,
Нигә сүзсез әле ул яр? Үзе дә
Шагыйрә лә... Дәшми – кылыйк ни чара?!

**Ә мин котлап язам**

Бөреңдә чәчәкләр күрдем, яз, ямен, –
Беренче җырыңны котлап язамын.
...Бу юлда тик шатлык, дан, бәхет тап син,
Миңа бир, очраса, кайгы, газабын!

**Без очрашкан көн**

Бу очрашу Галәмдә бер очракмы?
Күкләр кушканмы, ялгышмы йә хакмы?
Тетрәп сүнгәндә... гөлт итте рух-филтәм,
Күзләрең бит көлтә-көлтә ут атты!

**Зилзиләнең исеме ни?**

Аһ, бер елдан җанда күпме зилзилә!
«Әпипә»ме хистә, әллә «Зәлидә»?!
«Уф, беттем...» дип куям да, искә килеп:
«Илаһым! – дим, калдыр шушы хәлемдә?!»

**Җан сүзем – ул сиңа**

Марттан алдым бәхетем – изге Нәүрүздән.
Бу язда да Кучкар үтенә Сездән:
«Булыгыз туган аемның йолдызы!
Җан сүзе бу – инде телсез, нәүмиздән...»

**Шәһит гашыйклар килсә?**

Безнең уртак бәйрәмгәме ул – бүлмәң
Бизәлгән? Аһ, тасвирына сүз белмәм.
Ак, кызыл, зәңгәр – күпме төс! гөлләрме?
Котлап изге гашыйк җаннармы килгән?

**Нигә шулай көлдек?**

Без шаштык бер кышкы кичтә, тилердек:
Шугалакта тимераякта йөрдек.
Киткән яшьлек миннән – һаман егылдым;
Әй шатландың! Күздән яшь чыкты – көлдек...

**Сөю юлында**

Үз-үземне аңлар чик ул югалды,
Юлны җуйдым... Ярлар, таулар уалды.
Ташлап качты түземлелек һәм акыл,
Ә хис, өмет китмәде... Хыял калды.

**Нәфсе халәтең**

Әй-йа, омтылышың! Күккә очарлык,
Җирнең бар яшь гөлен җыеп кочарлык.
...Дәшми генә бер илле ел көтимме,
Миңа да бер наз мизгелең бушар дип?

**Нинди яңа көйләр синдә?**

Төректәнме бу көй-мөнәҗәтләрең?
Гарәптәнме моңлы аять-мәкамең?
Хис манараңда имамнар гел яңа,
Ә иманың үзгәрмәсме, әйт, җаным?!

**Йолдыздан кем өне?**

Күктән һаман аваз килер (шуннан бу!),
Яндырыр да суытыр бер (чыннан бу!).
Әкрен, салкын, үз кадерен белгән тавыш
Әйтер тагын: «Мин әле бу... Чулпан бу!»

**Фирдәвестә дә уйла**

Онытма ихлас догачың Гаташны.
Хыялыңа биекләргә юл ачты...
Ашсаң да күккә, уйла аны – бу җирдә,
Сөеп, гел сусаган җанны, гел ачны...

**Яңа гасырга үрелеп карау**

Алда да гашыйк җаннарга серләр күп,
Ачылыр яңа сурәтләр, сүзләр күп.
Алай да... бу зәгыйфь «Чулпан сүрәсе»н
Күк сүзе итеп, анда кемдер сөйләр күк!

**Чал гашыйк бәхете**

Яшь көндәшләремә бу сүз... Гаепме?
«Сезне сөя ярым, сез – таҗ, тәхетле...»
Ә чал гашыйк: «Мин шаһтан бәхетле», – ди...
Бәлки, башкача аңлый ул бәхетне?!

**Мактавым бугай бу**

Холкың-фигылеңә ни әйтим, гүзәл яр?
Миннән гайре аңа кемнәр түзәр, яр?
...Шундый хисем: кышын атарсың чәчәк,
Саклый алмам, куркам: читләр өзәр, яр!

**Шагыйрь дусларыма**

Мөдәррис, Зөлфәт! Белмисез хәлем сез...
Үзе матур, сүзе суык, рәхимсез
Яшь кыз әсир итте... янам да язам,
Тагын нишли алам? Бәлки, әйтерсез?

**Хафиз, Ронсарларны уйлап**

Бөек гашыйкларның аңлыйм хисләрен,
Җан кардәшем итеп данлыйм үзләрен.
Шундый таныш миңа алар халәте! –
Башлыйлар – яттан тәмамлыйм сүзләрен!

**Йөгем кадерле булгач**

Хистән – таудай йөк төялгән иңемә,
Авыр – төшлектән бер узгач, сизелә...
Яшьләргә хас, бар дөньяны кочкан яр,
Түзәрмен – иңемә алыйм сине дә?!

**Икебезнең сурәт**

Икәү төшкән «мәшһүр» сурәт аша мин
Бар дөньяга бәян итәм – дәшәмен:
«Эшләпәле яшь бер туташ – син анда,
Һәм авызы ачык, гашыйк «карт эшләпә» – мин...

**Үлеп көнләшәм**

Көнләшәм! Кичерсен Ходам... Үләм мин!
Хакым да юк бу «бәхет»кә, беләм мин...
Әйдә, дим, бер кычкырыйм, җан бушансын, –
Сизәм юкса: үз-үземне җиңәлмим!

**Бер-беребезне аңлый төшкәч**

Күрәм: сиңа була барам кызыксыз,
Күңел дөньям фәкыйрь, сулышым – утсыз...
Әмма әле хисләрдә син көтмәгән
Фетнә чыкмас димә... Гаташ – холыксыз!

**Уендагы ... минсез бәхетең өчен**

Нәкъ песиең – бәхеттән арган, рәхәт... —
Ул кич шундый «ирде» – синең кыяфәт:
Хыялыңда җәннәт иде, тик – минсез...

Шуннан бирле уйларымда кыямәт.

**Артык... «ватылмыйча» гына**

Кем ул әйтте: «Гаташ коллыкка төшкән!
Хезмәт итә ярына, тирләп-пешкән».
Ә бу юлда хәйлә белгән бик күпләр
Көч куймыйча да теләккә ирешкән.

**Бер халәт**

Әллә күз тиде, әллә сүз – язалмыйм...
Илһамым юкмы – кабынып яналмыйм.
Әрли алмыйм – яшь холкың рәнҗетсә дә,
Мактарга да сүзләр бетте – табалмыйм.

**Сине уйлаган кичтә**

Син театрдадыр шушы сәгатьтә! –
Ложаларның күзе синдә, әлбәттә...
Аһ, мин җитмим анда – сиңа багарга
«Илаһи» һәм чын шашкан кыяфәттә!

**Калфагыңа җыр «чугы»м**

Исеңә ал шулай җырлап калганым:
«Бигрәк килешә, яр, каян калфагың?»
...Урыс иле димим, бар кыйтгаларда
Татар пакьлеген саклап йөрт, аппагым!

**Тагын бер сүзем**

Бизәкләре алтын калфак башында,
Уф дияргә мәҗбүр итәр барсын да.
Каралтмассың, дим, калфакны, милләтнең
Кызартмассың йөзен Ходай каршында!

**Башка кем үгет бирер?**

Шикләнә дә күңел, һаман шомлана:
Ташлар бу яр дип уйлый да моңлана.
Һичнәрсә юк җирдә мәңгелек, бел, дип
Кат-кат тукыйм... Башка ни әйтим аңа?!

**Бар да үтәчәк, диләр**

Дуслар әйтә: «Бик бетеренмә, җитәр!
Авыр булса яр сүзе – көлеп үткәр...
Вакыт барсын оныттырыр, дәва ул.
Сөю – авыру, ялкыткач... үзе китәр!»

**Нинди төстә?**

Уңдымы, яшьлек, күлмәгең? Үзгәрдем,

Үзгә хәзер минем сөйгән төсләрем.
Сөю, соңгы эләмең нинди төстә? –
«Үтә кызыл»га күп китте исләрең!

**Усал сүзеңә**

Иске авыздан яңа, тик авыр сүз!
Ничек, дим, әйтә алдыгыз аны Сез?!
...Яшермәдем мең гаебемне Сездән,
Сез – тәкәббер, бәлки, берсен танырсыз?

**Кемгә яна утың?**

Ялкын чәч дип, алтын чәч дип, әгәр дә
Быел әйтсәм, сүзем, бәлки, әрәмгә?
Һаман, балкыш булып, ул ут-чәчләрең
Янадыр... Тик кемгә?! Нинди бәйрәмгә?!

**Халык җыры искә төште**

Килдек җиргә – гыйбрәтләр алмак өчен,
Сөйдек – җырда үрнәккә калмак өчен.
Килер җәза – ят кавем алдында син
«Кулыңнан төшергән ак калфак» өчен?!

**Иске чынлык, яңа газап**

Иске гыйбарә: «Яратам... Ә ул – юк...»
Ятлар өчен бу әллә яңа, кызык?
Ә минем күңелдә яңа бер упкын –
Фаҗига ул... Һәм җыр бугай шул чынлык!

**Пирамидалар иленнән көнләп**

Көнчыгыш! Нур, кояшмы син тоташтан! –
Ярның җаны нигә синңа тоташкан?
Фән эшен дә иһрам итеп язар, дим:
«Шәрекъ, улларыңа гашыйк туташтан...»

**Зармы, алтын-зарифмы?**

Хисләрдә – зар? Зари-зари елаумы?
Зариф – алтын ярны һаман уйлаумы?
Зарланамдыр, чөнки белмим зәррә дә
Һәм мыскал да— хистә алдау-уйнауны!

**Синең исемдәге авылда уй**

Исемең нуры, әйт, ил-йортка тулган ник?
Рекламамы? Мохитемдә «Чулпан» тик...
Кайда юлыксам да, җаным кузгала,
Миңа да күк капусы ачылган күк!

**Сагындырыр, дим**

Әле исеңә төшмәсә дә, бер төшәр.
Сагындырып җил исәр, гөлләр үсәр...
«Гаташ шундый сөйде мине!» – диярсең,
Өстәрсең: «Тик... Чама белмәде, исәр!»

**Хушлашырга әллә?!**

Бер башлагач, шәт, ахыры кирәктер?
Сузылса хис, соңы кыен гыйбрәттер?
Харап булганчы бу башың, Гаташым,
Инде «мән белеп» хушлашу әйбәттер?!

**Моң китабым – диваным бу**

Гашыйк диванаңнан сиңа бу диван! –
Моң китабым, мең хыялым, бел, сыйган.
Укы аны җан тәхтеңдәге ярга,
Миннән бәхетлерәк булсын! – шул догам...

**Бәлки, хисең уяныр...**

Уйланган, күңелең моң тулы көнеңдә,
«Таңы ерак» йокысыз бер төнеңдә
Гаташыңны син искә ал, бер мәлгә
Мәрхәмәт хисең уяныр синең дә!

**Җиңгәч...**

Заман «чир»е! – китә каләм шукланып,
Гөнаһлы уй белән читкә укталып...
Тыям аны: бүген, Иблисне кугач,
Тордым хәтта үз-үземә сокланып!

**Сайлау кампаниясе узгач**

Милли Мәҗлес! Шул матур исем-атны
Ник ят күрә түрәләр – читкә атты?
...Милли Яр! Аһ,син күңелең мәҗлесеннән
Кума: булыйм ихласлык депутаты...

**Чынлап та сабый мин!**

Өмет юкны аңлыйм да, яшь матур, мин,
Үз-үзеңне җиңү, ахры, авыр, дим.
Ишек тоткаңа ябышып тик торам,
Могҗизамы көтәм? Чынлап шагыйрь мин!

**Шул алмагач истә**

Узган елда тик Гаташмы саташты,
Яшьлегем, дип, кабат китмәскә кайтты...
Ялгыштыммы? Ә бакчамда ник көзен
Карт алмагач яшәрде – чәчәк атты?

**Син дә минем кебек ләса**

Март аенда сайраган, әй, сәер кош!
Серләшик бер икәү, яныма син төш!
...Ярың турындамы җырың? – моңлы бик,
Сереңне, дим, бигрәк фаш итәсең ич...

**Яшь гашыйкка**

Бәхетле бул, сөйсәң, яшь ихлас бала!
Булмасаң – оныт, җаныңны кыйнама...
Китап укы йә тән үстер, илләр гиз –
Файдалы шөгыльләр дә бар дөньяда!

**Өстәп торам...**

Җырлыйм – әллә сагыну моңы бу җырда?
Җаныма рәхәт тә кебек, авыр да...
Хәлем аңлый мәллә? Җырга кушыла –
Һаман шаулый: су салдым самавырга...

**Югалтулар күп бу җирдә**

Кайгың зур, күрәм: күзләрең елаган...
Җырыбызга кергән мәчең югалган!..
...Сабыр бул, Яр...Уйла, без сөйгән күпме
Җаннар китте Җирдән – кичте дөньядан...

**Яшь Кояш кебек, дим...**

Кичәге яңа, аһ, бүген иске ул! –
Сиңа күптән мәгълүм гыйшкым төсле ул...
Ялгыш әйттем! Һәр көн таң каны юган
Пакь Кояш күк, яңа, якты, көчле ул!

**Дуңгыз елыннан ни көтәм?**

Ямьсез сүзме: «Дуңгыздан алган бер кыл»...
Миңа бирсен кабатланмас бер җыр шул
Дуңгыз елы! Кылдан нечкә юл үтим,
Үземдә шундый көч сизәм мин быел!

**Саулар ягына ник багам?**

Сызлана тән... Рух тамы? – ардым бугай,
Сөю, синнән чын-чынлап авырыйм бугай...
Ә күзем ник сау-тазалар ягында?
Яшь ярлардан ни көтеп карыйм болай?!

**Ул да эретмәсә!**

Үз вакытымы һәр жанрның. Кара аны:
Укылмый, диләр, бу көндә романны...
Илаһи чын роман – ул безнең сөю,
Шул да эретмәсме туң бу заманны?

**Иелсәм дә – табигыйдыр...**

Иелсәм дә һаман синең алда – соң,
Үземнән түбән булмам ла – аңла син!
Һәм үземнән өстен, биек тә булмам...
Башны исәм – озаккамы? Аллам – син!

**Җыр тыңлаганда**

Фарсы аша төрки ярга кул сузган,
Әнкә телдә илдә җырдан юл сузган...
Яд итик бер җанын бүген: гашыйк, кем,
Бу дөньядан Мостафа Ногман узган!

**Алдан күргәнсез шул**

Авылдашлар! Еллар томанынннан сез
Миңа кырыс карап торган сымансыз:
– Авыр булыр бу «җенле»гә дөньяда,
Җаны – чуар... – Ахры, ялгышмагансыз...

**Ул да шул кабиләдәнме?**

«Бәну гозрә» – түгелме кабиләсе?
Бөек гашыйклар – тик шуннан киләсе...
Мәҗнүннән соңгы пәйгамбәр булмасмы
Синең гарәп? – мин «кяфер»не җиңәсе...

**Пәйгамбәр-шагыйрең биеклеге**

Ул пәйгамбәр-шагыйрең сине күргән,
Күккә аш дип, рухыңа баскыч биргән,
Шуны миңа да сузарсың дип көтәм –
Онытмасаң Җирне... Син шактый менгән!

**Сәер бер сүз**

Бер мин мәллә? – Үтә җитди йөргәннәр,
Акыллылар да, ахры, тилергәннәр.
Әйтте бер дус: «Яшереп йөрт җан нурыңны!
Сизмисеңме – сиңа күз тидергәннәр...»

**Ышаныргамы?**

Дан гөлләрем соңлап чәчәк атканмы? —
Чираттагы бер алдану-хатаммы?
...Дус дигәнем уңышларымны... «күрми»...
Дошманымнан оялсын! Ул мактады.

**Һаман яхшы саналмыйм**

Үз бәямне көтәм әле җирдә мин,
Инде матур сүзләр тезә беләмен.
Сөю сүзе... Кемгә кирәк ул бүген?
...Һаман яхшы санда түгел илдә мин!

**Нииндидер бер хис кылы**

Быел да ак канәфер син китердең:
Туган көнем яшьлек ямеңә төрдең.
Былтыргача тетрәнмим ник? Үлгән күк
Җанда бер хис... Бәлки, үзең үтердең?!

**«Ярым ятлар белән уртак...»**

Бәдәвиләр чоры бик ерак, бәлки?
Күңелләр күчмә түгел, утрак, бәлки?
Ник күбәйде дөньяңда ятлар, Ләйләм?
Зур шәһәрдә хисләр дә уртак, бәлки?!

**«Җирдә әллә ниләр бар...»**

«Җирдә әллә ниләр бар», бел, дигәннәр
Чын шагыйрьләр... Әйтегез соң, ниләр бар?!
...Кемнәр мине күктән җиргә төшерде?!
Сорау бирсәм, ник көләсез, юләрләр?!

**«МОҢЛЫ БЕР МӨНӘҖӘТ...»**

* * *

Ахырына җитсә бу – безнең хикәят,
Ул – бер гүзәл кыйссадан мисал, шаять?
Тик мәңгелек түгел ник Җирдә һични?
Җавап бирерме Мәңгелек, ниһаять?

* * *

Шулкадәр, дим, чаң сук – җаныңны кыйна...
Әллә Сөю – дөньякүләм вакыйга?!
...Шуңа инанганга язам бу җырны
Һәм ышанганга, калыр дип бакыйга!

* * *

Узып бара Дуңгыз атлы бу ел да...
Быел каләм ник сүлпән йөри кулда?
Беттеме көч? Юк, син ардың дип куркам, –
Хис кәрваны тик фәрман көтә – юлда...

* * *

Сине минем күк яраткан булырмы?
Күкләргә ашкан, җан аткан булырмы?
Кайчан да бер үзең сөйсәң шулай, бел,
Кәгазьгә дә чишмә яшерен уеңны...

* * *

Масрадан чакырган инде Басрамы?

Борынгы Гыйракмы тарта, башкамы?
...Галәм хәйрандыр күңелеңә: күптән ул
Кыйтгаларда – Җиргә сыймый башлады!

* * *

Моңлыларга читен заман (ни әйтим?),
Моңсызларга, бәлки, таман (ни әйтим?),
Өйдә, урам, илләрдә – Җирдә җәнҗал,
Син дә усалландың тәмам (ни әйтим?)!

* * *

Уйлыйм: җанга ихлас ярмы син, юкмы? –
Гамь утыны ятның – көчәйттең утны...
Шул хәлемә сөенгән кыз! Сиңа бит
Үзем бирдем бугай мондый хокукны?

* * *

Эндәшә кем шулай? Әллә соң Тәкъдир?
Бик олылап әйтә: – Әй-йа, кем, тәкъсир!
Һич үкенмә сөеп узган гомереңә:
Ул – Киләчәк бер аклар «җинаять»тер...

* * *

Ымсындырдың, яндырдың – чын сер булдың!
Тоташ бер китап яздырды, күр, кулың!
Гөл-ярларны оныттырдың, яныңа –
Биеккә, күккә чакырдың... Ник кудың?!

* * *

«Аллаһы әкбәр ел ярым!» дип, ахрысы,
Кабатлар җан: анда Бабич яктысы...
Сиңа баглы китапта да чагылсын
«Китабеннас»ның саф алтын-ак төсе...

* * *

Гарәпчәне өйрәнүең ярады:
Урлады җаныңны «Багдад карагы»...
Югалмассың чит илләрдә, тел белгәч,
Мин тынычлык җуйдым аның каравы...

* * *

Бу сиңа күңел телендә эндәшем:
Гашыйк җаннар аңлар шивәм-сөйләшем,
Холкыма хас сәердер күп сүзләрем,
Тик әнкәм телендә моңлы күз яшем!

* * *

Кайчак уйлыйм: яшь кенә гомереңдә син
Күпме моң-гамь күргәнсең – кичергәнсең...
Минем яшьтә нинди булачак җаның?
...Буш касәдән, мөгаен, исермәссең...

* * *

Ут иткән, күр, яфракларны көз тыны,
Алтын диме һаман шигъри сүз шуны?
Ник матурлык, балкыш – үләр алдыннан?
Картлар гыйшкы дип атыйкмы без моны?

* * *

Илледән соң да сөюем хак, димме?
Чәчләрдә дә, шөкер, аз бит ак, димме?
Әллә сөеп, әллә көлеп, янымда
Тукталган яшьлеккә карап, «аһ!» димме?!

* * *

Аерылышу! Беләм, авыр буласы...
Әмма тиеш, шундый тормыш йоласы...
Киткән чакта, алдыңа тезләнеп, Яр,
Озын итеп нинди дога кыласы?!

* * *

Көз чишендергән табигатьтәй халәт.
Күңелсез – калам күк синсез, мәхәббәт!
...Хисе ташып, былтыр көз чәчәк аткан
Алмагач та үлде... Ни бу, әйт, Хәят?!

* * *

Иске җәрәхәтең генә канаттың,
Яшьлеккә якынайма, җан, кабат син...
...Тик бөек хис – Илһам яры үлмәсме
Гүзәлеккә, куркып, читтән карап син?!

* * *

Яр кашында тиңсез, яшь, шәп егеткә
Бармы ихтыяҗ – сүз, вәгазь, үгеткә?! —
Калдырганнар ярга ялвару фәнен
Чал гашыйкка – әйе, безнең кебеккә!

* * *

Телем әйләнми «сөй мине!» дияргә,
Тиеш син яшьне, тиңеңне сөяргә.
Бәхет – аның кулындадыр... Ә миңа
Кала моңлы бер мөнәҗәт көйләргә!

**ГӨЛЛӘРНЕҢ ШАҺИНӘСЕ**

**Кереш**

Бу нәсихәт син Ярдан: «Хистә, – дидең, –
Бул сабыррак, бик тиргә төшмә... – дидең, –
Сал җырыңа, сөйсәң, сүз асылташың, –
Шомарт аны ләкин, нык эшлә! – дидең.

* * *

Исмеңнең ник бер иҗеген кабатлыйм?
(Әллә нинди серле сүз күк... яраттым!)
Ахырын әйтеп беткәнче ничек болай
Сөеп өлгердем? Булмаммы харап мин?

* * *

Җанга җылың җитәрме, хисләр җәе?
Бармы, дим, тән-гамь аша үтәр җае?
...Гомер, якты нигә шулай бу кичләр?
Балкый, бәлки, соңгы теләкләр ае?!

* * *

Каты хаста хәлдән терелеп киләмме?
Үткәннәрне оныттым дип беләмме?
...Ә ник синең күзләрдә күрәм бүген
Еллар моңым сарган яшьле гөлләрне?!

* * *

Кемгә баглы яшь омтылышың синең —
Илаһи зар – «галәм ишеткән» серең?!
Башкага ул җырың... Ә ник, алайса,
Бар дөньяга, котлап, мин аваз бирдем?

* * *

Халкың-кауменнәндер хыял байлыгың:
Шуннан билге – чиккән бу кулъяулыгың!
Ничек тетрәнмисең, һәр төс-бизәктә
Милли чалым... Хәтта җан чуарлыгың!

* * *

Кичер, кайчак минем хаксыздыр сүзем:
Ихтыярсыз тузындым – яндым, кыздым...
Ит гафу! Мин күп битәр-сүз күтәрдем,
Үткәр син дә бәгъзе гакылсызлыгым!

* * *

Кемгә тансык хиссез, сөюсез дөнья?
Әйтер идек: «Абау, күңелсез дөнья!
...Беркөн шундый «мир» хөкем итсә безне?
Кайсыдыр ки, бер тук... шигырьсез дөнья?!»

* * *

Ходама ялварсам, кальбемдә теләк күп!
Дога белән жаныңа да тиям күк!
...Динең – башка? Пәйгамбәрем чит булса,
Үз Аллаңа җыр телендә келәү ит!

* * *

Яр авылы! Бер сәлам-сүз җәлләдең...
Искә алырмы Кәвәл йә Әлбәден?
...Син суынсаң җырларымнан («Тәүбә!» дим...),
Аңлар, бәлки, төбәгең җан хәлләрен?!

* * *

«Урман авызлары, дисез, тар авыз...
Тал башлары икән сары балавыз».
Сагынырбыз бергә, бәлки, моң-урман
Эчләренә ерак китсә балагыз!

* * *

Җырлады кем? «Гөлләрнең падишаһы...»
Уйладым: син – гөл иле шаһинәсе...
Юккамыни сезгә омтыла бу җан?
Тәхетен тапмый һаман – хәл итәсе...

* * *

«Актый мунчагызга кемнәр яккан»дыр,
Җил очыртса, хискә очкын капкандыр?
«Садтый бакча»гызда үскән тиңсез гөл» –
Җырымны шуның хуш исе тарткандыр?!

* * *

Юлга карап бу кышта еш күз тала.
Буран һаман... Адашмасмы кыз бала?
Кайсы чишмә чакыра янган хисен?
Кайтты гына... тагын юлга кузгала!

* * *

Кара чәчләреңдә бәс – кыш сулышы...
Ал бит алмаларың – кышның уңышы!
Суык һәм күз тимәскәдер, яшерен
Куш булганы кайсы багның җимеше?!

* * *

Сабый хисме? Җаныңда татлы яра...
Ул – җыр башың... Ә миндә «хәсрәт» яңа.
Карлар күмде безнең кадерле эзне! –
Өшемәсме? Суык тимәсме аңа?

* * *

Бишегеңә җыр көйләгән Ануклар,
Керәшеннең ак, пакь җаны Начтуклар.
Хыялыңны шулар үстергәннәр бит –
Татарча чын моң сакчысы карчыклар.

* * *

Колакта тавышың: «Чалъярым... чү, абый!»
Чылтырый гел сүз чишмәң, сөйли: «Җаный...»
Яшьлектән күпме наз, вәгъдә... Яшәрсәң,
Гел алданып, йөз яшәсәң дә ярый!

* * *

Рәхмәт егетләрегезгә! Сезләргә –
Кызларга китабым биргән – бәйрәмгә!
Ышаныйммы яклар дип хисем шулар
Һәм аңлар дип япь-яшь талибәләр дә?!

* * *

Гөлбакчамы, җырбакчамы – илеңә
Сәлам бездән – нәзкәй билле гөленә!
Шул бил өчен инде акылын җуйган
Кемсәләр рәтеннән эзлә мине дә!

* * *

Исемеңне мәгърур йөрт – сәбәп бар ла:
Атлар – капкаңда, яр да анда, ятлар да...
Килгән бер карт җор телле, мут чәчәндәй,
Мөнәҗәт әйтер Мулилле-Саттар да!

* * *

Сагышлы җыр: «Җанкай китте чәшкегә...
Батып үлде... калды башым яшь көйгә».
«Ашказар»ны тыңлап еласаң да, Яр,
Гаташың кайчан китсә дә... яшь койма!

* * *

«Әлеп-би-ти» дип, сабак укыймсың син?
Дәресем кала, шигырь язалмыйм, димсең?
Ялварыйммы Хакка: «Әйбәт бала бу!
Ял иттерик... йә аңа вәхи килсен...»

* * *

Сурәтләреңдә житди син... Ник көлеп
Тормыйсың гел, тирәңдә нур бөркелеп?
Оныт Тукай каһкаһәсен... Рәми бит:
«Көлдисә, ди, дөньяны ямьләр кебек!»

* * *

Гомеремнән шашкын, кыен әкият күк

Тоелмыймы еллардан бу көндәлек?
Күпме хата, ялгыш... Сөйли һәр бите:
«Гаеплебез... Сез укыр дип белмәдек!»

* * *

Унсигезең тулы, тик – акылың камил!
Сабый язса да, Әнкә сүз – өлкән ул.
Күзләреңнән укыйм киләчәк шигырен,
Кума карт гашыйк «күсәк»не, ит кабул!

* * *

Туган көнемдә бәэлди бер бәрән,
Бәлки, котлый? Китмәсен сүзе әрәм, –
Бу төш, имеш... Мөгезенә хат элеп,
«Кучкар»ымны «Арыслан»га җибәрәм!

* * *

Аһ, нигә бәхәсләр безнең ешайды?
Сүз кылычы сугыштан бер бушармы?
Холыклар – бер... Ярый ансы... Ник җаның
«Ни кылсам да, кичерә...» дип ышанды?!

* * *

Төзәлмәссең, җан: буласы булынган...
Сөю ди торгач, көферлек кылынган!
Ходаем, дим, үч алма, зинһар, зәгыйфь
Бәндәңнән – фәкыйрь һәм шагыйрь колыңнан!

* * *

Нинди булган, дип, Туфан «Тәнәкә»се,
Күпме табылыр гайбәте, мәрәкәсе...
Онытмассың, татар, бу – бөек Чалның
Иң соңгы һәм иң бөек мәхәббәте!

* * *

Шик-шөбһәләр йорты җаным тумыштан,
Корт иледәй тузгый бүген... тулышкан!
Уемда гел шул «күренеш»: җаныңа
Бөек алдакчы, тасма тел елышкан...

* * *

Авызы-сүзе алтыннанмы шайтанның? –
Йөнтәс кашлы, тар маңгай, салкын җанның?
Ничек шул кол сихерли шаһинәне?
Биеклек, син сазлыккамы ышандың?

* * *

Шигырем бавы тоталырмы озак, дим? –
Күңел кошыңа кордым бит «тозак» мин.
Язылсын бу диван! Аннан, тагын да

Чаралар табармын, бәлки, азак мин!

* * *

Болгар иле... Бүләр, Кашан, Җан-Сувар...
Күпне күргән гөлбакча-җир, дан чыгар.
Бу шигырем хәбәрче тик... Ә тиздән
Шан кәрваны күренеп... җаның чаң сугар!

* * *

Кем ул әйтә: «Милли хис юк җанында...»
Борынгы моң, тоям, шаулый каныңда...
Юккамыни Ходай җан биргән сиңа
Идел-йортта, чын төрки аймагында?!

* * *

Кан, җан – уртак, типтәр йә мишәр, дисәм,
Казан, керәшен – газиз өлешләр, дисәм,
Үзем дә, шиксез, төп Татар йортыннан
Кайчандыр киткәнгә гаҗиз, Яр, дисәм!..

* * *

Китерде эфир бер яшь тавышыңны –
Сабый өнен... Җаным шундый ашкынды.
Шөкер, таныйм инештә диңгезне мин,
Тамчыда тоям илаһи ташкынны!

* * *

Моны язган көн – бәйрәм... Нәүрүз бүген!
Җанга якты барсы, рәхәт, үз бүген!
Каләм генә «мыраулый», кәгазь тырнап...
Табалырмы сиңа тиң шәп сүз бүген?!

* * *

Килде аваз: «Йә инде, шул Яр өчен
Җирдән бездең, – уй-күккә очар өчен...
Болай булсаң, денеңнән дә язарсың,
Кара-чутыр бер кызга ошар өчен?!»

* * *

Рухта биекләргә ашкан дәверемдә
Ил каршында ник мин түбән хәлемдә? –
Дан юк... Синнән наз, җылы сүз булырмы
Җаным Ходайга ирешер мәлемдә?

* * *

Иртән сөйли радиодан... мелла Хатип:
Кандалыйны, татар, еш укып бак, дип.
Академик! Уят әле Яр хисең,
Тиңсез гашыйк Гаташ атын да әйтеп?!

* * *

Мин табынган саен ераклашасың,
Нинди канун-көчкә яраклашасың?
Горурлыкмы юлдаш? Әллә җаның таш?!
Гаташ, тагын абындыңмы ташка син?

* * *

Әллә нинди рәтсез, болгавыр заман!
Барчабызны үзгәрткән авыр заман!
Әйтәләр: «Син башка дөньядан, бәлки?
Үзгәрмисең... Картаймыйсың да... Яман!»

* * *

Һәрчак алчак: бәлки, уй-акылым юк?
Югалтырлык мөлкәтем, байлыгым юк?
Кыңгыр эш өчен борчымый вөҗданым,
Йокым тәмле... Һәм хәрам азыгым юк!

* * *

Ни генә беләм дөньяда?.. Белмәм, шәт, –
Җаным тыныч күпне белмичә яшәп,
Мәкер белмим, үч, явызлык миңа ят.
Дөнья бутамыйм, аз белгәч. Шуңа – шат!

* * *

Юк миннән дә зур гөнаһлылар, бәлки?
Гамәлдә ул – миндә тик уйлар, бәлки?
– Син – изге... – дип әйттең бүген миңа ник?
Тирәңдә миннән усаллар бар, бәлки?

* * *

Гаҗәп: юлың башында ук дошманнар
«Өргә» җай көтә – койрык кысканнар.
Мескеннәр! Бит савап табар иделәр,
Үз-үзләрен җиңеп, мактап чыксалар!

* * *

Һәм бар (шактый!) сиңа игътибар иткән...
(Шуңа булыр – син үсенеп тә киткән!)
Нигә соң мин хәтта шуларга «үчле»?
Җүләрлекме? Төп жанрым көнләү микән?
* * *

Син торган йорт – бер иске, тузган бина:
Дивар – кубып, баскычы тузан гына.
Шуннан күтәреләм, Яр, ак җаныңа —
Хыялымның чын биек чарлагына!

* * *

Безгә кадәр дә йөргәннәр бу күлдә,
Әмма калган күпме сер безнең көнгә.
...Яр, үтенәм: беркөн туйдырсам да мин,
Пакь тойгың өчен һичкайчан үкенмә!

* * *

Нинди булса да, сиңа яр бу башым,
Илһамга мәңге мохтаҗ ир чал чәчен
Яшь җаныңа, яшь даныңа бәйләсен!
Зинһар, димен, шулай булсын, җанашым!

* * *

Сөю! Ниләр әйтелмәгән бу бабта!
Буталдым бу юлда... Яздым бутап та...
Ярлыкарсыз... Әле «гөнаһ»ларымның
Бик аз өлеше бугай... бу китапта!

* * *

Уртак дус дигән Гөргери – Г.Рәхим!
Кабул күрмәсәң язганым, ни әйтим?
Чукынып китим, хисләрем саф, ихлас...
Дәш, ошатсаң: «И Хак! Рахмәнир-рахим!

* * *

Дүртъюллыклар – Ярга эндәшү-хитап!
Күңелем мөнбәреннән син – хистән хисап! –
Тукай һәйкәле янында башландың...
Бер ел узды... мәңге шунда Яр, дус тап!

**МОҢСУ БЕР БАКЧА**

* * *

Әллә инде озаграк көттем? Озак...
Сим-Сим, кайда син? Ачылмый бер йозак:
Оҗмах ишегеме йә күк капусы?
...Җавабың бардыр, табышмак, сер-җомак?!

* * *

Мин язам. Ә бакчамдагы алмалар
Ымсындыра: үрел, ал – алсу, аллар...
...Көзнең тиңсез яме, өмете булып
Чемнән түгел, җаннан өзелер алар.

* * *

Кайгыда җан... Ил кайгысы ул: Нажар...
Китте олуг шагыйрь – күңелләргә Яр,
Уфада яшәп, Казан! дип янган дус...
«Татар теле» дип кем язар, кем янар?!

* * *

Без якташлар идек, әйе, бер яктан –
Агыйделле һәм Бабичлы тарафтан.
Ике тиңсез остазым... Шигырь-Әнкә,
Туармы сине шулар күк яраткан?

* * *

Аны уйлыйм; уем-шигырь минем дә:
Истәлекләр... Җәйнең матур көнендә
Бакчама бит мине эзләп килде ул,
Шуңадыр яшь бүген гөлләр күзендә!

* * *

Яшь гөлләргә, яшьлеккә – хәятында
Гел сокланды, тукталды җыр атында:
Киләчәген күзаллаган ул моңның.
...Яр, синең исмең дә бар – хатында...

* * *

Китә соңгы асылзат, азаматлар.
Төрки рухны үлгәч тә алар саклар.
...Шундыйлыкка әллә бездәме дәгъва,
Әй, барсыннан разый, тук, канәгатьләр?!

* * *

Шагыйрь үлү – йолдыз сүнү, югалу...
Күңелләрдә уелып нуры калу.
...Кабатлана – китеп кадере «арткач»,
Бер пәйгамбәр иде бит дип юану...

* * *

Ике меңгә керәм моңсу... Беләм мин –
«Гүрләр аша – алга!» – Гете сүзләрен.
Алда – Яшәү, Сөю, Җыр; алда – Яшьлек, –
Анда һаман сиңа баксын күзләрем!

* * *

Әлегә Син янда. Җанда – хыялым
Исән һаман, хистән нигә оялыйм?
...Киләчәктә бу «Робагыйят» Сине
Исертерме? Искермәмме? Уйланыйм...

* * *

Әле фани дөньяда мин – фанатик:
Биектә йөрим, күкләрдә – лунатик.
Айның тарту көчеме син, биеклек?
Сиңа ник гашыйк җан якын була тик?

* * *

Сөйләшик бер шул урында, сердәшем,
«Яр» сүзе күптер җырымда, чордашым!
«Яр» – Хак үзе бар итү, яратудан,
Һәм ул нәкъ Синең турында, җирдәшем!

* * *

...Бер манзара: ерακта кораб бара...
Мәрмәр, Эгей? Ярга чыккан кыз бала.
Җир тетрәгән чакта бирегә аны
Ни китергән? Җырмы? Сакла, бер Алла!

* * *

Ил-кыйтгалар кысандыр шигырьләргә,
Төрки нигез – тамыры сау күңелләргә!
Милли тарих – моң, җирсү җилкән булмас
Маңкортка тик... Юлдаш булмас җилләр дә!

* * *

...Сәйяр җанның сәламе килеп җиткән,
Ул китаплар (мине дә!) сорый икән.
Төркиядә – гашыйклар ватанында
Шансыз исемең, Гаташ, яңгырый микән?

* * *

Ә бит чакыра безне дә аваз-нида:
Анда Троя... Ә бәлки, Атлантида!
Нуриханын көткән Фест дисбеседәй
Әйтә булыр: «Мин монда, Әнкә-дөнья!»

* * *

Сөрмә ит, җыр, читтә ватан тузанын!
Илдә үтәрбез вөҗдан, тел кушканын.
Әлифбабыз да латинга кайтыр, шәт,
Шул имляда дөнья иңлик, дусларым!

* * *

Яр! Син кереп ямьләп чыккан бакчамның
Бар төшендә нур калдырганмы җаның?
Һәр чәчәге сорый: «Кая китте ул –
Ханиясе безнең моңсу бостанның!

* * *

Флокслар үскән җиргә чүгәләп,
Нинди әфсен укыдың, Яр-күбәләк?
Арта һаман хуш исе... Кисеп җанны,
Юкса көз килә, таҗларны өзгәләп...

* * *

Тик безнеке булган серле кичәләр...
Башкалар шул сергә дәгъва итсәләр?
Бар мизгелләр: Җиргә тик икәү сыйган...
Тартына хис – хәтта күкләр белсәләр...

* * *

Шүрәле күрдеңме? Син – Тукай ягында...
Кемне уйладың анда – җыр тарафында?
«Сине түгел!» дип, җил хәбәр китергәч,
Һушсыз булып яттым гөл арасында.

* * *

Бәрәңге дә, күр, даулый илдә хакын:
Каләм тотар яшь кулың казый «алтын»...
Ризык таушы яшьтән таныш шул безгә! —
Шигырь бәясе төшмәс бит, әйт, халкым?

* * *

«Чакырып алдым әле чакрым ярымнан...» –
Белдем, аерым яши алмам ярымнан.
Җитмеш булсын, йөз, мең чакрым – чакырам,
Җырда сине аерыр көч юк җанымнан!

* * *

Начтук әбкәңнең җыры гел колакта:
Елгамы дәште онычы – болакка?
Инеш идеме саф моңлы Нина әнкәң?
...Нишләп шагыйрә тумасын бу якта!
* * *

«Бу илләрдә гашыйк Чалбала булды...»
Шундый язу күзеңә чалындымы?
Балкып, сүнеп, шулай искәртәдер Күк!
... Ә китабым янмыйча язылдымы?

* * *

Сезгә кайткач, хәтерлә, көн ачылды...
Яхшы фал! Хыял туктаусыз ашкынды:
Аязда күрдем җаныңны ачыграк...
Һәм ныграк сөйдем миңең, күз-кашыңны!

* * *

Фаш итимме тиңсез... шикчел икәнем?
Бер халәттән сездә йөдәп беткәнем?
Йорт, мәктәбең – һәр җирдән бакты безгә
Бер көнчел рух – исме, имеш, «Никодим»!

* * *

Ошыймы язганым, нигә язмыйсың?

Көзге уттан курка мәллә яз хисең?
Инде бар җан дөньям егылды Сиңа
Сәҗдәгә – Кояш, Ай, Җир дә... Аз! – димсең?

* * *

Безне күргән көнләшә йә соклана,
Гадәти пар-яр түгелдер без аңа.
Ә шулай да... хуплаучылар күбәя...
Үпкәбез булмас бу камил дөньяга!

* * *

Онытма (мең елдан соң да!), сөйгәнем,
Иртә-кич шашып янына килгәнем,
Көнләвем... һәм ир башымнан елавым,
Әмма кыен булды шуннан көлгәнең!

* * *

Латинча «w» – «виктория», җиңүме ул?
Син яраткан киногерой сүземе ул?!
...Чын каһарман сөюдә җиңелсә дә,
Олуг ул, гашыйк шигаре – «түзем бул»!

* * *

«Какканны күрдем» сөюдә мин – ятим,
Ихлас «сыйпап үстерде тик милләтем...»
Яшәү – бүлмас үпкәсез... Була калса,
Милләтнең тәкәббер кызы, сиңа әйтим?!

* * *

Нәкъ кырык ел (!) – мәктәп бетергән идем,
Аннан – Уфа, Казанда дарелфөнүн.
Мәскәүдә дә шәкерт идем. Кем булдым?
Түземле бу дөньяга: «Гафу кыл!» – дим.

* * *

Ә Уфамда кумир – Атнабай иде;
Дуслыкта – Ай, шәкертләргә бай иде.
«Иде» дим... Аһ! «Кабатланмас канат-дус
Вафат!» диеп, җан өзәр хәбәр килде.

* * *

«Йолдызларга йолдыз атылып» гелән
«Очрашканда, – диеп, – көннәр төн белән».
Синең җырны Ярга җырладым төнен...
Шул мәл җан кошың очканны кем белгән?!

* * *

«Кичә берәү китте бу дөньядан» дип
Язган идең, тормышка гашыйк әдип...
Үзең киттең бүген... Олуг матәмең

Күтәрә алырмы энең – чал Рәдиф?!

* * *

Күз алдымда бит шанлы гомер кичте, –
Остазларым бакый дөньяга күчте.
Югалтулардан гел тулы моң касәм
Бушармы бер? Бу җаным күпме эчте!

* * *

Алтмышынчы еллар! Шигъри табында
Без, «биш йолдыз», тостлар чөйгән чагында
Ант эчтек бит һаман тугры калырга
Гасыр ахырында һәм аргы ягында.

* * *

Күпме хаким, хәким безнең дәвердә
«Сөрде дәүран»... Күпләр инде кабердә.
Күпме канун алмашынды! Иман – сау,
Шагыйрьлек тә сакланды күк хәзергә!

* * *

Дары иснәгән буын, син исәнме?
Оныклар хәзер газ, агу иснәрме?
...«Герман көе» елаткан милли җанны
Инде Әфган, Чечен моңы кисәрме?

* * *

Азмы алмалы хыяллар алдады!
Коелдымы?.. Яфрагы да калмады.
...Бер гаҗәеп яктылык пәйда булды:
Ачык күрәм Мәңгелекне... Алланы!

* * *

Үзгәрде дуслар, чынлыклар бу йөздә
(Юккамы тирән сызыклар бу йөздә?!).
Сабыйдан пакь, Йосыфтан матур яшьлек,
Сине танып, бүген кем дәшәр безгә?!

* * *

Һәм якында – Хисап көнең үткәннән!
Еллар – гомер, бәлки, бушка үтмәгән!
...Һаман багам: туган җир – җыр башында
Бер чишмә бар... Исәндер ул – кипмәгән?

* * *

Мин – оптимист, гәрчә пессимистлар бар,
Дөнья булгач төрле-төрле эшләр бар.
Үзгәрдек, «үстек» без озын юл үтеп,
Күп яшәлгәнгәдер – шөбһә, шикләр бар?!

* * *

Элек, хыял, йорт-курамнан чыкмадың,
Хәзер инде киңәйде офыкларым;
Шөкер, күзаллыйм безгәчә дөньяны –
Киләчәген чамалыйм оныкларның!

* * *

Әйтә төштә әткәң-әнкәңме: «Рәхмәт,
Җаныгыз ихлас – тимәстер сүз-гайбәт.
Аңлап та бетмәстер, бәлки, бу гавам,
Шигырьгә без бәхил... Ихласлык – әйбәт!»

* * *

Яңгырый җыр: «Титаник» музыкасы...
Син яраткач, килсә дә үз итәсе,
Чыңлый шулчак чулпымы? Сүрәкәме?
Әллә инде ханбикә хәситәсе?

* * *

Бу – хат елы булды. Язам, язылыр...
Көн-төн синең тарафка сүз агылыр...
Гасыр ахырыннан хатларым! Югалтма,
Яңа йөздә аңлаганнар табылыр!

* * *

Сентябрьме? Көннәр көн дә үзгәрер.
«Яңгыр», «аяз» – җырда да сизеләдер?
Шулай да җырым – алтын көз җимеше;
Татлы, диярсең, ачыккач син дә бер!

* * *

Нәрсә әйтим, дусларың әйбәт алар.
Язганымнан «эзләреңне» тапсалар:
«Нинди бәхетле Син! – диләр, – Каракай...
Аһ, безне дә бер шулай яратсалар!»

* * *

Исмеңә атап, бу китапны язсам да,
Гомер көзем һәм хисем фашласам да, —
Ике дөнья каршында да йөзең ак,
Фатихаң бир, яңасын башласам да!

* * *

Яр! Сафолар, Софьялар, Мариналар... –
Матур затлар, барыбер җанга чит алар.
«Безнең ил» дә «Гөлҗамал»лар тибрәткән
Талбишектән төшмәгәннәр бит алар!

* * *

Көз, димен дә... якты көн дә аз булмый.
Тик җылы аз... көз шул хискә – яз булмый...
Бүген сезгә очырам моң кошымны:
– Синсез яшәү юк: язылмый... Рас! Булмый!..

* * *

Сөеклем, дим, «түлә сөюем әҗере»н,
Йөз сүземә бер җавап бир, кадерлем!
...Кайда соң ул, дулап таләп иткән чак?
Ник басылдым, хәтта юаш хәзер мин!

* * *

Ни генә әйтмә, Гаребтән җан гарык:
Аннан алган калып-өслүбем ярык...
Шуңа гел «Хәйям!» дим; кайтам Тукайга...
Кайтам, димәк, үзебезгә: без – Шәрекъ!

## АЛТЫНМЫ, КӨМЕШМЕ КАСӘҢ, АЛТМЫШЫМ?!

* * *

Робагыем! Бирерсең бит бер киңәш:
Ярым... бик яшь, булырмы җанга сердәш? –
Яңа гасырга мине ул алырмы?
Аралаша салкын шик һәм эссе яшь!

* * *

Куз-күмерләр эзлим көлдән кайчак мин,
Сүнгән учакларым, сезне кочаклыйм!
...Нигә үткән? Кисә күзне төтене
Ят өчен бүген син яккан учакның...

* * *

Уйлыйсыңмы зарың тансык яшькә дип,
Әй, күңеленне яшьләрең юган Рәдиф!
Мәңгелек хис касәң... нинди шәрабы?
Шигырь дәрт тик... Ялгышма ул дәрман дип...

* * *

Мин өйрәткән гыйлем... каршымы миңа? –
Ятка сыеныр фән укыттыммы Сиңа?
...Кем ышаныр, камил тәрбия алгач,
Остазына шәкерт ят булмасына?!
* * *

Ә мин Ходайга ялварам: «Бир канат!
Биек очсын... Булсын тиңсез бер талант.
Һәм миннән киткәндә беркөн мәңгегә,
Бир көч, Тәңрем, кул болгарга соң кабат...»

* * *

Күпме кыйсса, әфсанә бар ядымда!
Күпме гашыйк аһлары – колагымда...
Тик берсе дә ачык, төгәл сөйләми
Синсез узачак гомерем хакында.

* * *

Бер аңларсың син дә минем халәтне,
(Тик мин булмам... – ерак ул көнгә хәтле!)
Сәер, шул халәт каләмгә: «Бу – бәхет,
Каргый күрмә мәхәббәтне...» – дип әйтте.

* * *

Гасырның соңгы сулышы, Ике Мең!
Бәхетлеме, бәхетсезме итүең?!
Күпме афәт китердең... Кем җәзасы?
Нык яраткан өченме бу хөкемең?

* * *

Чәчләреңне җилләр тузгыта булыр,
Салкын язда да ут-хисләр ургылыр.
Чияләр, күр, шау чәчәктә... Беркөнне
Шул чәчәкләр минем чәчкә коелыр...

* * *

Шыксыз язга җылы җаным ник ачтым?
Бикле уйларың – хыялым ник ачтым?
Күңелең тарихмы? Чөй язу, таш билге...
Әлифба-ачкыч яраттым... Ни ачтым?!

* * *

Аңлармы ятлар, аларга ни – «аһ»лар?
Һәркемгә бар язмыш – юл... шуннан атлар.
Әйт, ул кайсы әкияттә, чал ир сөйгәч,
Мәңге аңа тугры туташ – үрнәк бар?!

* * *

Чәчәкләр, сезнең касәләр гел тулы!
Эчтем ләса яшьлек кулыннан, булды!
Гасырны исереп озату ярармы?
...Аек килеш тә кала алмам бу елны!

* * *

Үрти, көлә, чакыра кем еракка?
Яңа гасыр? «...Уйга төшмә озакка.
Әле миңа һәм ярыңа кирәк Син,
Әй-йа, шагыйрь, әллә кая олакма!»

* * *

Күрәм җанны дәшкән бөек көч итеп
Синең таңны! Минем...килә кич җитеп.
Шуңа ачу белән, ахры, язам күп...
Син дә яз язында, көзгә үч итеп!

* * *

Йә, кил әле, укыйк икәү Пушкинны,
Чәчрәр, бәлки, җанга уты, очкыны...
Бөекләр белән сөйләшү – җиһанны
Ныграк аңлау... Шул – шагыйрьнең эш көне!

* * *

Күзаллый хыял бүген дә бүлмәңне,
Гыйбадәт урының– мәгарә, хөҗрәңне.
Һичшиксез хак дингә кайтам – көтәм тик
Тизрәк сиңа яңа вәхи иңгәнне!

* * *

Кирәк, кирәк, табыныр Кеше кирәк,
Нурлы, биек, бөек, пакь, көчле кирәк.
Гомеремне күпләргә багладым мин! –
Атым – Рәдиф, димәк, иярчен йөрәк.

* * *

Ай, шагыйрьләр! Хыялый ханым, ирләр...
Аңлыймы соң сезне Җир? Кавем, илләр?!
Күп – яратмаучы, көнләүче, хөсетле...
Табынганнар да күп! Юк, кимемиләр...

* * *

Хәбәр итепме яңа шом-афәтне,
Шаулый, шаулый җилләр нигә бу хәтле?
Әллә кар... йә салкын Яр болыты?
Йә ялгыш уй-гамәлләр галәмәте?!

* * *

Җилдәнме, нәркис, лаләләр талпынган?
Йөгерәме, куып җитәм дип, артыңнан.
«Барысын да әйтмәде Гаташ...Китмә әле...» –
Бик мөһим яшерен серләре бар сыман.

* * *

Фал ачыйммы кайтырыңнан? Ни әйтә
Шагыйрәләр? Алар белә, әлбәттә...
Дәшми ник Саҗидә апаң? Лена да...
Салкын, сүзсез Ахматоваң да хәтта!

* * *

Бәләбәйне, ниһаять, без дә күрдек,
Фатих Кәрим дәште дә, бардык, йөрдек.

Кулыннан бүләк тә алдык. Якташ бит
Безнең җаннар, димәк, җырлар да! Белдек...

* * *

Зөлфәт, нихәл! Кайда Тукай тамгасы?
(Минем җанда сине хуплау тамгасы!)
Чәч, пеләш тирәли нур шул таҗданмы?
Ялгышмаган, валлаһи, дан алласы!

* * *

Өзә җанны: «Әүмәле дә тәүмәле...»
Дәшәм сиңа: «Исәнме әле, саумы әле?!»
Минем өчен, хисем, шигырем өчен
Шул җыр – җанның тоташ тетрәү, шау мәле.

* * *

Шагыйрь! Булган сиңа рәсүл ихласы:
Тар иңеңә кунган киң ябынчасы...
Мең елдан артык бит шуны ябынабыз –
Шагыйрьләр – мөслим, кяферләр барчасы!

* * *

Әнкәсенең каберен яд итеп, елап
Искә алган пәйгамбәр хәлен уйлап,
Авылымдагы нәни тауга кайтыйм, дим...
Гөнаһым зурдыр... Форсат юк, юл – ерак...

* * *

Әнкәм күмелгән Марсымда, зиратта
Инде шагыйрь агам Рәшит тә ята.
Югалтулар... Пәйгамбәрдәй ятим мин,
Җыр касәмдә шуңа, бәлки, гамь арта?!

* * *

Рәфит, Рәфит! Сөйләшик, сау туганым!
Яшәүдән, Дөньядан юктыр туйганың?!
Безне – фәкыйрь, ятимнәрне Хак бит шаһ
Иткән рухта – ул биргән шагыйрь җанын...

* * *

«Шигырьдә бар Марс атлы йолдызлык!» –
Диде башкорт Әлибай (Яшә, дуслык!).
Яңа йөздә ул янармы, сүнмәсме?
...Без бусында бергә – бәхетле булдык!

* * *

Алтынмы, көмешме касәң, алтмышым?!
Кайнап тора һаман да, Гаташ, хисең!
Гамь шәрабың өләшсен җан, ул – сакый,

Калдыр, гомер, ихлас сүздә шат исмең!

# *VIII. Соңгы еллар дәфтәреннән*
***(2001–2006)***

* * *

Рәсүл үзе уңнан сулга яздырган
Аллаһ сүзен... Кем шул юлдан яздырган?

Изге сурәтле мең еллык хәрефне
«Оныттырды» ни – бер ят рәвешле?

Нинди язмыш – кемнең көче, әмере
Алды аңны ... гүя шайтан хәмере?!

Кот киткәндер рух язуын үзгәрткәч?
...Тәкъдирме бу? Мәскәүме – катгый әйткәч, –

Укып «кирилл»да, без шактый тукындык...
«Чукындык!» дип, искә килдек – укындык!

...Тагын яңа күчеш көтә имлабыз,
Ходай, инде үзгәрмәс бит кыйблабыз?

...Шик-шөбһәләр булган, булыр, табигый...
Тарихи кан... Улмы Хакны танымый?

Сулдан уңга илтсә латин язмабыз,
Аздырмас бит Иблис? Шаять, азмабыз?

**ТУКАЙ ТАҖЫ**

Шигърият!
Тагын җаныңны
Барлый яз – чираттагы...
Нурланып яңа биектә
Тукайның мирас таҗы...

Уй җитә алмас шигъри таҗ!—
Бармы, әйт, сиңа лаек?!
«Мин!» дигәннәрне, варис дип
Танырмы зирәк халык?!
Хакның тик исемен әйткәнгә
Әҗер без көтмибезме?!
Изге кәгъбәгә пакьсезләр,
Исерекләр үтмибезме?!
Көч, дәрәҗәбез дә бардыр
Йолдызга үрелергә!
Ходай... аһ, Тукай каршында
Курку да булса бездә!

Ә бармы моңсыз шигърият?!
Әдәпсез әдәбият?!
Үзең әйт, шигырь алласы,
Вөҗданны безнең уят.

Мәңгелек җыр – Туган телне
Котлый яз – чираттагы...
Биектә һаман кул җитмәс,
Сатылмый, вакланмый торган
Шигърият –
Тукай тажы!

* * *

«Гел бөгелеп, гөл таҗын үбә торгач,
Горурлыгын – үз таҗын җуйдымы баш?
Шаһ түгелдер – күптән кол мин сөюдә,
Җаным һаман шашкын хискә буйсынгач,
Шул таҗсыз гомергә яшь яр баш булгач!»

... Алтмышына җиткәндә, сискәнде дә
Шуны әйтте кем – «эзеңә яшь койгач...»

**БИЮЧЕ КЫЗ СУРӘТЕНӘ**

Калибан, дипме атарсың?
Каннибал мәллә Гаташың?
Күр карашын:
Йотар булып текәлгән.
Әйтәсең күк:
– Әле вакыт җитмәгән...

Оҗмахтан алган ике алмаң
Тәгаен пешкән, тыгыз...
Кул сузудан тыя күзең:
– Сабыррак булыгыз!

Бии гүзәл тәнең. Шулмы
Хавадан мирас балет?
Ул – һинд йә гарәп көеме?
Шашкын «корсак биюе»ме?
Күзәтәм хәйран калып.

Тузгыган чәч өермәңдә
Ни? Сансыз Адәм җаны! –
Ияртkән сөю ятьмәсе
Гашыйклар кавемен... Әйтәсең:
– Үзеңне шуннан таны!

...Әй, мәңге канмас ир күңле!
Сусавың ник бетмәгән?
Ширбәт эчим бер, бир, Ходам,
Эчимче ярым кулыннан –
Әле вакыт үтмәгән.

Күзләрем җуйган түземен –
Йотар кебек текәлгән!

* * *

Кем соң әле миңа бер әйтте аны:

– Капласа да тыштан кабырчык җанны,
Эчтә – бәхет! Көтә ул ачылганны...

Ә ачкычын табу язган соң кемгә?
Ачылыр сер буйсыныр нинди көйгә?

Аңлар соң кем ахыргача Кыз җанын,
Бәллүр җанның кайчан ташып-тулганын?

Яулыйм, димсең? Корбан бул ярың өчен,
Бары аңа багышла гомереңне син.

Куркытса да сине тышкы кабырчык,
Эчендә бит балкый – күрүчесе юк! –

Тиңсез энҗе... Үсәчәк ул, көтәчәк,
«Зиндан»нан аны кем азат итәчәк?

Бел: морадка тик сабырлар җитәчәк!

* * *

*(Фарсычадан)*

Ачылдымы җырдан «бәхет капкасы»?
Алдымда ни? Гүя тылсым бакчасы...

Әкияти Гөл-лалә күрәм... ут чәчәк! –
Хыялымны ул таҗына төрәчәк!

Аһ, Матурлык! Нурдан яралган заты...
Ул – бәхеттер, кемнең өлеше, хакы?

Үземә алсам, Матурлык, тик микъдарың,
Мәңгелеккә илче-сурәт итәрмен!

...Шул Гөл-лалә тик хыял, ди, – Җирдә юк!
...Касәсеннән эчмәгән шагыйрь дә юк!

* * *

Күз-керфекләрең аз гына дымсурак...
Йөз – бәхетле, бераз тартылган сымак...

Кавышу төненең ашыккан иртәсе!
Берәүнең бердәнбере син – бикәсе...

Бар дөньяның күзе сездә гүяки,
Сөеп багу, сынап карау – үтәли...

Хыял кызартса яшь малай, кызларны,
Карт-карчыклар уфлап уйлый узганны...

Туй кояшы – кияү балкый – канәгать...
Тәңкә-тәңкә рәхмәт сибә мәхәббәт!

Беренче мунчадан соңгы рәхәтлек!
...Оялчан наз – кәләштә... Ирдә – шәплек!

* * *

Тагын туган җирдә мин, Уралымда,
Син уяткан уйларга уралдым да

Башым куйдым тагын тау күкрәгенә –
Меңәр еллык җырлар һәр тетрәвендә!

Таймасам җаннан күкрәүләр узганын,
Каян минем үз дәрманым, моңнарым?!

... Хисләр дә бүген ефәктәй сузыла,
Туган җир, кызыл кояштай кызыңа!

Ут-чәчләргә тели җыр уралырга.
...Чит күрмәсләр, димен, үз Уралымда!

* * *

Иреннәрең тетрәнә нәкъ гөлчәчәк,
Читтә торсаң гүя үпкәләячәк;

Якын барсаң, яндырыр кебек уты...
Яндырмаса? Көч бирсә яшьлек суты?

«Авызы шикәр, бал кебек» дип җырлаган
Бабайлар да бу бабта ким булмаган;

Сөеп, күптән тиңләгәннәр ал гөлгә!
...Күпме гөл гомерен кискән җил бу илдә!..

Күпме яудан яшь, гамь бар Иделләрдә...
Шуңа ярсу үч янса иреннәрдә? –

Тетрәнәләр, димәк, утлы тарихы...
Идел гөлем, Син – шул тарих варисы!

## ЭЧТӘЛЕК


Заманның шигъри пәйгамбәре. *Р.Ганиева* .................

**I. Чулпан-йолдыз калыкканда. (1994)**

«Акыл җуеп...» .................................
«Кыз хыялы!..» .................................
Бөекләргә касыйдә ................................
«Әүвәл пәйда булып илдә вәкиле...» .....................
«Тагын шул як дәшсә сине...» ........................
«Миннән соң да аязыр йә...» .........................
«Бәлки, шагыйрьләр оҗмахы бу кала?..» .................
«Ян әле син!..» .................................
«Иске саутыңда, тән...» .............................
«Сүзләр – гүя йөгерек су...» ..........................
Олыгайгач, бер дога ..............................
«Җырлар җыры»н укыгач ...........................
Сиңа – Сәгыйть Рәмигә тәкълидән ......................
Уфадан сиңа хат .................................
«Ни китәрде Әфганда...» ............................
«Әкияттәге өч патша кызы гүя...» ......................
«Сәламнәрем сезгә – өч кыз туганга!..» ...................
«Нииндидер төпсез коеда калганмы...» ....................
«Яшь яр, миңа нигә ишегең бикле?..» ....................
«Гаебем синең алда зур: чал чәчем...» ....................
«Ник шулкадәр уйлыйм мин синең хакта?..» ...............
«Кайт тагын да шигыремә...» .........................

«Гүя айнып китте җырым...» ..........................
Синең бүләгең – Ләйлә сурәтенә ........................
«Нинди сер соң бу юлларда?..» .........................
«Ни әйтим мин?..» ...............................
«Кызлар, быел һәммәгез ут чәчлеме?..» ...................
«Садәлегем куркытамы...» ..........................
«И милли яр!» .................................
«Кабат-кабат сорыйм...» ............................
Сәяхәттән экспромтлар ............................
«Ник җаныңа үталмый җан...» .........................
«...Ә нинди көч хуҗа минем җаныма?» ...................

**II. Моңсу матурлык. (1996–1998)**

«Яшьлеккә хас саф...» .............................
Гөнаһ-ут .....................................
«Син язмышым мәллә...» ............................
«Пакь яшьлегең саклый алса...» .......................
Шөн дастаны *(Цикл)* ..............................
«Ки-и-л! – димен...» ...............................
«Мин, ахрысы, өметемнең чигендә...» .....................
«Иреннәрем тияр-тимәс касәңә...» .....................
«Назларымнан качтың һаман...» .......................
«Бөдрә яшь тал...» ................................

**III. Кальбеңә хис юлласам... (1998–1999)**

Луизалар өчен генә... түгел ..........................
«Дөнья гиздем...» ................................
«Бу чәчәк балигъ түгел...» ..........................
«Көтәсеңме янганымны...» ...........................
«Гүя лалә йөзеңдә тап-миңеңне...» ......................

**Борынгы җырларга вариацияләр**
«Суда балык йөзәдер...» ............................
«Сезнең тирәдә... козгыннар очадыр...» ..................
«Ә сезнең соң күңелдә...» ............................
Җыр эзеннән ...................................
«Иртәләрдә уйлыйм...» .............................
Арысланкай киек .................................
«Җаныем, чәчең чыннан дамы бөдрә...» ...................
«Булырсың чын хәйран...» ...........................
«– Сине бит күпләр сөйгәндер?..» ......................
«Син, бәлки, Мәңгедән миңа...» ........................
«Әйттем...» ...................................
«Тигезсез без!..» .................................
«Сиңа абый тиеш йөрәк өчен...» .......................
«Төшеңә кердемме?..» .............................
«Илдә – алты яшәр юлдан кайтса...» ....................
«Куркытмыймы алда имтиханың, Яр?..» ..................
«Безнең хис өчен Шеллиләр шөллиләр...» .................
«Синең беренче хисләрең...» .........................
«Чәчләреңә төрдең мине...» ..........................
«Күпме хат-хитап бар гүзәл җенескә...» ...................
«Мин китаплар бирәм Сиңа...» ........................
«Бәлки, сине – бердәнберне...» ........................
«Ил табынына ярармы сыем бу?..» .....................
«Әллә эссе капты җанга...» ..........................
«Безне генә күзләде бит...» ..........................
«Бармыни моңга имтихан?..» .........................
«Бер карашыңнан кечерәйсен...» .......................
«Һаман язсам – ул Сине сагынганга...» ...................
«Яр! Күз салдым ялгыш мин язганыңа...» .................
«Әтил суы ака торур...» ............................
«Күнегә алмам сәер бу җиһанга...» ......................
«Узып тик... илле (!) ел...» ..........................

**IV. Газәлләр. (1965–2001)**

«Кайда ул ил?..» ................................
Каләмгә газәл .................................
Мәҗнүн XX ...................................
1913 елның җәе. Зәйтүнә – Тукай каберендә ................
Зәйтүнә Мәүлүдова-Рәсүлевага газәл-хат ..................

Бабичка бер вариация-газәл ..........................
«Аңладым, ниһаять!..» .............................
Синең газәл ....................................
Газәл. 1989 ....................................
«Ташлармынмы? Җыр ни ди...» ........................
«Әй, йолдызчы! Сиңа минем...» ........................
«Багышладым җанны сезгә...» .........................
«Синдә, әйт, болан күзле яр...» ..........................
«Синең күзләр...» ...............................
«– Безнең якта алма, диләр...» ..........................
«Бәхеткә, әлбәттә, яшьнең хакы зур!..» .....................
«Синең бакчаңа кунган мин...» .........................
«Дуслык урамы»ннан хат...» ..........................
«Димәк... Сездә гашыйктан көлү уе!..» ...................
Безнең газәл ....................................
Тагын бер уртак газәл ..............................
Фөзүли газәлләре ................................
Газәл-тәрҗемә ...................................

**V. Гөлбалага хатлар. (1996–1998)**

«Изгеләр, дидем, сез мәдәт бирегез!..» .....................
«Күземнең нуры, бел...» .............................
«Гөл туташ! Сиңа дәшәмен...» ..........................
«Сүзең балы җам...» ...............................
«Яннарыңнан куган – ул мин түгелме?..» ..................
«Бакчада алтын өләшә сентябрь!..» .....................
«Сары яфрак...» .................................
«Гомер таңында, җитәкләп, кулыңнан...» ...................
«Язларың саныннан синең...» ..........................
«Инде... Мин...» .................................
«Кариэм, дим, бармы сабрың?..» ........................
«Язам – сиңа хатым барып җитәрме?!» ...................
«Йа Ходай! Миңамы бүләк...» .........................
«Гашыйклар яше ашлаган гөл кыры!..» ...................
«Хатыма әгәр тамса яшь...» ..........................
«Кул изә һаман миңа...» ............................
«Бәхетемме, бәхетсезлегемме?..» .......................
«Күпер аръягындадыр җан...» .........................
«Ни генә әйтер ак кәгазь?..» ..........................
«Очратудан әүвәл...» .............................
«Ник яшь зәүкың...» ..............................
«Нур илендә гөл син!..» ............................
«Яндырды ник язганы син – баланың?..» ..................
«Кем кагылган синең сердәш каенга?..» ...................
«Сәерҗан» мин күпләр өчен...» ........................
«Өч айлык нарасый – өмет...» ..........................
«Ил картлары!..» ................................
«Сүзләрең – җыр...» ..............................
«Миллион халкы булган Казан...» ......................
«Сокланырсың бу Диванга...» ........................
«Иң матур шигырең Синең...» ........................
«Бозланган» булса күңел...» .........................
«Синсез дөньям кошлары – ни?..» ......................
«Биек күтәргәннәр...» .............................
«Авыр бу ел!..» .................................
«Сүнгән учаклар...» ...............................
«Коткарырга теләп сине ялгыштан...» ....................
«Җирдә шул кабатлана...» ...........................
«Шигырең шәрабын бер авыз итәргә...» ..................
«Илбашының юлы бүген...» ..........................
«Төнге шәһәр гашыйклары!..» .........................
«Яр» сүзеннән качма!..» ............................
«Ә мин хәзер төн-кичәләр кешесе...» .....................
«Бирсә миңа Сөю хакын...» ..........................
«Рәхмәт, Газәл!..» ................................
«Алты гына» аймы...» .............................
«Күзләрме тик?..» ................................
«Газәлләр ятлап үсәсең...» ...........................
«Син якында, Егерме беренче йөз!..» .....................
«Сиздекме без...» ................................
«Икәүләп илһам көтәбез...» ..........................
Кышкы газәл ...................................

«Чайпалыр да ташырдыр...» ..........................
«Ут янам...» ...................................
«Күңелем аңламыйсың...» ...........................
«Минсез ниләр били синең җаныңны!..» ..................
«Быел сүзен дөнья бик кырыс әйтте...» ...................
«Ник килмисең?..» ...............................
«Юлбарыс елының кыен язы бу!..» .....................
«Нишләтим җанның...» ............................
«Җырда ярый зарлану...» ...........................
«Рәнҗешемме төшә...» .............................
«Нишлим соң?..» ................................
«Синдәйләргә – ихлас җанга – авырдыр?..» ................
«Газәлләргә тиңсез азык...» ..........................
«Сиңа ошармы бу бүләк...» ..........................
«Мең сорауның тапса бер җавабын...» ....................

**VI. Миңгүзәлгә газәлләр. (1998–2001)**

«Туганмын, бел, мин дә...» ...........................
«Төштә – кем?..» .................................
«Сусадым», «яндым» дип...» ..........................
«Әй-йа, күңел!..» .................................
«Зөһрәсе исмен телгә алу...» ..........................
«Узды бу яз...» ..................................
«Йә, авылда көннәрең...» ............................
«Ил хәтерендә калырмы бу кичәләр?..» ...................
«Шагыйрәм! Күр...» ..............................
«Хаксызга әйтсәм каты сүз...» .........................
«Кем ул?..» ....................................
«Шатмы хисең?..» ................................
«Миңгүзәлгә бер газәл-хат...» .........................
«Ни телим синнән, һинд гөлем?..» .......................
«Йә, әйт: кем мин...» ...............................
«Җаным!» дим...» ................................
«Җанан, нәнүс!..» ................................
«Агыласыз меңьеллыклары...» ........................
«Сихри бер миң саклый гаурәт алмасы...» .................
Дога ........................................
Газәлләр диванын тәмамлау ..........................

**VII. Робагыйлар бакчасы. (1991–2001)**

Багышлау – башлау ...............................
Әллә дөньяда бер яшәп киткәнмен... .....................
Әлвидагъ . ...................................
Тарафларга – хатлар . .............................
Бер йолдызның нуры ..............................
Сагышлы сөйләшүләр ..............................
Кышкы робагыйлар ...............................
Җылы язда яуган карлар ............................
«Моңлы бер мөнәҗәт...» ............................
Гөлләрнең шаһинәсе ..............................
Моңсу бер бакча .................................
Алтынмы, көмешме касәң, алтмышым?! ...................

**VIII. Соңгы еллар дәфтәреннән. (2001–2006)**

«Рәсүл үзе уңнан сулга яздырган...» ....................
Тукай таҗы ...................................
«Гел бөгелеп, гөл таҗын үбә торгач...» ....................
Биюче кыз сурәтенә ..............................
«Кем соң әле миңа...» ..............................
«Ачылдымы җырдан...» ............................
«Күз-керфекләрең...» ..............................
«Тагын туган җирдә мин...» ..........................
«Иреннәрең тетрәнә нәкъ гөлчәчәк...» ....................

Литературно-художественное издание

**Гаташ** Радиф
(**Гатауллин** Радиф Кашфуллович)

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

**В трех томах**

**Том 3**

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Гаташ** Рәдиф
**(Гатауллин** Рәдиф Кәшфулла улы)

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

**Өч томда**

**3 том**

Мөхәррире *И.Н.Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Л.Р.Галимова, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2009.
Форматы 70г108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 15,40.
Тиражы 2000 д. Заказ О-10.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.